МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№4 / июль 2012

Мирсәет Солтангалиевнең туына 120 ел

Питрау

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

Татарстан Республикасы Президенты
УКАЗЫ

**(2012 елда Ураза бәйрәмен
һәм Корбан бәйрәмен уздыру көннәрен
билгеләү турында)**

«Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре
һәм истәлекле даталары турында»
Татарстан Республикасы Законының
1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасында:

Ай календаре һәм гадәткә кергән традицияләр нигезендә
2012 елның 19 августын — Ураза бәйрәме башлануга туры килә торган көн;

Ай календаре һәм гадәткә кергән традицияләр нигезендә 2012 елның 25 октябрен Корбан бәйрәме башлануга туры килә торган көн дип билгеләргә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

Казан, Кремль. 2012 ел, 27 июнь.

Журнал «Татмедиа» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.

Индекс 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов

Иҗат төркеме:
Рамил Ханнанов
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Дания Фәйзуллина
Ренат Минигалиев
Ландыш Әбүдәрова

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ №17339.
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 х 108 1/16
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 13.07.2012

МИРАС

ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№4 / июль 2012

Эчтәлек

ТАРИХ
3 Социаль инкыйлаб һәм Көнчыгыш. *Мирсәет Солтангалиев*
11 Мирсәет Солтангалиев — милли каһарманыбыз *(«түгәрәк өстәл»)*
20 XIX гасыр уртасында керәшен татарларының Сабантуй бәйрәме. *Радик Исхаков*
30 Татарлардан беренче педагогика фәннәре докторы. *Ләлә Мортазина*
37 Шигъри дөньям. *Гәрәй Рәхим*
38 Гомумтатар мәдәнияте өчен мөһим! *Геннадий Макаров белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе*
46 «Питрау үтте — җәйләр бетте», — диләр...» *Клара Булатова*
47 Питрау ыруларын җыя. *Геннадий Макаров*
51 «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле. *Артур Поляков*
56 Укымышлылар турында. *Гәрәй Рәхим*
ӘДӘБИЯТ
57 Кыска, әмма мөһим нотык. *Зөфәр Рәмиев, Резеда Ганиева*
59 Нотык. *Гаяз Исхакый*
61 Ходай сине илдән алган. *Яков Емельянов*
62 «Җанга рәхәт туган яктан яхшы хәбәр...» *Әлфия Галимуллина*
ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ
70 Казан арты керәшеннәренең табын җырлары. *Зоя Кириллова*
76 Казан керәшен педагогия курслары укучысы И.Д.Бабушкин иншасы. *Радик Исхаков, Халидә Баһаветдинова*
84 Кешегә ни җитми? *Егор Уткин*
ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР
85 Халык байлыгы — җир белән су *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*
89 «Табигатькә нәрсә булды икән...» *Александр Филиппов*
90 Киләчәккә илтик. *Ямаш Игәнәй*
БАЛАЧАК ЯДКӘРЛӘРЕ
92 Чынаяклар. *Йолдыз Шәрәпова*
94 Яңа китаплар
96 Тарих сәхифәләреннән

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторлар һәм Макс Платонов, Халыклар дуслыгы йорты архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә — Питрау бәйрәменнән бер күренеш. М.Платонов фотосы;
3 нче биттә — Болгар шәһәрендәге Ак мәчет;
4 нче биттә — Керәшеннәрнең бизәнү әйберләреннән. Тәңкәләр.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132
ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә языла аласыз.

ТАРИХ

Кемнәр килгән,
кемнәр киткән —
Гасыр артыннан гасыр.
Ята милләт маңгаена
Тарих сызган күпме сыр?!

Гәрәй Рәхим

М.Солтангалиев,
И.Фирдевс.
1919 ел

МИРСӘЕТ СОЛТАНГАЛИЕВ

СОЦИАЛЬ ИНКЫЙЛАБ ҺӘМ КӨНЧЫГЫШ

I

Россиядәге социаль инкыйлаб — бу әле көрәшнең башы гына, бары тик дөньякүләм халыкара социаль инкыйлаб этапларының берсе. Иртәме-соңмы ул революцион көрәш формасына, бер-бере белән килешмәс ике дошманның, капма-каршы килүче ике көчнең — халыкара пролетариат белән халыкара империализмның тәвәккәл һәм хәлиткеч бәрелеш формасына әйләнергә тиеш. Бүгенге көндә элекке Россия монархиясе киңлекләрендә уза торган гражданнар сугышы чикләре һәм территориясе үзенең эчке мәгънәсендә дә һәм тышкы чагылышында да киңәергә һәм тирәнгәрәк китәргә тиеш. Инкыйлаб үсеш алган саен, тулаем алганда, җир шарында кешелекнең соңгы канкоешы булган бу сугышка үз ихтыярларына каршы барлык халык һәм илләр акрын-акрын тартыла һәм тартылырга тиеш тә. Бу — котылгысыз. Иске дөнья шактый какшады, тузды. Ул ыңгыраша, ухылдый һәм җимерелә. Үтәли череп таркалгач, бөтен җөйләре тарала. Бөтен җир йөзе һәм аның барлык атомнары, ашкынып, үзенең яңарышын көтә һәм көтә генә түгел, таләп итә, бөтенләй яңача төзелешен таләп итә. Кешелекнең аерым бер индивидлары, шәхесләре өчен генә түгел, хәтта, мәдәни-тарихи төрлелек буларак тулы бер халык һәм дәүләтләр өчен дә шундый хәлиткеч мизгел килеп җитте ки: боларның һәрберсе үз язмышын билгеләргә, үзенең баррикаданың кайсы ягында тору кирәклеген катгый хәл итәргә тиеш. Теләсәң-теләмәсәң дә, син анда катнашырга, аңлы рәвештәме яки аңсыз рәвештәме, син йә «кызыл», йә «ак» булырга тиешсең.

Моның шулай икәнен эш-гамәлдә күрәбез. Әле Октябрь инкыйлабы булмаган, әмма Россиядә хезмәт һәм капитал, пролетариат һәм буржуазия, бер-беренә дошман ике көч буларак, инде бүлгәләнә, үзбилгеләнә һәм бер-бере белән хәлиткеч сугышка әзерләнә башлады.

Октябрь инкыйлабы Россиядә бары тик әлеге көчләрнең бер-берсе белән бәрелеш мизгеле генә булды. Бу вакытта үз илендә тар-мар ителгән рус буржуазиясе калган көчләр тупланмасын кыска вакытка булса да якынча «иреккә» яшәү мөмкинлеген тәэмин итә торган урынга — Россия читенә һәм Антанта илләренә күчерергә мәҗбүр булды.

Әмма дөньякүләм инкыйлабка әйләнү тенденциясен чагылдыра торган һәм үсеш алучы бар нәрсәгә каршы көрәш халыкара мәйданга чыга. Россиянең үз буржуазиясен җиңгән эшче крестьяннарга каршы көрәштә рус буржуазиясе генә түгел, халыкара буржуазиянең аерым өлешләре, көчләре дә катнаша. Башта таркау булса да, алга таба көчләр берләшә. Аларның үзәк һәм оешкан көче булып бөтен җир шарының барлык контрреволюцион көчләре, бер фокуска җыелган кебек, бергә тупланган Милләтләр Лигасы тора. Ул инкыйлабның үсешенә тегеләйме-болаймы комачауларга һәм киртә булырга мөмкин барлык нәрсәне үз тирәсенә берләштерә торган кара интернационалга әйләнә.

Бүгенге көндә халыкара социаль инкыйлабның үсеш шартларын үз эченә алган гомуми нигезләмәсе ал-шартлары менә шулар. Бары тик шуннан чыгып кына без киләчәккә аның үсеше нинди формаларда булачагын фаразлый алабыз.

Хәзерге көндә безнең инкыйлаб гамәли формада алдыбызга куйган мәсьәләләрнең берсе — Көнчыгыш

мәсьәләсе. Безгә аны кичектергесез хәл итәргә кирәк. Ул — хәзерге чынбарлык һәм халыкара сәяси вәзгыять шартларындагы, аз да түгел, күп тә түгел, дөньякүләм социаль инкыйлабның табигый үсеш фазаларының берсе. Аның котылгысызлыгы менә шунда яшеренгән дә инде. Хәтта без аны танырга теләмәсәк тә, аның белән исәпләшмәсәк тә, ул барыбер үзенең эчке һәм тышкы катлаулылыгы, буталчыклыгы белән алдыбызга килеп басар иде. Әгәр мәсьәләне өстән хәл итү белән генә чикләнсәк, дөрес фикердә булмас идек. Бу мәсьәлә бөтен яклап һәм зур игътибар белән өйрәнүгә мохтаҗ. Социль-икътисади гына түгел, халыкара-сәяси мөнәсәбәтләрдә дә шул ук зарурлык.

Без теге яки бу очракта халыкара социаль сыйнфый бүленешнең гомуми барышында Көнчыгышның үсешен чагылдыруы мөмкин барлык тәгаен формаларны карап тикшерергә һәм алдан билгеләргә, шуның белән моннан килеп туган барлык нәтиҗәләре белән аңа булган мөнәсәбәтебезне дә мәңгегә ачыкларга тиешбез.

Социаль инкыйлабта халыкара сәясәтнең без алган гомуми курсы тулысынча дөрес һәм бернинди үзгәртү дә сорамый, дип күпме генә уйласак та, Көнчыгышка кагылышлы мәсьәләгә җитди төзәтмәләр кертелергә тиешлеген танырга мәҗбүрбез һәм моны аңларга туры килә. Шунысы кызганыч: бүгенге көнгә кадәр Советлар Россиясе белән Көнчыгыш арасында үзара дөрес хезмәттәшлек һәм мөнәсәбәтләр урнаштыруда без кабул иткән чараларның соңгы елларга кадәр артык очраклы һәм паллиатив төстә булуын да танырга кирәк. Бу өлкәдә планлы һәм ышанычлы-хәлиткеч сәясәтнең ныклап үткәрелүе бөтенләй сизелмәде дә.

Бу сәясәтнең тискәре ягы — безнең үз көчсезлегебезне чагылдыру һәм тану: мәсәлән, Персиядән рус гаскәрләрен чыгару. Ә инде уңай, яхшы дип санарлык гамәленә килгәндә, бер генә очракны күрсәтергә була — әфганлыларның инглизләргә каршы баш күтәрүеннән соң, без кылган гамәл кебек үк, Көнчыгышның революцион омтылышларына теләктәшлек һәм ярдәм итәргә вәгъдә бирү; әмма моннан ары уза алмадылар. Бу мөнәсәбәттә безнең хәрәкәт, эш-гамәлләр бары тик Көнбатышта социаль инкыйлабның уңышсызлыкларын ачыклау вакытыннан гына азмы-күпме төс ала башлый: вакыйгалар үсешенең барышы (Германиядә спартакчыларның җиңелүе, рус эшләренә тыкшынуга каршы протест белдереп, гомуми баш күтәрүнең уңышсызлыкка очравы һәм Венгрия Совет Республикасының таркалуы), ниһаять, безне Көнчыгышның катнашыннан башка халыкара социаль инкыйлаб ясау көчебездән килмәячәген аңлаткан гади бер хакыйкатьне танырга мәҗбүр итте. Тик әле хәзер дә бу чаралар социаль инкыйлабның дөрес үсеш законнары алардан таләп итә торган билгеле бер рәвешкә ия түгел.

Әлеге мәкаләнең бурычы — әлеге мәсьәләгә күпмедер күләмдә тулы анализ ясау.

II

Коммунизм чагылышы булган Совет строе — буржуаз-капиталистик дәүләтчелек антиподы. Бу ике строй бер-берсе белән янәшә тыныч яши алмый. Алар бары тик вакытлыча гына бер-беренә түзеп торырга мөмкин, чөнки теге яки бу як көчләре икенчесеннән аз гына булса да көчәеп китә икән, бу көчле як әлеге вакытка көчсезрәк булган якка кичекмәстән һөҗүм итәргә тиеш.

Инкыйлабның социаль үсешенең үзгәртелә алмый торган һәм төп законы нигезендә, Россия инкыйлабы

М.Солтангалиев, Ф.Ерзина, И.Фирдевс. 1919 ел

башлануының беренче көннәреннән үк бөтендөнья инкыйлабына әйләнә башларга тиеш иде, югыйсә Россиядәге бу Советлар империализмының котырынган диңгезендә бөтендөнья империалистик вакханалия өермәсе, давылы белән минут саен җир йөзеннән себерелеп төшү куркынычы янаган кечкенә бер оазис кына булып калыр иде.

Октябрь инкыйлабы җитәкчеләре бу хәлне бик яхшы аңлый иде, шуңа күрә дә аны халыкара интернациональ юнәлештә җибәрергә тырыштылар. Башкача була да алмый, киресенчә булса, Россиядәге социаль инкыйлаб үзенең барча эчке мәгънәсен югалтыр иде.

Әмма инкыйлабның бу үсеш процессы тактик ялгыш юлдан китте. Читтән караганда, аерым чагылышлары дөрес булып күренсә дә (Германиядәге спартакчылар хәрәкәте, Венгрия инкыйлабы һ.б.), гомуми эчтәлек ягыннан ул берьяклы гына булды. Бу берьяклылык инкыйлаб җитәкчеләренең игътибары Көнбатышка гына юнәлгән булуында күренә иде. Октябрь инкыйлабын халыкара социалистик ин-

М.Солтангалиев икенче хатыны Фатыйма Ерзина белән. 1919 ел

кыйлаб буларак җәелдерү мәсьәләсен гамәлгә ашыру аларга Россия инкыйлабы энергиясен, көч-куәтен турыдантуры Көнбатышка механик рәвештә, үзгәртмичә үзкүчерү булып тоелды. Пролетариат белән буржуазиянең сыйнфый мәнфәгатьләр каршылыгы бигрәк тә кискен һәм рельефлы булгач, җир шарының сыйнфый инкыйлаб үсеше өчен күпмедер дәрәҗәдә ныклы нигез булган өлеше иде бу.

Көнбатыш Европа буржуазиясе тарафыннан коллыкка төшерелгән миллиард ярым халкы булган Шәрык исә бу яктан бөтенләй диярлек онытылган иде. Халыкара сыйнфый көрәш үсешенең төп агымы Көнчыгышны читләтеп узды — Шәрыкта инкыйлаб ясау мәсьәләсе дә бу илләрнең даулы диңгезендә үзләре дә бер тамчы су кебек булган аерым башлар аңында гына яшәде.

Бер яктан, Шәрыкны белмәү һәм, икенче яктан, шул нигездә аннан курку халыкара инкыйлабта Шәрыкның катнашуына бәйле фикерне юк итте.

Шунлыктан халыкара социаль инкыйлаб мәсьәләсендә Көнбатышка гына йөз тоту дөрес түгел иде.

Шунысы бар: Көнбатыш Европа дәүләтләре, аларның союздашы Американы да кертеп, халыкара империализмның барлык матди һәм әхлакый көчләрен туплаган (концентрацияләгән) илләр булып тора. Шуңа күрә, бу яктан алар безнең тарафтан аңа каршы хәлиткеч бәрелеш, сугыш ачарга тиеш төп территория булып тоелса, икенче яктан, без, Көнбатыш Европа буржуазиясен җиңү өчен Көнбатыш Европа пролетариаты үз көче генә дә җитә, дип, берничек тә ышанып әйтә алмас идек, чөнки дөньякүләм, халыкара буржуазия үзен җиңсеннәр өчен халыкара пролетариатның, шул исәптән Көнчыгыш пролетариатының да, революцион ихтыяр көчен һәм революцион энергиясен бергә туплауны таләп итә.

Халыкара империализмга бары тик Көнбатыш Европа пролетариаты аша гына йогынты ясап, без аңа Көнчыгыштагы манёвр-хәрәкәтләренә, эш-гамәлләренә тулы ирек биреп килдек. Халыкара империализм Антанта йөзендә колония итеп Шәрыкны әлегә үз кулында тоткан вакытта, ул аның барлык табигый байлыкларына тулы хокуклы хуҗа булып тора, икътисади нигездәге метрополияләрнең эшчеләр белән аерым бәрелешләре аның өчен уңышлы, җиңү белән бетүенә тулы гарантия бар. Чөнки бу хәлендә ул, аларның икътисади таләпләрен канәгатьләндерергә ризалык биреп, «авызларын томаларга» тулы мөмкинлеккә ия.

Безнең Россия инкыйлабыннан соң ике ел дәвамында бер файдасызга Көнбатыштан революцион ярдәм көтүебез — бу хәлне раслаучы факт.

Хәтта Көнбатыш Европа эшчеләре үз буржуазиясен җиңеп чыккан очракта да, безгә Көнчыгыш белән котылгысыз рәвештә бәрелешергә туры килгән булыр иде, чөнки соңгы очракта Көнбатыш Европа буржуазиясе бәхетсезлек буенча үз «товаркасы» — рус буржуазиясе үрнәгендә, көчләрен үзенең «чикләрендә» һәм, беренче чиратта, Көнчыгышта туплау белән шөгыльләнә башлар иде.

Ул хәтта Көнбатыш Европада социаль инкыйлабны бастыру өчен Шәрыкның йөрәгендә империалистик җәбер идеясен йөртүче булган Европага карата гасырлар буе яшеренеп яткан милли-сыйнфый нәфрәтен файдаланырга да, кара тәнлеләрнең Европага походын оештырырга да оялмас, читенсенмәс иде.

Без моның мөмкин булуын күрсәтеп кенә калмыйча, хәтта шулай булачагына инанабыз, чөнки Россия пролетариатның үз буржуазиясе белән икееллык көрәш тәҗрибәсе бу яктан безне шактый күп нәрсәгә өйрәтте.

III

Шәрыкка социаль-икътисади яктан караганда, ул — тулысынча диярлек Көнбатыш Европа капиталы тарафыннан эксплуатацияләнүче объект, аның сәнәгатенең төп ресурсы булуын күрәбез, һәм бу мәсьәләдә ул үзенең революцион кайнарлыгы, ялкынланып кабынып китә һәм яна алуы мәгънәсендә безнең өчен гаҗәеп бай материал булып тора.

Әгәр Шәрыкның Көнбатыш Европа капиталы тарафыннан эксплуатацияләнү дәрәҗәсен һәм, шуңа бәйле рәвештә, эксплуатацияләүне дәвам итүче Европа белән Американың бөтен масаюлы, кылтый буржуаз мәдәнияте һәм цивилизациясе көчләрен, егәрен булдыруда аның читтән торып катнашу дәрәҗәсен исәпләп чыгарырга мөмкин булса, без «акларның» барлык матди һәм рухи байлыгының иң зур өлеше Шәрыктан таланганын һәм аның барлык төстәге һәм расадагы йөзләгән миллион «туземецлар» хезмәт массалары түккән тир һәм кан хисабына булдырылганын күрер идек.

Бүгенге «прогресс һәм техникалы» «космополитик» мәдәниятле «ирек яратучы» Америка төзелсен өчен дистәләгән миллион Америка аборигены һәм Африка кара тәнлеләре һәлак булырга, җир йөзеннән инкларның бөтен мәдәнияте тулаем юкка чыгарылырга тиеш булды. Американың Чикаго, Нью-Йорк һәм европалаштырылган башка шәһәрләрдә күккә ашкан горур йортлары кешелексез плантаторлар тарафыннан изелгән һәм җәзаланган «кызыл тәнлеләр» һәм негрлар сөякләрендә, шулай ук инкларның җимерелгән шәһәрләренең төтенләп торган хәрабәләрендә төзелде.

Христофор Колумб!.. Европа империалисты йөрәгенә бу исем бик кадерле һәм гаҗәеп күп нәрсә турында сөйли. Ә бит ул Европа ерткычларына Америкага бара торган юлны «ачты». Англия, Франция, Испания, Италия һәм Германия — һәммәсе дә «туземецлар» яши торган Американы талауда, җимерүдә, бар нәрсәне кырып бетерүдә бертигез дәрәҗәдә катнашты, аның хисабына үзенең капиталистик шәһәрләрен һәм буржуаз империалистик мәдәниятен торгызды. Европага Тамерлан, Чыңгыз хан һ.б. монгол кенәзләре ябырылуларының җимерү көче кансызлыгы европалылар үзләре «ачкан» Америкада кылган гамәлләре янында югалып кала.

Мәкаләмнең башында мин әйткән фикер Көнбатыш Европа империализмының алга таба үсеш чоры белән ачык раслана, чөнки ул, «туземецлар» Америкасын бөтен яктан файдаланып һәм туйганчы канәгатьләнеп, тукланып, үзенең бөтен игътибарын дөньяга әлеге империализм «аваз салганның» беренче көннәрендә үк диярлек буйсындыруда көчле теләк уятудан туктамаган Шәрыкка, аның үзәге булган Һиндстанга юнәлде.

Тәре походларының бөтен тарихы һәм алга таба Көнчыгышта узган буржуаз империалистик сугышларның озын тезмәсе Көнбатыш Европа феодаллары һәм аларның варислары тарафыннан Шәрыкны икътисади яктан коллыкка төшерүгә төгәл исәпләнгән, аларга акрынлап тулы уңышка китергән сәясәтне чагылдыра.

Әгәр без бүген Көнбатыш Европа торышын, аның сәнәгатенең Шәрыктагы соңгы үсеш этабында, ягъни Бөтендөнья империалистик сугыш башлану вакытындагы халәтен өйрәнсәк, без бу вакытта Шәрыкның чынлап та халыкара капитал тарафыннан нык изелгәнен һәм аның каты кыскычында тартышып өзгәләнгәнен күрербез.

Бөтен Азия һәм Африка Европа тарафыннан аларның Кытай, Иран һәм Төркия кебек шактый зур дәүләтләренең «мөстәкыйльлеген» бары тик чын булмаган, декоратив тану-

га нигезләнгән кайбер «тәэсир итү даирәләре»нә бүлгәләнгән иде.

Соңгы империалистик сугыш шулай ук әлеге сәясәтнең чагылышы һәм аның кульминация чоры тәгъбире булды, бу вакытта халыкара империализм, үзенең тиздән җимерелүен алдан күреп, үз-үзе белән көрәшкә чыгарга тиеш булды. Хәзерге вакытта, Антанта Германияне җиңгәннән соң, Шәрык мәсьәләсен азмы-күпме хәл итү рәвешен алды кебек: нәкъ менә, Көнчыгышның хуҗасы Антанта була, дигән нигезләмә рәвешендә.

Инде хәзер үк, әлеге әллә ни ачык булмаса да, Шәрыкта бу «изге берлек»нең төп элементлары арасында каршылыклы мәнфәгатьләре булуы күзәтелә башлады һәм шул нигездә иртәме-соңмы халыкларны талаучы Милләтләр Лигасында аңа кергән эре империалистик дәүләтләр аерым конкурентлары арасында беренчелек өчен җитди бәрелешләр булачак.

Бер генә минутка да шуны онытмаска кирәк: бөтен Шәрык Көнбатышның икътисади коллыгында икән, Шәрыкның авыр, катлаулы өлкәсенә моннан ким булмаган «эчке» басымны ясаучы эскәнҗә (пресс) булып аның милли буржуазиясе тора.

Без халыкара социалистик инкыйлабы үсешенең Шәрыкка кагылышлы өлешендә берничек тә Көнбатыш Европа империализмы хакимлеген аннан себереп ату белән генә тәмамланырга тиеш түгеллеген беркайчан да онытмыйк. Ул алга таба да дәвам итәргә тиеш, чөнки бу гамәлләрдән соң Шәрык алдына билгеле бер вакытка кадәр либераль булган, әмма үзенең асылында тупас деспот һәм үз мәнфәгатьләре өчен үзенең артта калган «чит җир» дошманнарына карата позициясен сәгать саен үзгәртеп торырга сәләтле клерикаль-феодаль буржуазияне бәреп төшерү мәсьәләсе — гаҗәп катлаулы мәсьәлә килеп баса.

Без бер нәрсәне нык итеп һәм мәңгегә истә калдырырга тиешбез: Көнчыгыш — нигездә халыкара империализмны тукландырып торучы төп чыганак һәм шул мөнәсәбәттә бөтендөнья социалистик гражданнар сугышы шартларында безнең өчен ул чиксез файдалы, ә халыкара империалистлар өчен безнең алар белән бәрелешүдә чиктән тыш файдасыз фактор булып тора. Көнчыгыштан колак каккан, Һиндстан, Әфганстан, Ираннан һәм башка Азия, Африка колонияләреннән аерылган Көнбатыш Европа империализмы хәлсезләнергә һәм үзенең табигый үлеме белән юкка чыгарга тиеш булачак.

Әмма шул ук вакытта Шәрык — деспотизм бишеге, һәм шуңа күрә без, Көнбатыш Европа империализмыннан азат булганнан соң, анда әлегә үзенең Европа туганының авыр эскәнҗәсе астында баш күтәрә алмый торучы Шәрык империализмы тергезелмәс, дип ышанып әйтә алмыйбыз. Әле безнең ярдәм белән чит ил изүеннән котылган Кытай, Һиндстан яки Төркия белән Иран феодаллары, империалистик Япония һәм Европаның тагын берәрсе белән кушылып, берләшеп, үзләрен «азат итүчеләргә» «большевизм» дигән йогышлы чирдән котылу өчен поход оештырмас, дигән гарантия дә юк безгә.

1919 ел.

Чыганак
Мирсәет Солтангалиев. Сайланма хезмәтләр. — Казан: «Гасыр» нәшрияты, 1998. — 198-203 битләр.

Флёра Тарханова тәрҗемәсе

МИРСӘЕТ СОЛТАНГАЛИЕВ – МИЛЛИ КАҺАРМАНЫБЫЗ

(«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»)

«Чын мирас» журналы редакциясе, 2012 ел, 25 июнь

Катнашалар: **ИНДУС РИЗАК УЛЫ ТАҺИРОВ** — *тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы;* **ИЛДУС КОТДУС УЛЫ ЗАҺИДУЛЛИН** — *тарих фәннәре докторы, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының урта гасырлар тарихы бүлеге мөдире;* **ДАНИЯР РӨСТӘМ УЛЫ ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ** — *тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү үзәге өлкән фәнни хезмәткәре;* **ИЛФАК МИРЗА УЛЫ ИБРАҺИМОВ** — *«Чын мирас» журналының баш мөхәррире.*

И.М.Ибраһимов. XX гасыр башында Россиядә зур үзгәрешләр башлана. Менә шундый зур вакыйгалар чорында һәр милләтнең лидеры, аның җитлеккән көрәшчесе ничек барлыкка килә. Сез бу турыда ниләр уйлыйсыз? Мирсәет Солтангалиевнең шәхес буларак революцион хәрәкәткә килеп керүе аның өчен тарихи яктан котылгысыз булганмы?

И.Р.Таһиров. XIX-XX гасыр чикләрендә татар дөньясы яңарыш кичерә. Гаҗәеп могҗиза бит татар яңарышы. Татар халкының барлык яшәеш өлкәләрендә өр-яңа күренешләр пәйда була: әдәбияты — менә дигән әдәбият, дистәләрчә язучылар, дистәләрчә журналистлар аваз сала, утыздан артык газета-журналлар берничә ел эчендә басыла башлый. Милли театрыбыз барлыкка килә. Гомумән, искиткеч алгарыш күзәтелә. Бер газетада язалар: «Татар халкы үзенең кабереннән торып, өстеннән туфрагын кагып төшерде һәм тарих мәйданына чыкты». Һәм шушы милләттә яшь әйдәманнар пәйда була. Әйтик, Мулланур Вахитов. Араларында социал-демократлар да, социалист революционерлар да — төрле мәсләктәге кешеләр булган. Әлбәттә, татарлар шушы чорда барлыкка килгән социализм шаукымына кушылмый булдыра алмыйлар. Ни өчен дигәндә, социализмны баштарак азатлык байрагы кебек кабул итәләр. Мәҗит Гафурины гына алып карагыз. «Кызыл байрак» шигырендә ул болай дип яза:

Кара син алга, барамын алга,
Кызыл байракны күтәргән
анда эшчеләр.

Шул ук вакытта социализм байрагы исеме астында Мәҗит Гафури милли үсешне беренче урынга чыгара. Татарлар социализм ярдәмендә гасыр-

лардан килгән торгынлыктан котылу мөмкинлеген эзли.

Мәҗит Гафуриның тагын шундый сүзләре бар:

Бер адым алга басам да,
Борылам мин артыма,
Кайда бастылар икән, дип,
Күз саламын халкыма.

Солтангалиев тә шундыйлардан. Юкка гына Солтангалиевне дә, Мулланур Вахитовны да кызыл панисламистлар дип атамыйлар. Мулланур Вахитов үзен турыдан-туры кызыл панисламист, дип белдерә. Социализмга алар безне азатлыкка илтә торган тәгълимат итеп карыйлар.

Ул чор күпләр өчен зур мөмкинлекләр тудыра. Ләкин мөмкинлекне тормышка ашыру өчен, әле тагын шартлар кирәк. Кешенең шәхси өлгергән булуы иң беренче нәүббәттә тора. Мирсәет Солтангалиев иҗтимагый мәйданга шәхес булып өлгереп чыга. Ни өчен дигәндә, ул укытучы гаиләсендә туа. Яхшы белем ала. Бәләбәй китапханәсендәге бөтен китапларны укып чыга. Әлбәттә, аның беренче танышлары социалистлар була. Ул чакта социализмның шаукымы көчле, хәтта аның нәрсәгә китерәчәген белмәсәләр дә, якты киләчәккә илтәчәк байрак итеп ышанып карыйлар. Солтангалиев шул социалистларга иярә. Ул да социализм татарны, Шәрык халкын коллыктан чыгарырга тиеш дип уйлый.

Һади Атласи Солтангалиевкә әйтә: «Синең кебек кешеләр алар — ярым социалист, ярым милләтче». Чыннан да, аларның бер күзе социализмга, бер күзе милләткә текәлгән була.

Шулай ук татар социалистлары арасында ике төрле караш хасил була. Берсе — сыйнфый караш: Мулланур Вахитовта сыйнфыйлык көчле. Солтангалиевтә дә баштарак ниндидер рәвештә сыйнфый караш яши. Ә Фуат Туктаровта киресенчә. Фуат Туктаров «Корылтай» исемле газетада: «Без — татарлар — шушындый чорда бүленеп, таркалып яшәргә тиеш түгел. Без большевик та түгел, без социалист та түгел, без — татарлар», — дип яза. «Берләшик!» дигән лозунгны күтәрә.

Солтангалиевтә шушы ике төрле караш көрәшә башлый. Большевиклар хакимиятне үз кулларына алгач, ул большевиклар алдыйлар, боларга ышанып булмый, дигән фикергә килә. Бу сүзләрне ачы тәҗрибәдән чыгып әйтә. Мулланур Вахитов 1918 елның августында һәлак булгач, аның урынына Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариатының җитәкчесе булып Солтангалиев билгеләнә. Хәрби мөселман коллегиясен дә ул җитәкли. Шул вакытта гыйбрәтле бер вакыйга була — башкорт гаскәрен большевиклар ягына күчерү вакыйгасы. Башкортлар, башка халыклардан аермалы буларак, үзләренең гаскәрен төзиләр. Ә безнекеләр, ни кызганыч, әзер гаскәрдән дә файдалана алмыйлар. Зәки Вәлиди бу өлкәдә күбрәк эшләгән. Чөнки аның максаты «кем безнең автономияне таный, без шуның белән», дигән принципка корылган була. Большевиклар 1917 елның декабрендә оешкан республиканы танымыйлар, шуңа башкортлар Дутов ягында калалар.

Большевиклар Колчак гаскәрен таркатуны бурыч итеп куялар. Шушы юлның берсе — башкорт гаскәрен Советлар ягына күчерү. Бу хәтәр эштә төп рольне Солтангалиев һәм Ильяс Алкин — Зәки Вәлиди гаскәренең штаб начальнигы — башкаралар. Большевиклар башкорт гаскәрен 10 нчы армиягә кушарга боералар. Солтангалиев, куркынычсызлык мак-

сатында, сер таралмасын өчен, башкорт гаскәрен 2 нче армиягә куштыра. Шушы вакыйгадан соң большевиклар Солтангалиевкә ышанмый башлыйлар. Партия җитәкчелегендә «ул милләтчеләр белән, Зәки Вәлиди белән элемтәдә икән», дигән фикер туа. Аны эзәрлекләү башлана. Ә Солтангалиевнең большевикларга ышанычы кимегәннән-кими бара. Шул ук 1919 елны «Жизнь национальностей» газетында аның мәкаләсе дөнья күрә. Автор анда үзенең марксизм тәгълиматы белән килешмәвен белдерә. Пролетариат диктатурасы теориясенең тамырдан дөрес түгеллеген, Ленинның милли колониаль изү турындагы тәгълиматы дөреслеккә туры килмәвен ачыктан-ачык әйтә: «Шәрык халыкларында социалистик революция була алмый, Шәрык халыклары бүген күтәрелештә, киләчәк — Шәрык кулында», — дип яза.

И.К.Заһидуллин. XX йөз башында татар җәмгыятендә күп яңалыклар күзәтелә. Иң мөһимнәре: европалашу, җәдитчелек фикере таралу, рус мәдәнияте йогынтысы көчәю. Мирсәет Солтангалиев, Мулланур Вахитов, Хөсәен Ямашев кебек шәхесләр — шушы күренеш вәкилләре.

Солтангалиевнең әтисе татар һәм башкорт мәктәпләрендә рус теле укыта. XX гасыр башы татар зыялыларыннан аермалы буларак, ул мәдрәсәдә укымаган, белемне әтисеннән алган. Индус Ризакович әйткәнчә, үзлегеннән бик күп русча китаплар белән танышкан.

Шулай итеп, XX гасыр башында мәдрәсәләрдә белем алмаган татар яшьләре буыны пәйда була. Алар рус мәдәнияте белән кызыксыналар, яшьләр арасында бик популяр булган социалистик идеяләр белән мавыгалар. Гасыр башында Казан татар укытучылар мәктәбенә туган телен белмәгән яки онытa башлаган яшьләр укырга килә башлый. Солтангалиев шушы мохиттә формалаша. Аның үзенә күрә аралашу даирәсе дә булгандыр. Ни хикмәт, шундый актив шәхес булса да, Казанда укыган чорда аның татар вакытлы матбугатында басылган мәкаләләрен әлегә белмибез.

Күрәсең, рус мәдәнияте йогынтысында Солтангалиев социалистик идеянең дөреслегенә ышанган. Әлбәттә, аның яшьлек максимализмын да исәпкә алырга кирәк.

И.М.Ибраһимов. Индус Ризакович, Сез Зәки Вәлидинең максаты милли республика төзү, дип ассызыкладыгыз. Солтангалиевнең, революцион фикер иясе һәм партия функционеры буларак, милләтләрнең үз дәүләтчелеген төзүенә бәйле карашларына һәм эшчәнлегенә нинди бәя бирәсез?

И.Р.Таһиров. Солтангалиевнең мәкаләләрендә милләтне ничек тә коллыктан йолкып алырга, дигән фикер ярылып ята. Ул милли идеяне революциягә ияреп кенә тормышка ашырып була дип саный. Дөнья купкан вакытта татар өчен, Шәрык халыклары өчен дөрес юлны ничек сайларга? Пролетариат диктатурасы дөрес түгел. Капиталистик диктатура урынына пролетариат диктатурасы урнаша икән, ул Шәрык халыклары өчен барыбер начар булачак: чөнки коллыктан азат итми. Шуның өчен Шәрык халыклары үз язмышларын үзләре хәл итәчәк — бередә тиздән милли азатлык революциясе булачак, дип яза Солтангалиев. Алар күтәрелештә, ә Көнбатышта мондый күтәрелеш күзәтелми, дип белдерә.

Д.Р.Гыйльметдинов. Мин югары уку йортында Татарстан тарихын укытам. Бик еш кына студентларга сорау куям: ислам һәм православиенең социаль планда нинди сыйфатларын беренче урынга куярга мөмкин. Бу сорауга үзем болай җавап бирәм: исламда — гаделлеккә, православиядә — гадилеккә омтылыш. Безнең шартларда бу ике сыйфат бер-берсе белән бәйләнештә. Гаделлек һәм тәртиплелек Солтангалиев теориясендә зур урын били. Бу сыйфатлар мисалында Солтангалиевнең ислам динен һәм социалистик идеяне ничек аңлавы да ачык күренә.

Солтангалиевнең концепциясе бүгенге көндә яшәп килүче берничә теориянең чишмә башы дип санала ала. Шуларның беренчесе итеп Мисырдагы «Бертуган мөселманнар» хәрәкәтенең карашларын атар идем. Икенчесе — Америкада яшәп иҗат иткән зур галим Эдвард Саид теориясе. Аның «Ориентализм. Западные концепции Востока» исемле китабындагы төп тезисларның берсе: Көнбатыш Көнчыгышны объектив рәвештә аңларга җыенмый дигән фикер. Өченче зур теория — С.Хантингтонның «салкын сугыш» чоры тәгәлләнгәннән соң цивилизацияләр бәрелешү вакыты киләчәге турындагы карашлары.

Индус Ризакович дөрес әйтте: Солтангалиев ул — социалист-панисламист. Солтангалиев татарлар һәм башкортлар дигән сүзләр урынына һәрвакыт мөселманнар дигән термин куллана. Ул Үзәк мөселман комиссариаты исемен Үзәк татар-башкорт комиссариаты итеп үзгәртүгә каршы чыга. Чөнки татарлар һәм башкортлар — Россиядә ислам тарафдарлары, аларның уй-фикерләре исламның дәрәҗәсен күрсәтә, дип санаган. Әлбәттә, Солтангалиев исламга дин буларак түгел, ә, беренче чиратта, мәдәни мирас итеп караган, аны шулай бәяләгән.

И.М.Ибраһимов. Без хәзер ислам мәдәнияте нигезендә берләшкән җәмгыять моделе, христиан кыйммәтләренә таянып берләшкән җәмгыять моделе, дип сөйлибез. Әле тагын Кытай, Һиндстан цивилизацияләре үрнәкләре һ.б. бар. Солтангалиев кешелек дөньясының киләчәген ничек күргән? Татарларның киләчәген ул мөселман цивилизациясе моделе үрнәгендә күргәнме? Идел-Урал штаты нинди дәүләт булыр дип күзаллаган?

И.Р.Таһиров. Ни кызганыч, Солтангалиевнең иң зур хатасы, Мулланур Вахитов белән бергә, шушы Идел-Урал штатына каршы чыгу була. Идел-Урал штаты идеясен большевиклар үзләренә каршы хәрәкәт дип кабул иткәннәр. Ни өчен дигәндә, большевиклар, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын телдә танысалар да, нигездә аңа каршы чыкканнар. Алар милләтләрнең статусын өстән билгеләүне максат итеп куйганнар. Ә Идел-Урал штаты безнең милләтебезнең үзбилгеләнү хокукын тормышка ашырган. 1918 елның 28 февралендә кабул ителергә тиешле Идел-Урал штатын булдырмас өчен, Мулланур Вахитов Мәскәүдән Казанга матрослар отряды җибәрә. Казанда, Х.Урманов дигән кеше житәкчелегендә, берничә кораллы кызылармеец Алкинны фатирында кулга алалар. Шулай ук Икенче Бөтенроссия мөселман хәрби съездының башка җитәкчеләре дә сак астына алына. Кулга алып, аларны шушы идеядән баш тартырга мәҗбүр итәләр. Бер үк вакытта, Идел-Урал штаты идеясен юкка чыгару өчен, Татар-башкорт республикасы идеясе

барлыкка килә. Бу — өстән төшкән идея. Кайберәүләр ике проект арасында аерманы күрми, республикаларның территорияләре бер үк, хокуклары да тигез, дип санийлар. Ләкин бер үк түгел шул. Беренчесе халыкның үзбилгеләнү хокукын тормышка ашыруны аңлата, икенчесе — Мәскәүдән бирелгән декрет. Ул декретны юкка чыгарып була, һәм большевиклар шулай эшләделәр дә. Ә менә үзбилгеләнү хокукын тормышка ашырган халык белән исәпләшмәү авыррак. Шуны аңламау күзәтелә. Шул исәптән, Солтангалиевтә дә. Солтангалиев, Шамил Госманов соңыннан бу эшләре өчен үкенәләр, зур хата җибәргәнлекләрен таныйлар.

Ул вакытта халык арасында татар большевикларына карата тискәре караш күзәтелә. «Алтай» газетасының 1918 ел 28 апрель санында Вахитовка, Идел-Урал штатын бетерүче дип, бик каты бәреләләр, аңа янаулар була. Янауларның бер өлеше Солтангалиевкә, бер өлеше Галимҗан Ибраһимовка да карый. Чөнки Галимҗан Ибраһимов — Татар-башкорт Республикасы идеясенең авторы. Ләкин Ибраһимов, калганнардан аермалы буларак, Татар-башкорт республикасын Идел-Урал штатына каршы куймый.

Ул вакытта әлеге хата эшләнмәгән булса, тарих икенче төрле юл белән китәр иде. Бу вакытта Казанда 95 нче мөселман полкы, күпчелеге безне яклаган чувашлардан торган 164 нче полк тора. Уфада 144 нче мөселман полкы боерык көтә. Менә шушы хәрби көчләр барысы да Алкинга буйсына. Татарлар шушы форсаттан файдаланмыйлар. Тәвәккәллек җитми. Бусы — бер яктан. Икенче яктан, Советлар тарафыннан Идел-Урал штаты төзү омтылышына балта чабыла. Солтангалиевнең бу гамәлен, хатасын күпләр гафу итә алмый.

И.М.Ибраһимов. Бу Солтангалиевнең фаҗигасеме?

И.Р.Таһиров. Әлбәттә, шулай.

И.К.Заһидуллин. Чыннан да, Идел-Урал штаты юкка чыгуны хаклы рәвештә зур югалту дип кабул итәбез. Тарихи хезмәтләр шартлы фигыль формасын яратмаса да, Идел-Урал штаты оешкан, дип фараз кылдык ди.

1920-1930 еллардагы Совет федерациясе төзелүне искә төшерик әле. Большевиклар аны барыбер тараткан булырлар иде. Ул елларда милләтләрне бүлгәләү, аз санлы халыкларга да автономия хокуклары бирү сәясәте алып барыла. Әйтик, Идел буенда кайбер милли республикалар татарларның, ТАССРның йогынтысын киметү өчен махсус оештырыла. Сталин, Идел-Урал штатында булган удмурт, мари, чувашларга мөстәкыйльлек «бүләк итеп», аларга автономияле республикалар төзергә рөхсәт биргән декрет язып, барыбер Идел-Урал штатын таркатыр иде. Бер сүз белән, әйткәндә, илдә барган сәяси барыштан Идел-Урал штаты гына читтә кала алмас иде.

Югалтулар зур булса да, ул тарихи вакыйгалардан безгә гыйбрәт алырга, дөрес нәтиҗәләр ясарга кирәк. Шунысы белән ул ялгышлар безнең өчен бик мөһим. Киләчәктә, мөмкинлек туганда, бу хаталарны исәпкә алып хәрәкәт итү сорала.

Д.Р.Гыйльметдинов. Мин Ленин һәм башка большевик җитәкчеләрне практиклар, гамәли эш кешеләре, ә Г.Ибраһимовны һәм М.Солтангалиевне романтик шәхесләр, каһарманнар, дип әйтер идем. Чөнки алар исламны да, социализмны да үзләренчә аңлаганнар. Алар икесе дә гаделлек, тигезлек турында — кешеләр һәр заманда хыялланган кыйммәтләр турында сөйләгәннәр.

И.М.Ибраһимов. Мирсәет Солтангалиев федерализм тарафдарымы? Аның фикерләренең кайсылары бүгендә әһәмиятләрен югалтмаган?

И.Р.Таһиров. Мирсәет Солтангалиев чын мәгънәсендә федералист булып өлгерә. СССР төзелгән вакытта ул дәүләттә берничә федерация, шул исәптән төрки халыклар федерациясе дә булырга тиеш, дип саный. Ни өчен Кавказ халыклары өчен федерация төзисез, ә төрки халыкларга шуны тыясыз, дип ачынып яза. Шушы максатны ул һаман алга сөрә. 1918 елны, 1919 елны да большевиклар Солтангалиевкә әле күпмедер дәрәҗәдә ышанганнар. Ләкин Солтангалиевнең большевикларга ышанычы бетә. Башкорт гаскәре советлар ягына Башкорт республикасын тану шарты белән күчерелгән була. Бу хакта килешү төзелә. Килешүдә Башкортстан чит илләр белән мөнәсәбәтләр кора ала, үзенең гаскәрен тота ала, эчке эшләр тулысы белән аның кулында, кебек киң хокуклар беркетелә.

Ундүрт айдан соң шушы килешүне большевиклар берьяклы рәвештә юкка чыгаралар. Зәки Вәлиди Лениннан: «Ни өчен болай булды?» — дип сорый. Ленин: «Бу килешү кәгазь генә бит», — дип җавап бирә. Шуннан соң Зәки Вәлидинең дә, Солтагалиевнең дә большевикларга ышанычы бетә.

Солтангалиевне Төньяк Кавказ республикалары федерациясен төзү комиссиясе рәисе итеп билгелиләр. Ул бу халыкларның җитәкчеләренә Үзәктән Татарстан республикасыныкын түгел, Башкортстан Республикасына бирелгән хокукларны таләп итәргә киңәш бирә. Мондый гамәлләре большевиклар һәм Сталинның нәфрәтен уята. Чөнки большевиклар өчен бу мөмкин хәл түгел: 1919 елда ук, VIII съездда алар милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын уен дип таныйлар. Бу уенны туктатырга кирәк, без аны тактика рәвешендә, кирәк булганга гына кабул иттек, диләр. Сталин 1922 елның 22 сентябрендә Ленинга язган хатында бу уенны туктатыйк, әгәр дә вакытында туктатмасак, соң булачак, дип билгели.

Менә шушы рәвештә СССР төзелә, Солтангалиевнең бер генә тәкъдиме дә кабул ителми. Дөресен әйтергә кирәк, Солтангалиев Кавказ, Төркестан республикалары җитәкчеләрен үз ягына тартырга тырыша: ләкин алар куркалар, Солтангалиев артыннан иярмиләр. Бердәм чыгыш ясаган булсалар, бәлки, СССР башка рәвештә төзелгән булыр иде.

1924 елда Солтангалиев болай дип яза: «СССР рәвешендә төзелгән Россиянең гомере кыска булыр — ул таркалачак, чөнки панрусистлар республикаларның хокукларын бөтенләй бетерергә омтылалар». Аның фаразы дөрес булып чыкты. Солтангалиев федерацияне чын мәгънәсендә тулы хокуклы милләтләрнең берлеге итеп таный. Большевиклар исә аңа уен, шушы уен аша унитар дәүләт оештыру юлы итеп карыйлар. Республикаларны бетереп, Россияне унитар дәүләт ясау өчен тырышалар.

Бүгенге көндә без нәрсә күрәбез? Бүген чын федерация бармы? Бүген дә уен бара. Ленин бит акыллы кеше булган. Ул федерациядән бөтенләй баш тартып булмасын аңлаган. Ләкин федерация исемен илгә кертеп, ә җисемен ишек артында калдырган. Бу нәрсә дигән сүз? Федерация игълан ителә, ил белән унитар рәвештә большевиклар идарә итә. Чөнки үзәкләштерелгән централизм — большевикларның беренче принцибы. Гомумән, дәүләт түгел, партия идарә итте бу ил белән.

И.К.Заһидуллин. Әлбәттә, большевиклар һәм милли лидерлар еш кына бер үк сүзне сөйләгәннәр, ләкин һәрберсе аны үзенчә аңлаган. Большевиклар милләтләрнең үзбигеләнү хокукын тактика рәвешендә кулланмасалар, Россия таркалыр, аны җыеп булмас иде. Большевиклар унитар дәүләт төзергә омтылалар, ләкин булдыра алмыйлар: чөнки халык һәм милли лидерлар үз таләпләрен куялар. Большевиклар бик зур көч һәм тырышлык салып кына дәүләтне СССР рәвешендә оештыра алдылар. Халыкларның теләкләрен өлешчә, күпмедер дәрәҗәдә исәпкә алып һәм аларны алдап шушы килешүгә ирештеләр. СССР — 1922 елгы килешү формасы ул. Россия Федерациясе дә — шундый ук килешү формасы. Ләкин шунысын онытмаска кирәк: бүген милли республикалар моделе артында меңләгән кешеләрнең үз халкы киләчәге хакындагы уй-хыялы, фикере тора.

Бер сүз белән әйткәндә, Солтангалиевнең СССР төзелү чорында башкарган эшләре дә, аның теориясе дә чынбарлыкка таянып эшләнгән.

Д.Р.Гыйльметдинов. Безнең илдә демократия һәм федерализм булсын өчен әле күп тырышлык куярга кирәк. Солтангалиев теориясе изелгән халыклар өчен зур хыял булып калган һәм киләчәктә дә шулай булып калачак. Солтангалиев «кара интернационал» (Англия, Франция һәм аларның колонияләре күздә тотыла) дигән термин керткән, шуңа мөселман һәм көнчыгыш илләрен каршы куйган. Солтангалиев уйлавынча, мөселман халыклары, дин уртаклыгы нигезендә берләшеп, социалистик интернационалга берләшү мөмкинлегенә ия. Бу фикер Солтангалиев концепциясенең үзәк өлешен алып тора.

И.М.Ибраһимов. СССР буларак төзелгән дәүләт моделенең чарасызлыктан оешканлыгы аңлашыла. Россия халкының, татарларның киләчәге нинди? Бу уңайдан бүген Солтангалиевнең нинди фикерләре әһәмияткә ия?

И.Р.Таһиров. Солтангалиев, СССР таркалгач, милли дәүләтләр оешыр, дип күзаллый, Туран идеясен — төрки халыкларны борынгы ватаннары исеме белән берләштерү идеясен күтәрә, ләкин бу идея тормышка аша алмый. Соңрак моны Солтангалиев үзе дә таный, төрки халыкларның бердәм дәүләте тиз генә оешмаячагына инана, ләкин татар белән башкорт һәрвакыт бергә үсәргә тиеш, дип яза. Татарстан республикасы составына керергә тиешле Бәләбәй һәм Бөре өязләре дә читтә калгач, ул моңа вакытында зур әһәмият бирми. Башкортстан һәм Татарстан киләчәктә бер булачаклар, дип исәпли.

Солтангалиев милләтләр, һичшиксез, үзләренә азатлык яулап алачаклар, дип белдерә. Кытай ирек алды, Һиндстан ирек яулады. Төркиянең алдынгы дәүләт булачагын күрсәтә. Барысы да ул язганча булды. Әлбәттә, без дә — татар-башкортлар — киләчәктә дәүләтле халык булачакбыз. Мин аның шушы идеясенең дөреслегенә ышанам.

И.К.Заһидуллин. Мирсәет Солтангалиевнең ялгышларының берсе — Россиядәге татарны, башкортларны метрополия колонияләрендәге халыклар белән янәшә кую. XIX гасырда Идел буе, Урал төбәге Россиянең тулы мәгънәсендә колониясе булмаган. Бу чорда колония дип Төркестанны атарга була. Татарлар империя сословияләренә кергән, төбәкләр илдәге икътисади үсеш барышы кысаларында яшәгән: алар промышленность үзәкләре белән чагыш-

тырганда шактый артта калган булса да, тимер юллар төзелгән, башка капиталистик үзгәрешләр күзәтелгән. Әлбәттә, төбәктә хакимият рус чиновниклары кулында булган.

И.Р.Таһиров. Россиядә рус булмаган халыкларны «инородец» (чит кавем) дип йөрткәннәр. Татар белән башкорт беркайчан да, бер билге буенча да руслар белән тигез кабул ителә алмаган. Мин Идел-Урал төбәген «йотылган рәвештәге колония» дип саныйм. Бүгенге көнне колонияне кире кысып чыгардык. Чөнки суверенлык турында декларация кабул иттек. Аны төрлечә бәялиләр. Декларациядән бернәрсә дә калмады, диючеләр дә бар. Әмма декларацияне, безнең референдум нәтиҗәләрен кемнең инкарь иткәне бар? Референдум алдыннан булган Югары Совет сессиясендә Конституцион судның рәисе Зорькин әйтә: «Если на референдуме на поставленный вопрос будет дан положительный ответ, то это будет юридической основой для провозглашения независимости. Каждый юрист будет так считать и будет прав», — ди.

Мәскәү белән төзелгән соңгы Шартнамәбез шушы референдумнан чыгып әзерләнде. Референдум, Зорькин әйткәнчә, үзенең кыйммәтен саклый бирә.

И.М.Ибраһимов. Мирсәет Солтангалиевнең исеме һәм хезмәтләре әле соңгы егерме елда гына халыкка кайтарыла башлады. Индус Ризакович Таһировның Мирсәет Солтангалиевкә багышлап 1989 елда басылган беренче мәкаләсеннән соң мәшһүр шәхесебезнең исемен, мирасын илдә таныту өчен зур эшләр башкарылды. Күпсанлы мәкаләләр дөнья күрде, аңа кагылышлы документлар җыентыклары укучыларга барып иреште: «Султан-Галиев М. Статьи. Выступления. Документы» (Казан, 1992), «Тайны национальной политики» (Мәскәү, 1992), «Неизвестный Султан-Галиев» (Казан, 2002), «Мирсәет Солтангалиев: сайланма хезмәтләр» (Казан, 1998) һ.б. «Гасырлар авазы» журналы бу темага даими игътибар биреп килә. Р.Мөхәммәдиевнең Солтангалиевкә багышланган романы дөнья күрде. Сез аның мирасын өйрәнгәндә нинди чикләүләргә очрадыгыз? Солтангалиев турында нинди яңа китаплар, монографияләр бастырып чыгару планлаштырыла?

И.Р.Таһиров. Мирсәет Солтангалиев темасын өйрәнү өчен юллар ачык. Солтангалиев кулга алынганнан бирле, 1923 елдан 1938 елга кадәр әзәрлекләнә. 1940 нчы елны атып үтерелә. Бүгенге көндә аның шактый хезмәтләре, аннан сорау алу материаллары, сорауларга нигезләнгән җаваплары фәнни материал булып тора. Чөнки ул, кыйнауга, җәберләүләргә карамастан, бирелгән сорауларга нигезле җаваплар язган. Хаталарын таныган сыман, үзенең хаклыгын да исбатлаган. Менә шушы материалларны акрынлап бастырачакбыз. Бер-ике томы инде әзерләнде. Аннан соң башка томнарга күчәчәкбез.

Боларны дөньяга чыгарырбыз. Монда бит тагын шушы материалларны халыкка җиткерү мәсьәләсе бар. Бөтенегез дә яхшы беләː теория халык массаларының аңын яулап алганда гына зур көчкә әверелә. Безгә әле Солтангалиевнең хезмәтләрен, тарихыбызны пропагандалау җитми. Халык китап укымый, дибез. Халык укый торган китаплар язарга кирәк. Бигрәк тә балалар өчен яңа китаплар язу әһәмиятле. Ул китапларда Солтангалиев һәм башка милли каһарманнарыбызның газиз халкы өчен көрәше һәм тормыш юлы яктыртылырга тиеш. Безгә бүген мил-

ли горурлыкны кайтарырга кирәк. Милли горурлыгыбыз кайтса, бар да булачак.

И.М.Ибраһимов. Ялгышлары булуга карамастан, Мирсәет Солтангалиев безнең милли каһарманыбызмы?

И.Р.Таһиров. Солтангалиев — бөек шәхес, һичшиксез, милли каһарманыбыз. Чөнки аны дөнья таный. Аның тәгълиматы дөнья масштабында тормышка ашкан. Мао Цзэдун кебек шәхесләр Солтангалиевне үзләренең юлбашчысы итеп санаган.

И.К.Заһидуллин. Берничә ел элек Гиссен университеты профессоры Марк Кирхнер белән Казан Кремлендәге «Татар һәм Татарстан дәүләтчелеге тарихы» музеенда булганда, алман галиме стенадагы фотосурәткә күрсәтеп: «Мин бу кешене беләм. Бу — Мирсәет Солтангалиев. Безгә мәктәптә аның метрополияләр һәм колонияләр мөнәсәбәте турындагы концепциясен укыттылар», — диде. Кирхнерның элеккеге көнбатыш Алмания территориясендә үскәнен исәпкә алганда, бу гаҗәеп тоелды. Без: «Бутамыйсызмы, бәлки, югары уку йортында танышкансыздыр», — дип кайтарып сорадык. Марк Кирхнер исә үз фикерендә калды. Ә бит мәктәп дәреслекләрендә кешелек тарихы үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр хезмәтләре һәм карашлары гына урын ала. Чыннан да, Мирсәет Солтангалиевнең концепциясе кешелек җәмгыяте үсеше турында яңа сүз булды.

Аның халыкара мөнәсәбәтләр тигез хокуклар нигезендә корылырга тиешлеге, башкача булганда метрополияләр зур югалтуларга дучар булачагы турындагы фикерләре искермәгән. Индус Ризакович бик дөрес әйтте. Аның фикерләре ватаннарының азатлыгы турында хыялланган һәм көрәшкән милли лидерлар өчен өстәл китабы булган һәм булачак. Мирсәет Солтангалиевнең хезмәтен империализм, метрополия вәкилләре дә ныклап өйрәнгәннәр, бигрәк тә язганнары рас килә башлагач, чигенергә юллар ясар өчен.

Шуңа күрә үзеннән-үзе «Мирсәет Солтангалиев фикерләренең XX гасырда халыкара мөнәсәбәтләргә тәэсире» дигән бик мөһим тема калкып чыга. Бу теманы халыкара грант алып, берничә ил галиме берләшеп эшләсә, нәтиҗәсе матур булыр иде. Солтангалиев — XX гасыр шәхесе.

И.Р.Таһиров. Һәм XXI гасырга килеп кергән шәхес. Аның фикерләре бүген дә бик актуаль.

Д.Р.Гыльметдинов. Без Россиядә федерализм юлын нан барырга әзерләнәбез генә. Шуңар Солтангалиев фикерләре дә, аның эшчәнлеге дә бик мөһим.

И.Р.Таһиров. Барлык күренекле шәхесләрнең дә хаталары бар. Хаталар Маркста да, Энгельста да, Ленинда да, Солтангалиевтә дә, Госмановта да булган. Хаталар бар һәм булачак, ләкин шушы хаталар аркылы максатыбызны билгеләп, шуңа юнәләбез икән — без дөрес юлда. Шушы юлны ачучыларның берсе XXI гасырга безнең белән килеп кергән бөек шәхесебез Мирсәет Солтангалиев булды.

И.М.Ибраһимов. Күрәбез, бүген дә Мирсәет Солтангалиевнең фикерләре Россия Федерациясе өчен дә, дөнья җәмәгатьчелеге өчен дә кыйммәтләрен югалтмаган. «Чын мирас» журналы редакциясе Сезгә, хөрмәтле тарихчылар, киләчәктә дә халкыбызның үткән тормышын, мәдәни мирасын өйрәнүдә яңа уңышлар тели һәм киләчәктә дә сезнең белән хезмәттәшлек итәргә ниятли. Барыгызга да зур рәхмәт!

КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ЭТНОКОНФЕССИОНАЛЬ ГРУППАСЫ ОЕШУ КАТЛАУЛЫ ВАКЫЙГАЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ. БҮГЕН ТАРИХ ФӘНЕНДӘ КАЛЫПЛАШКАН КОНЦЕПЦИЯ БУЕНЧА, КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ЭТНИК НИГЕЗЕН XVI-XVIII ГАСЫРЛАРДА ТӨРЛЕ СӘБӘПЛӘР БЕЛӘН ПРАВОСЛАВИЕ ДИНЕН КАБУЛ ИТКӘН ТАТАРЛАР ТӘШКИЛ ИТӘ. ХӘЗЕРГЕ КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫ ОЕШУДА ТӨБӘКТӘ ЯШӘГӘН ФИН-УГЫР (УДМУРТ, МАРИ, МОРДВА) ҺӘМ ТӨРКИ (ЧУВАШ) ХАЛЫКЛАРЫ ДА ҮЗ ӨЛЕШЛӘРЕН КЕРТКӘН, АЛАРНЫҢ МАТДИ ҺӘМ РУХИ МИРАСЛАРЫНА СИЗЕЛЕРЛЕК ЙОГЫНТЫ ЯСАГАН.

XIX ГАСЫР УРТАСЫНДА КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ САБАНТУЙ БӘЙРӘМЕ

РАДИК ИСХАКОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты
Керәшен татарлары һәм нугайбәкләр тарихын һәм
мәдәниятен өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре

Христиан динен кабул иткәнче, бүгенге керәшен татарларының ерак бабаларыннан күбесенең мөселман булуларын инкарь итмичә (моны тарихи чыганаклар һәм кайбер төбәкләрдә яшәгән керәшен татарларының ислам диненә бәйле дини йолалары раслый), ул чорда аларның исламлашуы бик түбән дәрәҗәдә булганын әйтеп үтәргә кирәк. Керәшен татарларының рухи мирасы, диннәре Евразиядәге борынгы төрки халыкларның исламгача булган космополитик карашлары белән үрелеп барган традицион кыйммәтләр системасына нигезләнгән.

Мөселманнар һәм христианнар белән озак вакыт янәшә тормыш итүгә һәм хуҗалык мөнәсәбәтләре урнашуга карамастан, халык традицияләренә нигезләнгән дин керәшен татарларының үзенчәлекле мәдәниятен саклап калуга юнәлдерелгән булган. Дини күзаллаулар системасының һәрбер элементы: кешедән югары көчләр, микро- һәм макрокосмос, аларның аерылгысыз бер өлеше кебек кабул ителгән кеше — керәшен татарларындагы патриархаль игенчелек җәмгыятенең (общинасының) мәдәни һәм психологик үзенчәлекләренә тулырак җавап биргән.

Диннең борынгы формалары сакланып калуның мөһим шарты итеп әйләнә-тирә мәдәни һәм социаль мохиткә оста яраклаша белүне атарга кирәк. Монотеистик диннәрнең тышкы формаларын, кайбер символик билгеләрен файдалануга карамастан, мәҗүси дини традицияләр керәшен татарларының мәдәни тормышларына йогынтыларын югалтмый. XIX гасырның беренче яртысында аларның дөньяны күзаллауларында политеистик карашлар өстенлек иткән. Бу карашлар, ышанулар керәшен татарларының дини үзаңнары формалашуда мөһим урын тоткан, милли үзаңның аерылгысыз бер өлешенә әйләнгән. Моны XIX гасырда традицион дини кыйммәтләр тарафдарлары булган керәшен татарларын «таза», «чи», «чын» керәшен дип атау да искәртә.

Этник һәм мәдәни үсеш үзенчәлекләреннән тыш, керәшен татарларында халык диненең саклануына тарихи шартлар да йогынты ясаган. Рәсми рәвештә православие динен кабул итү аларның мөселманнар белән мәдәни элемтәләре өзелүгә сәбәп булган, исламлашу барышын туктаткан. Исламлашу татарлар арасында бик актив барган һәм борынгы төрки йола-гадәтләрнең юкка чыгуына яки аларның кайбер билгеләренең генә өлешчә сакланып калуына китергән. Бер үк вакытта Рус православие чиркәве тарафыннан эзлекле һәм дәвамлы христианлаштыру сәясәте алып барылмау, керәшен татарлары күпләп яшәгән төбәкләрдә чиркәүнең тиешле инфраструктурасы оешып җитмәгәнлек, татар телен белүче һәм халыкны православие нигезләре белән ныклап таныштыра алырлык дин әһелләре булмау, авыл җәмгыятьләрендә бу диннең тышкы сыйфатларының, беренче чиратта, дини бәйрәм йолаларының гына кулланылуына китергән. Күңелләре белән алар христиан дине кабул ителгәнче булган йола, гореф-гадәт тарафдарлары булып калган.

Югарыда әйтелгән сәбәпләр, шулай ук үзенчәлекле социаль шартлар тәэсирендә керәшен татарларының көнкүрешендә патриархаль яшәү рәвеше һәм борынгы дини күзаллаулар сакланып калган. Аларның озын гомерле булуында авыл җәмгыятьләре тормышында мөһим урын тоткан борынгы Җыен структурасы да игътибарга лаек. Җыен системасы керәшен татарларына ябык, чит мәдәни йогынтыларга бирешми торган мәдәни-дини автономия моделен төзергә мөмкинлек биргән.

Керәшен татарларында традицион дини йола культурасының иң үзенчәлекләре дип игенчелек белән бәйле йолаларны атарга кирәк. Авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгән һәм табигать шартларына бәйле булган игенчеләр табигать көчләренә һәм Баш Аллага гыйбадәт кылуга, шул исәптән корбан чалуга бик зур әһәмият бирә торган булганнар. Бу ышанулар борынгы төрки халыклар алласы — Тәңрегә табыну культы белән тыгыз бәйләнгән. XIX йөздә керәшеннәрдә аграр циклга караган Тәңрене хөрмәт итү белән бәйле дини-мифологик ышану һәм күзаллауларны төрле формадагы табынуларны йола системасына әверелә. Керәшен татарларының бу ышанулары күпаллалыктан — бераллалыкка күчү этабы булган. Тәңре образы — Баш һәм Бердәм Алла, дөньяны бар итүче, аңа хуҗа булучы, җир йөзендәге һәр җан иясенең язмышы аның мәрхәмәтенә бәйле булып кабул ителгән. Әмма керәшеннәрнең Тәңрегә ышануларын — бераллалыкка табыну итеп кабул итәргә кирәкми, идеологик нигездә ул «баш» булып калса да, гыйбадәт кылу ягыннан ул күпаллалыкка кайтып кала. «Үзләренең» Баш Аллаларыннан тыш, керәшеннәр «татар», «рус», «чуваш» Аллалары да бар дип ышанганнар. Тәңре-Алла образы алар аңында китапка нигезләнгән авраамик диннәрдәге («татар» һәм «рус») Аллаһ белән һичничек тә охшаш булмаган. Киресенчә, капма-каршылык яшәп килгән. Православие миссионеры һәм этнограф С.Максимов шәрехләгәнчә, 1870 елларда Крещеный Ковали авылы халкы («таза керәшеннәр») — Аллаларын «Алла» дип атаган өчен үпкә белдергәннәр һәм үзләренең аерым Аллалары бар икәнлеген һәм аның Тәңре исемле булуын аңлата торган булганнар [1]. Тәңре культы һәм образы бераллалы христиан һәм ислам диннәренә карaганда чувашларның «Тура», мариларның «Юмо» (йорт иясе, кирәмәтләр), удмуртларның «Инмар», мордваларның «Нишке» («Шкай») кебек Баш Алла образына күпкә якын торган. Урта Идел буенда яшәүче күпаллалы башка җирле халыкларның ышануларындагы шикелле Баш Алла - антропоморфлы (Алла-бабай) булган, дини система дуалистик характерда булган, һәм пантеонда Тәңредән тыш аннан түбәнрәк булган аллалар яшәгән. Китаплы дин Аллаларыннан аермалы буларак, Тәңрегә карата «бар гөнаһларны кичерүче», «мәрхәмәтле» сыйфатларын кулланып булмаган. Чөнки ул, керәшен татарларының антропоморфлы карашлары нигезендә кеше холык-фигыленә ия булган. Ул үзен хөрмәт итүчеләргә, корбан чалучыларга карата «шәфкатьле» һәм «мәрхәмәтле», аңа табынмаганнарга, тиешенчә хөрмәт итмәүчеләргә һәм хурлаучыларга карата «үчле» булган. Ул мондый кешеләргә күпсанлы афәтләр, авырулар, корылык җибәрә, игеннәрен боз белән суга, яшеннән суктырып үтерә ала, дип ышанылган. Татарның күзаллаулары

1. Максимов С. Остатки язычества в современных верованиях крещеных татар Казанской губернии. — Казань, 1876. — С.5.

буенча, Тәңре бик озын чал сакаллы һәм чәчле бер бик зур карт бабай булган. Антропоморфлы формадан тыш, Зәңгәр Күк һәм Баш Алла абстракт рәвештә тагын да киң мәгънәдә, галәм хуҗасы буларак, кабул ителгән. Тәңре һәркайда бар, ул булмаган җир юк, күк йөзен һәм җирне бар итүче дип саналган. Керәшен татарларында Тәңре образын сурәтләгәндә беркадәр тыюлар булган. Аны берничек тә җисем формасында (пот яки сын) рәвешендә тасвирларга ярамаган. Аллалык символы буларак рөхсәт ителгән бердәнбер әйбер ул — изге агач. Аның янында җәмәгать гыйбадәтләре кылынган, аның хөрмәтенә корбан чалынган. Тәңре атамасы урынына «Күк ханы», «Күк падишаһы», борынгы иран (манихей) термины Ходай (Кыдай) кебек атамасын кулланганнар[2]. Тәңре атамасын куллануны тыю күп кенә дини йолаларда чагылыш тапкан. Күп кенә гыйбадәтләрдә аның исемен әйтү тыелган яисә аның исеме башка сүз белән алмаштырылган.

Күп халыкларның дини пантеоннарындагы кебек үк керәшен татарларында Баш Алла Күк күкрәү Алласы булып торган. Аның ихтыяры белән күк күкри, яшен суга, яңгыр, боз ява, иген уңышының күләме билгеләнә, дип саналган. Керәшен татарлары күк күкрәвен Тәңре бабайның тимер зинданнан иреккә чыккан Шайтан белән көрәше дип кабул иткәннәр. Моның өчен ул арбага күктән чабучы юртаклар җигә, аның бер кулында дилбегә, икенче кулында озын чыбыркы белән ул атларны сыдыра. Арба тавышыннан күк селкенә һәм күк селкенүдән күк күкри. Аның чыбыркы шартлатуыннан яшен яшьни, тирә-як ялтырый, күктә ут күренә. Башка ышану да булган: Тәңре юртаклары белән күк буйлап барганда, арба артындагы «гер рәвешендәге» ике зур тимер шар, бер-берсенә бәрелеп, күк күкрәве һәм яшен чыгара [3].

Яшенле яңгыр вакытында керәшен татарлары: «Әнә Тәңре бабай йөри», «Тәңре бабай күкрәтә», — дип әйткәннәр. Тәңренең Шайтан белән көрәше вакытында кешеләр акрын сөйләшергә һәм үзләрен тыйнак тотарга тиеш булганнар. Балаларга тыныч һәм селкенмичә генә утырып торырга кушылган. Йорттан чыгарга рөхсәт ителмәгән, тишек-тошыклар капланган, пәрдәләр корылган. Көлү, кычкырып сөйләшү, ашау (өстәл өстендәге барлык ризык алып куелган) һәм бигрәк тә сүгенү тыелган. Бу тыюлар күп кенә тарихи риваятьләр белән бәйләнгән. Имеш, яшенле яңгыр яуганда бер керәшен ашап утырган. Тәңренең җәзасы һәм ачуы хакында сөйләп торган хатынының сүзләренә колак салмаган әлеге ирне бу гамәле өчен яшен суккан [4]. Кешене яшен сугу аның гөнаһлы булуын, Алла белән дөрес мөгамәләдә булмавын, изге ниятләр белән яшәмәвен күрсәткән [5]. Яшен суккан йортны су сибеп сүндерергә ярамаган. Бу илаһи утны бары сөт белән генә сүндерергә рөхсәт ителгән [6]. Бу күзаллауларда Тәңренең илаһи утына карата ике төрле

2. Мөселман динендәге татарларда бу Аллаһ сүзенең синонимы буларак кулланылган.

3.Максимов С. Указ. соч. — С.5.

4. Степанова С. Указ. соч. Л.104
5. Сизов С. Народный календарь кряшен // ЧДГФИФА. 1 нче бүлек. Н.В. Никольский фонды. Саклау берәмлеге. 321. 112 б.
6. Шунда ук.

караш бергә кушылган: 1) гадәти булмаган утны гади ысуллар белән генә сүндереп булмый; 2) утны илаһилаштырганлыктан, аны су белән сүндерергә ярамый, бу Тәңрене хөрмәт итмәү була.

Керәшен татарларының Баш Алласына характеристика биргәндә өстәмә мәгълүматлар татар-мөселманнарда Тәңре турында сакланып калган карашларыннан табып була. Исламлашу нәтиҗәсендә борынгы төркиләрнең Алла образы татар-мөселманнарда Аллаһ образы белән кушылган. Тәңредә булган антропоморфлы сыйфатлар Аңа да күчерелгән. Аллаһ урынына татар-мөселманнарда «Алла-бабай» атамасын куллану киң таралган. Бу яшен сугуның һәм яшенле яңгырның илаһи көчкә ия булуына ышанудан килә. Казан арты татарларында кояш баегач, «Алла-бабай» кеше кыла торган бөтен гөнаһларны да күрми дигән караш яшәп килгән. Шунлыктан тәүлекнең караңгы вакытында татарлар ислам дине тыйган кайбер гамәлләрне кылганнар. Татарлар карашынча, Тәңре кеше гамәлләренә турыдан-туры кысылмаган, үзе кушканнарны үтәгән өчен җәзаламаган. Кешене яшен сугу гадәти күренеш буларак кабул ителгән: чөнки «эзәрлекләнә торган шайтан кеше арасына кача һәм Тәңренең аңа аткан яшеннәре ялгыш кешене дә үтерергә мөмкин». Яшен вакытында шайтан якын килмәсен өчен татарлар «Лә һәүлә вә лә кувәтә иллә билләһил галиел газыйм» яки «Бисмилләһ» дип дога укыйлар, аларны уку явыз рухларны нык куркыткан [7]. Оренбург губернасы татарлары Тәңрене мөселман календаренең изге төннәренең берсендә — «күк капкасы ачылганда» күрергә мөмкин дип санаган. Күк капкасы озак ачылып тормаган: ачылган мизгелдә җир өстенә аксыл көмеш төсендәге нур — «Ходай рәхмәте», «Тәңре рәхмәте» нуры иңгән. Бар теләгән теләкләр һәм догалар шушы мизгелдә Алла тарафыннан кабул була дип уйланган. Әмма мондый күренешкә бик сирәк кешеләр генә тап булган [8].

Керәшен татарлары ышанулары буенча, авыл кешесенең бәрәкәтле тормышы күктәге һәм җирдәге барлык көчләрнең хуҗасы булган Тәңрегә бәйле. Ул мул уңыш бирә алган, теләсә игенне боз суккан, корылык килгән, үләт авыруы таралган. Аның рәхмәтенә ирешер өчен корбан чалырга һәм гыйбадәт кылырга кирәк, дип саналган. Шуңа күрә XIX гасырның беренче яртысында керәшеннәрнең авыл хуҗалыгы белән бәйле дини йолалар күпмедер дәрәҗәдә Тәңре культы белән бәйле [9].

Авыл хуҗалыгы белән бәйле дини йолаларны җир кибүгә, чәчү башланганчы Шыйлык / Сабантуй бәйрәме ачып җибәргән [10]. Татарларның бәйрәм-йола культурасын тикшергән күренекле татар этнографы Р.К.Уразманова фикеренчә: «Сабантуйны бәйрәм итүнең тамырлары борынгыдан килә һәм ул аграр культ белән бәйле. Моның шулай булуын аның исеме үк күрсәтеп тора: «сабан» язгы чәчүне яки башка мәгънәдә тор-

7. Зорин Б. Остатки язычества у татар Оренбургской и Уфимской губерниях // Вестник Оренбургского учебного округа. — 1913. — №2 — С.54.

8. Шунда ук.

9. Керәшен татарлары бу ике бәйрәмне аерып карамаганнар, алар бер-берсен тулыландырган. «Шыйлык» сүзе Сабантуй атамасына синоним булып йөргән. Шыйлык һәм Сабантуй бәйрәмнәренең тыгыз бәйләнеше турында Казан губернасы Мамадыш өязе Чура авылы рухание И.М.Ляпидовскийның этнографик очеркында бәян ителә (И.Ляпидовский. Записка составления для Российского географического общества о жителях Ядыгеровской волости Мамадышского уезда Казанской губернии (1848 г.) // ОР РНБ. Ф.СПБДА. Оп.1. Д.АI./232. Л.17). Этнограф И.Коваль ТАССРның Минзәлә кантоны һәм БАССРның Бәләбәй кантоны керәшен татарлары үткәрә торган «Мәйдан»ның башкорт һәм татарларның «Мәйдан»нарына (Сабантуй — Р.И.) охшаш булуы турында яза (Коваль И.

ган, ә «туй» «тантана»ны аңлаткан. Шулай итеп, «сабантуй» сүзенең мәгънәсе — сабан ашлыклары хөрмәтенә бәйрәм итү. Беренче вакытта, йоланың максаты яңа елда яхшы уңыш алу өчен рухларны юмалаудан гыйбарәт булгандыр». XIX гасырда татар-мөселманнарда бу бәйрәм дини үзенчәлеген югалтып, төрле уеннар уздырыла торган халык бәйрәменә әверелгән. Керәшен татарларында исә, асыл мәгънәсендә сакланып калган [11].

Керәшен татарларында бу дини бәйрәм ике өлештән торган: «олы буын» вәкилләре өчен дини «Шыйлык», ә яшьләр өчен — дөньяви «Сабантуй». Шыйлык атамасының этимологиясе бик үк аңлаешлы түгел. Р.Г. Әхмәтҗанов уйлавынча, «шыйлык» сүзе Идел буе халыклары телләрендә төрле фонетик вариантларда кулланылган. Мәсәлән, чувашларда «шальлек», «шилек» — килен йортының ишегалды уртасында хәзерләнгән кунакларны сыйлар өчен куелган өстәл; мариларда «шелык» — ишегалды уртасында хәзерләнгән кунак өстәле, туй ризыгы; иске төрек телендә «патша мәҗлесе» мәгънәләрендә йөри. Бакалы һәм Чистай төбәге керәшен татарларында бу сүзнең мәгънәсе бик охшаш. Оренбург татарларында ул пикникка чыгу, күмәк күңел ачуны белдергән «шеллекә чыгу» гыйбарәсен аңлаткан.

Төрле телләрдә бу сүзнең лексик мәгънә ягыннан охшаш булуы Идел буе халыкларында бу бәйрәмнең киң таралыш алганлыгын һәм бертөрле эчтәлеккә ия булуы турында сөйли. Шыйлык бәйрәме мәгънәсе туй ритуалы мәҗлесе һәм гомумхалык бәйрәме дигәнне аңлатуы һич кенә дә очраклы түгел. Биредә килен ролендә җир-туфрак — хатын-кыз башлангычы, ә игенченең эш коралы сабан — ир-ат башлангычын (фаллос) гәүдәләндергән. Бу бәйрәмнең символик нигезе, гаилә тормышының серле йоласы — җирне сабан һәм кызартылган йомыркалар ярдәмендә аталандыру, яңа тормыш яралту (иген шытып чыгу) белән бәйле.

Шыйлык бәйрәме атнаның беренче көнендә үткәрелгән (дүшәмбе). Олы тантана рәвешендә үткәрелә торган бәйрәм авыл халкын сыйлау белән дәвам иткән һәм символик яктан туйны хәтерләткән [12]. Казан губернасы Мамадыш өязе (Никифорово (Чия Баш) авылы) керәшен татарларында бәйрәм билгеләнгән көнне, иртән яшь егетләр өй саен кызартылган йомырка җыйганнар. Һәр хуҗабикә йорттагы яшь бала санына карап йомырка бирергә тиеш булган, ә карчыклар «тавык исәнлеге» өчен күпләп биргән. Барлык йортларны йөреп чыккач, егетләр авыл кырыендагы аланга җыелган. Бу вакытта яшь кызлар да аларга килеп кушылган. Аннары күз тию һәм явыз рухлардан саклану өчен «ут белән чистарыну» йоласын үткәргәндә, зур учак ягылган.

Көн уртасында җыелган халык гыйбадәт кылу ритуалын башкарган. Һәр йорт хуҗасы тубалга 5 фунт (2 кг) тирәсе ашлык салган, бөртек өстенә ике арыш ипие, каймак яки эремчек,

Обряды крещёных татар (именуемых кряшен) // Краеведческий сборник. — 1930. - №2-3. — С.82). Этнограф Р.Г.Кашафетдиновның информаторлары фикеренчә, «шыйлык шул ук Сабантуй» (Татары Среднего Поволжья и Приуралья ... — С.370).

10. Бу бәйрәм-йола керәшен татарларының дини һәм мәдәни тормышында мөһим урын алып тора, аның «Сабантуй ае»нда үткәрелүе дә шуңа дәлил. [Баязитова Ф.С. Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. — М, 1986. — С.182.

11. Р.К.Уразманова фикеренчә, Казан төбәге татарларыннан аермалы буларак, татар мишәрләрендә Сабантуйны бәйрәм итмәгәннәр. Бары тик бу төбәккә якын җирләрдә һәм мәдәни яктан аралашкан кайбер төркемнәрдә бу бәйрәм билгеләп үтелгән. Татар-мишәрләр арасында бәйрәмнең тарала башлавы XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында татар милләте оешу белән бәйле. (Уразманова Р.К. Обряды и праздники

бал белән ризык һәм ике буялган йомырка куйганнар. Хуҗалар үзләре белән шулай ук бер чиләк яки чүлмәк сыра яисә шәраб алганнар. Бәйрәмчә киенгән гаилә әгъзалары да, әзерләнгән ризык белән шыйлык үтә торган аланга килгәннәр. Биредә тубалларны тигез рәткә тезеп куйганнар. Йорт хуҗалары җыелып беткәч, гыйбадәт башланган. Гаилә башлыклары тубалларны кулга алып, бил бөгә-бөгә, Тәңрегә гыйбадәт кылганнар: Алладан быелгы елда да мул уңыш, бәрәкәт сораганнар. Бу гыйбадәтнең икенче бер максаты — тиздән чәчеләчәк тубалдагы бөртекләрне рухи сихәтләндерү дә булган. Йола тулы тынлыкта башкарылган. Корбан казанына дип тубалларда салып килгән ризыкларның бер өлеше бирелгән. Эремчек, бал, каймак, йомыркадан гыйбарәт булган ризыкларны махсус билгеләнгән олы яшьтәге кешеләр (картлар) бергә җыеп аралаштырганнар. Авылның өлкән буын ир-атлары катнашкан икенче гыйбадәттән соң бу сый-нигъмәтләрне бәйрәмгә килүчеләргә таратканнар. Ир-атларга пешкән ботканы икмәккә ягып биргәннәр, ә хатын-кызларга касәләргә салып өләшкәннәр. Гыйбадәт вакытында рухи сихәтләндерелгән ашлыкка кагылмаганнар [13].

Кама арты керәшен татарларында (Уфа губернасы Минзәлә өязе) бу бәйрәмне үткәрү тәртибе Казан арты керәшен татарларыныкыннан бераз аерылган. Бәйрәм иртән иртүк башланган. Иртәнге сәгать алты тирәсендә бәйрәмчә киенгән ир-ат бәйрәм үткәрү өчен махсус билгеләнгән урынга яки аланга балалары белән килгән. Алар тубалларда тиздән чәчеләчәк солы (бодай, борай, тары) орлыклары, үлән суы белән буялган йомыркалар һәм сөт ризыклары (май, эремчек, әчетелгән сөт) алып килгәннәр. Азык-төлек тулы тубалларны өчпочмак формасында тезгәннәр. Өлкәннәр баш киемнәрен салмыйча гыйбадәт кылган, корбан ашы әзерләнгән. Алып килгән сөт ризыкларын бер казанга салганнар, алар өстенә эре итеп туралган, пешкән йомырка салып болгатканнар. Шул рәвештә әзерләнгән ботканы һәр хуҗалыктан килгән зур касәгә салып, гаилә башлыгына бүлеп биргәннәр. Төш вакыты җиткәч, ир-атлар тарала башлагач, Шыйлык мәйданына авыл хатын-кызлары җыелган. Матур итеп киенгән хуҗабикәләр кызлары, киленнәре, каен сеңелләре белән бергә бәйрәм үтә торган урынга сөттә пешкән тары яки борай боткасы салган зур савытлар алып килгәннәр. Алып килгән аш савытларын дөрес бер форма рәвешендә мәйданга тезгәннәр. Дини ритуалны башкару өчен чакырылган гыйбадәт кылучылар бер туры рәткә басып, кулларына ботка салган аш савытларын алып, дога сүзләрен әйткәннәр. Гыйбадәт кылганнан соң картларның ботканы тәмләп караулары җыелган хатын-кызлар өчен ботка белән сыйлану мәҗлесен башлап җибәрүне аңлаткан [14].

Җәмәгать белән гыйбадәт кылганнан соң, гаилә башлыклары, әйтик (Казан губернасы Мамадыш өязе Чура авылында),

татар Поволжья и Урала (годовой цикл XIX — начало XX вв.). Историко-этнографический атлас татарского народа. — Казань, 2001. — С.54.)

12. Православия идеологиясе һәм руханилары эшчәнлеге йогынтысы тәэсирендә XX гасыр башы керәшен татарларында дүшәмбе көнне кыр эшләрен башлауны тыю моның белән бәйледер, мөгаен. Дүшәмбе көнне ашлык чәчү уңыш булмауга китерә дип саналган (Петров И.В. Сочинение о сохранившихся суевериях и религиозно-мифологических представлениях кряшен (1921 г.) // ЧДГФИФА. 1 нче бүлек. Н.В. Никольский фонды. Саклау берәмлеге 321. 155 б.).

13. Тимофеев В.Т. Мое воспитание (рассказ старокрещёного татарина) // Казанская центральная крещёно-татарская школа. Казань, 1887. — С.18.

14. Коваль И. Обряды крещёных татар (именуемых кряшен) // Краеведческий сборник. — 1930. — №2-3. — С.81-82.

ат җиккәннәр, сука, тырма, орлык алып басуга чыкканнар, чәчүгә керешкәннәр. Ишегалдыннан чыккан вакытта хуҗабикә җигелү ат өстенә он сибә торган булган. Хуҗаның хатыны башка гаилә әгъзалары белән бәйрәмнән калган ризыкларны алып ире артыннан басуга чыккан. Йорт хуҗасы озынлыкка өч аршин (2,13 м), киңлеккә бер аршин (71 см) булган, басу юлы кырыендагы басу җирен сукалап, солы, бодай яки борай чәчкән. Орлык чәчкәндә сөрелгән җиргә кызартылган йомырка атканнар, соңыннан аларны кечкенә балалар җыеп ала торган булган. Орлык чәчелгән җирне тырмалаганнан соң, гаилә әгъзалары хуҗабикә алып килгән ризык белән сыйланганнар, ашаганнар, эчкәннәр [15]. Казан губернасы Мамадыш өязе һәм Уфа губернасы Минзәлә өязенең кайбер авылларында чәчелгән җир өстенә ашарга утырыр алдыннан җир хуҗасына яки (хуҗабикәсенә) корбан китерү йоласы башкарган: бербөтен икмәкнең кибән башы кисеп алынып, кызартылган йомырка белән җиргә күмелгән.

Тамак туйдыргач, басуда сука һәм тырманы калдырып, авыл кешеләре бәйрәмнең икенче өлешен — Сабантуйны бәйрәм итү өчен, авылга кайтырга ашыкканнар. Бәйрәмнең бу өлеше татар-мөселманнар уздыра торган Сабантуй белән охшаш булган. Татар керәшеннәренең бу бәйрәмне үткәрүләре турында Казан губернасы Мамадыш өязе Чура авылы рухание И.М.Ляпидовский бик төгәл һәм җентекләп язып калдырган: «Авылның бар халкы сабан басуы капкасы янына килә, биредә ат чабышы, көрәш, сикерү һәм йөгерү ярышлары була, җиңүчеләрне татарлардагы кебек бүләклиләр. Йөгерешкә кайвакыт иң өлкән кешеләрне чакыралар, алар йөгереп тамашачыларны бик каты көлдерәләр. Яшьләрнең күңел ачулары тәмамланганнан соң, авылның бер башына — халык кунак каршыларга әзерләнгән йортларга юнәлә. Авылның бу башында яшәүче һәр хуҗабикә зур савыт белән токмач һәм кашыклар әзерләп куялар. Киң һәм чирәм үскән ишегаллары уртасына өстәл һәм эскәмия куялар, килгән кунаклар шунда утыра. Ашап сыйланганнан соң, кешеләр йортларына тарала һәм бәйрәм төн буе дәвам итә. Бу бәйрәм өч көн дәвам итә. Сабан бәйрәме тәмамлангач, көннәр җылы булса, эшкә керешәләр, әгәр дә көннәр яңгырлы яки салкын торсалар, чәчү уңай һава торышы урнашканчы кичектерелә. Мәлки керәшеннәре дә Сабантуйны шушы рәвешле бәйрәм иткәннәр».

Шыйлык (Сабантуй) — керәшен татарларында XIX гасырның беренче яртысында авыл хуҗалыгы белән бәйле корбан чалусыз гына үткәрелә торган дини бәйрәмнәрнең берсе. Мул уңыш белән бәйле «яңа тормыш»ка җан бирә торган, җирне символик аталандыру («сабан һәм җир туе») йоласы, кан агызудан, корбан чалудан башка уздырылган. Чөнки мондый корбан бәйрәмнең асыл мәгънәсенә каршы килгән. Корбанлыкны авыл хуҗалыгы азык-төлекләре алыштырган.

15. Ляпидовский И. Записка составленная для Российского географического общества о жителях Ядыгеровской волости Мамадышского уезда Казанской губернии (1848 г.) // ОР РНБ. Ф.СПБДА. Оп.1. Д.AI./232. Л.17.

күпчелек халыкларның бәйрәм йолаларында мөһим урынны уңдырышлылыкның борынгы символы булган, кызартылган йомырка алып тора. Тәңрене хөрмәтләү белән беррәттән бу бәйрәм йолаларында җир һәм аның хуҗасы (хуҗабикәсе) культы чагылышы да сакланган. Р.Г.Кашафетдинов фикеренчә: «бәйрәмдә үтәлә торган йолаларда ата-бабаларны ихтирам итү белән бәйләнеш бар: болар (йолалар — Р.И.) барысы да борынгы язгы бәйрәмне искә алу мәҗлесендә чагылыш таба, чөнки язны искә алу мәҗлесе кар эрү һәм табигатьнең уянуы белән бәйле» [16]. Бу җәһәттән Шыйлык һәм мәҗүси чувашларның Шилек бәйрәмнәре арасында охшашлык күзәтелә. Шилек бәйрәмендә ата-бабаларны искә алу белән бәйле йолалар мөһим урын алып тора [17].

Уңдырышлылык белән бәйле һәм язгы чәчү алдыннан уздырыла торган татар Сабантуена охшаш бәйрәмнәр чувашларда Акатуй, мариларда Ага пайрам, удмуртларда Акаяшка, башкортларда Һабантуй исемнәре белән үткәрелә. Идел-Урал төбәгендә яшәүче рус булмаган халыкларда бу бәйрәм комплексын белдерә торган йолаларга сабан игенен чәчү алдыннан җәмәгать белән кырда гыйбадәт кылуны (татарлардан һәм башкортлардан тыш), күмәкләшеп сыйлану һәм күңел ачуны кертергә мөмкин. Татарлар белән янәшә көн иткән мәҗүси чувашларда (Казан губернасының Зөя һәм Чуел өязләре) Шыйлык бәйрәмен бераз мөселманлаштырып үткәргәннәр. Ул христианнарның Пасха бәйрәменә хәтле үткәрелгән. Гыйбадәт кылучылар итеп муллалар яки ислам йолаларын белүче татарлар чакырылган, ритуалны башкаргач, аларга сәдака бирелгән. Йоланы башкаручы халык мөселман догасын әйтмичә генә имамның гыйбадәт кылу хәрәкәтләрен кабатлаган. Җәмәгать белән гыйбадәт кылганнан соң, корбанлыкка пешкән ботка һәм хуҗабикәләр алып килгән ризыклар белән бәйрәм сые ясалган. Бәйрәмгә атап махсус зур күләмдә сыра кайнатылган. Бәйрәм тәмамлангач, күңел ачу игенчеләр йортларында дәвам иткән. Бу көнне кунакка йөрешкәннәр, җырлап һәм биеп күңел ачканнар.

Игенчелек циклы белән бәйле йола-бәйрәмнәр керәшен татарларының традицион дин нигезен тәшкил иткән. Традицион ышануларда Баш Алла — Тәңре, җир һәм су хуҗасы (хуҗабикәсе) культларының керәшен татарларында дини пантеон персонажларының иң әһәмиятлеләре арасында тыгыз элемтә булу юкка гына түгел. Бу күренеш керәшен татарларының традицион культурасын һәм дини традицияләрен формалаштыруда табигатьнең мөһим роль уйнавы, ә авыл хуҗалыгы җитештерү тармагының аларның социаль һәм экономик халәтенә һәм хуҗалык укладының йогынтысы белән аңлатыла.

16. Татары Среднего Поволжья и Приуралья … — С.371.
17. Шилек // Известия по Казанской епархии. — 1913. — №30-31 — С.909.

ТАТАРЛАРДАН БЕРЕНЧЕ ПЕДАГОГИКА ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ

ЛӘЛӘ МОРТАЗИНА,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты

Татар педагоглары арасында педагогик фикер үсешенә сизелерлек өлеш кертеп тә, беркадәр күләгәдә калган шәхесләр була. Шундыйларның берсе — Василий Михайлович Горохов. Онытылган шәхес дип әйтү, бәлки, дөрес үк булмас, чөнки галимнең хезмәтләре бүген дә актив кулланылышта, фәнни әйләнештә: татар мәгарифе тарихын өйрәнүчеләр аның мирасына еш мөрәҗәгать итә, ләкин педагогның тормышына, күпкырлы эшчәнлегенә, хезмәтләренә багышланган мәкаләләр әлегә бик аз. В.М.Горохов «Татар энциклопедиясе»нә кертелгән, аның эшчәнлеге беркадәр Я.И.Ханбиков, З.Т.Шәрәфетдинов тарафыннан өйрәнелгән [1], бүгенге көндә Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институ-

1. Татарская энциклопедия: В 5 т.: Т.2. — Казань: ИТЭ, 2005. — С.151; Ханбиков Я.И., Шарафутдинов З.Г. Из истории педагогической мысли татарского народа. — Казань, 1998. — С. 285.

В.М.Гороховның бердәнбер фотосы. Тәүге тапкыр басыла.

тында басмага әзерләнгән икетомлык «Татар педагогик фикере антологиясе»нә биографиясе һәм педагогик эшчәнлеге турында мәгълүмат, шулай ук хезмәтеннән өзек кертелгән, әмма галимнең тормышын һәм иҗатын тулаем күз алдына китерерлек хезмәтләр әле язылмаган. В.М.Гороховның тормышына караган яңа мәгълүматлар эзләүдә кыенлыклар бар, чөнки шәхси эше, башка документлары, ни сәбәпледер, архивларда сакланмаган [2]. Үзенең 30 ел гомерен Казан педагогия институтына багышлаган профессорны онытырга хакыбыз юк.

Татар галимнәре арасында бер үк вакытта педагогика һәм мәгариф тарихына, шулай ук заманның актуаль педагогик проблемаларына, белем бирү һәм тәрбия мәсьәләләренә мөрәҗәгать

2. КФУ архивында В.М.Гороховның шәхси эшенең тасвирламасы бар, ә эш үзе юк; Татарстан Милли архивында В.М.Горохов турында өзек-өзек, кыска мәгълүматларга гына тап булдык.

Дьякон Михаил Леонтьев, Покров керәшен татарлары хатын-кызлары общинасы мәгърифәтчелек мәктәбендә музыка укытучысы (1908 – 1917 еллар).
XX гасыр башында төшерелгән фоторәсем.

иткән һәм аларны бер үк дәрәҗәдә тирән итеп өйрәнгән педагоглар күп түгел. В.М.Горохов педагогика фәне тарихына, иң беренче чиратта, татар мәгарифе һәм мәктәбе белгече буларак кереп калды. Әлбәттә, бүген галимнең фикерләренә бәя биргәндә, ул хезмәт иткән чордагы партия сәясәтен һәм идеологиясен истә тотып эш итү мөһим. Гороховның фәнни эшчәнлеге ул заман өчен генә түгел, бүген дә актуаль.

Татарлар арасында беренче педагогика фәннәре докторы, профессор Василий Михайлович Горохов 1891 елның 1 мартында Вятка губернасы Алабуга өязе (Татарстанның хәзерге Алабуга районы) Олы Елау авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Олы Елау башлангыч мәктәбен, соңыннан Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен (1907) тәмамлый, Казан укытучылар семинариясендә белем ала (1907-1911). Педагогик эшчәнлеген Василий Михайлович Мамадыш өязе Яныл авылындагы ике класслы мәктәптә башлап җибәрә, ләкин белемен арттыру теләге аны авыл мәктәбеннән аера һәм еракка — Иркутск университетының философия-педагогика факультетына алып килә. В.Горохов биредә 1917-1922 елларда укый.

Югары белем алып, Казанга кайткач, ул педагогик эшчәнлеген дәвам итә: Керәшен педагогия техникумында укыта башлый. Василий Михайловичның 1930 елдан башлап [3] бөтен эшчәнлеге Казан педагогия институты белән бәйле. Ул ассистенттан башлап, доцент [4], профессор (1950) дәрәҗәләренә ирешә, 1930-1951 елларда педагогика факультеты деканы, педагогика һәм психология кафедрасы мөдире (1952-1956) булып эшли, төрле факультетларда педагогика фәне буенча лекцияләр укый. 1956 елдан алып вафат булганчы (1960), Василий Михайлович институтның фән эшләре буенча ректор урынбасары булып хезмәт итә. Биредә эшләгән елларда ул үзенең фәнни хезмәтләрендә гаилә һәм әхлак тәрбиясе, рус педагогикасы һәм татар милли мәктәбе тарихы проблемаларына мөрәҗәгать итә.

3. ТР МА, 1487 ф., 1 нче тасв., 210 эш, 7 б.

4. 1931 елның 1 гыйнваренда В.М.Горохов ассистент, 1931-1932 уку елы азагында доцент вазифасын башкара (ТР МА, 1487 ф., 1 нче тасв., 209 эш, 1 б.; ТР МА, 1487 ф., 1 нче тасв., 210 эш., 7 б.).

Горохов иҗтимагый эшләрдә дә актив катнаша. 1922-1925 елларда аның Татар телен гамәлгә кую (РТЯ) курслары мөдире булып эшләве билгеле. Күпсанлы хезмәтләре өчен галим Совет дәүләте тарафыннан «Хезмәттәге батырлык өчен» медале (1951) һәм Хезмәт Кызыл Байрагы (1952) ордены белән бүләкләнә.

Галим «Идел буе татарларына карата царизмның мәктәп өлкәсендә руслаштыру сәясәте» темасына кандидатлык (1939), «XIX гасырда һәм XX гасыр башында Идел буе татарлары арасында уку-укыту эшләре» темасына докторлык (1948) диссертацияләре яклый. Соңрак бу хезмәтләре аерым китаплар булып дөнья күрә һәм тиз арада галимнәр һәм мәгариф тарихы белән кызыксынучылар арасында теләктәшлек таба.

40-50 нче елларда педагоглар һәм тарихчылар арасында татар мәгарифе тарихының иң кызыклы күренешләреннән берсе булган җәдитчелек хәрәкәтен өйрәнү һәм аңа яңача бәя бирү омтылышы күзәтелә. Бу проблемага иң беренчеләрдән булып Г.М.Халитов, Р.М.Рәимов һәм В.М.Горохов мөрәҗәгать итә. Әлеге галимнәрнең хезмәтләрендә җәдитчелек татар мәктәбенә реформа алып килгән, «татар җәмгыятен европалаштыруга» юнәлдерелгән мәгърифәтчелек хәрәкәте буларак карала, XIX гасыр татар мәгърифәтчеләре эшчәнлеге белән бәйләп өйрәнелә.

В.М.Горохов үзенең кандидатлык диссертациясе нигезендә басылып чыккан «Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья» (Казан, 1941) дигән китабында хөкүмәтнең рус булмаган халыкларга карата алып барылган миссионерлык һәм рус телен тарату эшчәнлегенең асылын

билгели, аны кискен тәнкыйть итә, Россиядәге халыкларның тигез хокукка ия булып, бары тик «бөек рус» милләтенең генә күптөрле өстенлекләрдән файдалана алуы турында яза [5]. Аның бу фикерләре заманы өчен кыю сүз булды. Шуның белән күпләрнең игътибарын җәлеп итте.

5. Горохов В.М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. — Казань: Таткнигоиз-дат, 1941. — С.6.

6. Горохов В.М. Күрсәтелгән хезмәт. — Б.27.

В.М.Горохов, «новокрещенская школа»лар ачылуның әһәмиятен ассызыклап, аларны Казан губернасында яшәүче рус булмаган халыклар, шул исәптән татарлар, арасында элементар грамоталылык тарату учаклары дип атады [6]. Татарларга карата бу фикер белән килешү, әлбәттә, мөмкин түгел, чөнки аларның мөстәкыйль белем бирү системасы була. Татарлар арасында укый-яза белүчеләрнең саны башка халыклар белән чагыштырганда күбрәк булуы — күптән расланган факт. Татар мәгарифенең үсеш баскычларын тирәнтен өйрәнгән Гороховның бу турыда әйтми калуын шул заманның идеология йогынтысы белән аңлатырга мөмкин.

Галим рус-татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләр каршында ачылган сыйныфлар турында да үз фикерен әйтә. «Беренче карашка, — ди ул, — бу мәктәпләр бигрәк тә халыкны рус теленә өйрәтү, рус мәдәниятенә якынайту максатыннан караганда уңай роль уйнасалар да, аларның көчләп кертелүе сәбәпле, гади халыкта яклау таба алмады, алай гына да түгел, зур каршылыклар тудырды» [7]. Бу сәясәт патша хөкүмәтенең рус булмаган халыклар мәдәниятен үстермәскә тырышуда, милли һәм тарихи үзенчәлекләрен исәпкә алмауда чагыла иде. Галимнең бу чорны бәяләгән фикерләре бүген дә актуальлеген югалтмый.

7. Горохов В.М. Күрсәтелгән хезмәт. — Б.241.

Профессор В.М.Гороховның икенче китабы «Школьное образование среди татар Поволжья в XIX и в начале XX века» (1947) дип атала. Ике томнан торган бу хезмәт татарларда мәктәп тарихын системалы рәвештә анализлаган китапларның иң күләмлесе, саллысы һәм бүгенге көндә һич кенә дә әһәмиятен югалтмаган басмаларның берсе булып тора.

«Педагогика тарихыннан очерклар» (Казан. 1956) дип аталган өченче китабында автор, рус педагогикасы тарихы белән беррәттән, татар милли мәктәбенең тарихын да җентекләп сурәтли. «Татарларда мәгариф эшләре» дигән бүлектә, мәсәлән, галим хатын-кызлар өчен ачылган кайбер мәктәпләр, хатын-кыз педагогларыбыз турында кызыклы фикерләрен әйтә. Дөрес, бирелгән мәгълүмат бик үк тулы түгел, бүгенге көн күзлегеннән караганда, галим фикерләрендә кайбер каршылыклар да очрый.

В.М.Горохов татар мәгарифе үсешенә зур өлеш керткән атаклы шәхесләребез турында да яза. Ул педагоглар арасында беренчеләрдән булып сөекле шагыйребез Г.Тукайның педагогик карашларын өйрәнә, аның шигъриятендә әхлак һәм тәрбия мәсьәләләренә тирән анализ ясый. Тукайның татар мәгарифе үсешенә керткән өлеше кайбер мәкаләләрдә моңа кадәр яктыр-

тылса да, киңкырлы итеп өйрәнелгән хезмәтләр әле ул вакытта булмый [8]. Г.Тукайның педагогик карашлары фәнни тема буларак 1960 елларда гына өйрәнелә башлый [9].

Тукайның педагогик карашлары арасында иң әһәмиятлеләре дип галим халыкны гыйлемле итү, укытуның мәҗбүрилеге, мәгърифәт, белем таратуда матбугатның, әдәбиятның мөһим роле турындагы фикерләрен әйтә. Г.Тукайга бәя биреп, шагыйрьне «сизгер психолог һәм педагог» дип атый.

Галимнең дөнья күргән иң соңгы җыентыгы — хезмәттәше Б.П.Рождественский белән бергә язган «Развитие народного образования в ТАССР» (1958) дигән брошюра. Бу хезмәттә Октябрь революциясенә кадәрге чордан башлап 50 нче елларга кадәр булган вакыт аралыгында Татарстанда халык мәгарифе үсешенең төп тенденцияләре һәм үсеш үзенчәлекләре актырыла.

Гәрчә белеме буенча филолог булмаса да, галим татар терминологиясе фәне үсешенә дә үз өлешен кертә. Горохов психология һәм педагогика терминнарын туплаучы, өйрәнүче һәм эшкәртүче буларак та танылa. Галим катнашында төзелгән рус-татар терминнары сүзлеге [10] бу өлкәдә тәүгеләрнең берсе була. Рус терминнарын татар теленә тәрҗемә итү һәм аларга аңлатма бирүдә бу хезмәт шактый тулы һәм төгәл басма булып тора. Моңа кадәр кулланылышта йөргән рус терминнарының кайберләре урынына шактый кызыклы вариантлар тәкъдим итүе белән (мәсәлән, еллыкчы — второгодник) автор татар телен фән теле буларак раслауга да үз өлешен кертә. Бу сүзлек белгечләр тарафыннан хуплап кабул ителә.

Фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлешләре татар мәгарифе тарихы мәсьәләләре белән бәйле булса да, алда әйтелгәнчә, В.М.Горохов мәктәп, уку-укыту, тәрбия мәсьәләләрен дә ныклап өйрәнә. Ул — гаилә тәрбиясе, әхлак тәрбиясе мәсьәләләренә багышланган күпсанлы китаплар авторы [11]. Аның тәрбиягә багышланган хезмәтләре белән таныштырып китәсебез килә.

1955 елда галимнең «Мәктәптә тәрбия эшләре» («Воспитательная работа в школе») дип аталган хезмәте басыла. Бу китапта милли мәктәптә тәрбия эшләре алып баруның төп үзенчәлекләре ассызыклап күрсәтелә, балаларны тәртипкә өйрәтү, үз-үзен тоту кагыйдәләрен тәрбияләү буенча киңәшләр бирелә. Әлеге методик киңәшләрне, әлбәттә, бүген тулысынча файдалану мөмкин түгел, чөнки алар шул заман, шул чор идеологиясе кысаларында язылганнар, әмма төп принциплар хәзер дә актуаль. Чөнки бүгенге мәктәптә дә, беренче чиратта, тәрбиягә, тәртипкә игътибар җитеп бетми, балаларның эчке дисциплинасы түбән; югары әхлак кануннары нигезендә тәрбияләү бүген дә бик мөһим.

Хәзерге мәктәптә төп максат итеп белем бирү каралган.

8. Бакиров Г. Г.Тукай һәм татар әдәбиятыннан дәреслекләр // Совет мәктәбе. — 1940. — № 6-7.

9. Туишев Ю.А. Общественно-педагогическая деятельность Габдуллы Тукая. — Казань: Татар. кн.изд-во,1963. — 110 с.

10. Горохов В., Касыймов А., Хангильдин В. Русско-татарский терминологический словарь по психологии и педагогике. — Казань, 1950. — 104 с.

11. Горохов В.М. Трудовое воспитание в Кураловском детском доме в условиях военного времени. — Казань, 1943. — 35 с.; Горохов В.М., Рождественский Б.П. Балаларны тәрбияләүдә семьяның, мәктәпнең һәм җәмәгатьчелекнең бергәлек эше турында. — Казан, 1955. — 28 б.; Горохов В.М. Мәктәптә тәрбия эшләре. — Казан: Таткнигоиздат, 1955. — 140 б.; Совет балаларында, совет яшьләрендә үз-үзләрен тоту культурасын тәрбияләү. — Казан: 1954. — 26 б.

Тәрбия ата-аналарга йөкләнгән. Мәктәптән тәрбия функциясе алынуның аяныч хәлләргә китергәнлеге күз алдыбызда. Галим балаларны тәрбияләүдә гаиләнең һәм мәктәпнең уртак, бергәләп эшләүләре мәҗбүрилеген ассызыклый, әмма, баланың яшенә карап, бу бергәлекнең беркадәр үзгәрү кирәклеге турында яза. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр, ата-ананың бер-берсенә булган мөгамәләсе баланың дөрес тәрбия алуына ярдәм итә торган факторлар буларак сурәтләнә. «Гаиләдә кешенең характерына башлангыч нигез салына, баланың индивидуаль сыйфатлары үстерелә. Гадәт, үз-үзеңне тоту алымнары, дуслык һәм иптәшлек, коллективизм, тугрылык, намуслылык, совет патриотизмы, бөтен халкыбызга мәхәббәт — болар беренче тапкыр гаиләдә тәрбияләнә башлый», — дип яза автор. Аның өчен хезмәт тәрбиясе дә мөһим урынны били. Әхлак тәрбиясе галим хезмәтләрендә шулай ук алгы планда тора. Яшь буынны әхлакый яктан тәрбияләүгә бүген дә зур әһәмият бирелә. Шушы аспекттан караганда, В.М.Гороховның тәрбиягә багышланган хезмәтләре тирәнтен өйрәнүгә һәм, беркадәр үзгәртелеп, яңа шартларда укыту-тәрбия барышында кулланылуга хокуклы.

Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен һәм Казан укытучылар семинариясен тәмамлаган, Керәшен педагогия техникумында укыткан кеше буларак, В.М.Горохов керәшен татарлары мәктәпләре эшчәнлеге турында да күп яза. Ул — керәшен татарлары арасында мәгариф таралу мәсьәләләрен мөселман мәгарифе белән беррәттән990 бербөтен итеп өйрәнгән сирәк галимнәрнең берсе (фәндә татар мәгарифе дигәндә, нигездә, мөселман татарлары арасында белем һәм тәрбия бирүне күз алдында тоту киң таралган). Горохов хезмәтләрендә керәшен мәктәпләре тарихына да зур игътибар бирелә. Шуның белән бергә В.М.Горохов — керәшен татарлары мәктәпләрен методик яктан тәэмин итүгә дә сизелерлек өлеш керткән педагог. 1929 елда аның керәшен мәктәпләре өчен И.А.Алексеев белән берлектә төзелгән хрестоматиясе басылып чыга [12].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: В.М.Гороховның педагогик эшчәнлеге татар педагогикасы тарихында якты сәхифәне тәшкил итә. Педагоглар һәм методистлар галимнең фәнни эшчәнлеген югары бәялиләр. Профессор Я.И.Ханбиков, мәсәлән, В.Гороховны Татарстанда яңа мәктәп төзүчеләрнең берсе дип атый һәм М.Корбангалиев, Н.Надиев, Н.Мөхетдинов, Л.Җәләй кебек атаклы галим һәм мәгърифәтчеләр белән бер рәткә куя [13]. Бу зур галим һәм педагогның тормышы һәм фәнни эшчәнлеге һәрьяклап өйрәнүгә мохтаҗ.

12. Горохов В.М., Алексеев И.А. Нур: Хрестоматия. Керәшен шкулларының икенче уку җылы өчен уку китабы. — Казан, 1929. — 283 б.

13. Ханбиков Я.И. Основные направления в развитии педагогической мысли татарского народа в X-XX вв.: Автореф. дисс. ... доктора пед. наук. — М., 1968. — С. 20.

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ
ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

ГӘРӘЙ РӘХИМ

(15.07.1941)

ШИГЪРИ ДӨНЬЯМ

Сиңа кайтмаска дип ничә тапкыр инде
Тын дөньяма качтым.
Тик түзмәдем синсез, шигъри дөньям,
Тагын качып кайттым.

Төннәремне һаман синдә кунам,
Сөйгәнемнән качып, –
Илтү өчен аңа сөюемнең
Яңа серен ачып.

Дусларымны сагнып илгә кайтсам,
Мин, алардан качып,
Алар өчен җылы сүзләр эзлим,
Йөрәгемне ачып.

Уют вәгъдә иткән күпме ишек
Мине көткән чакта,
Хәйямнардан калган ишегеңнән
Сиңа кереп качам.

Тыныч бәхет сузып, зур дәрәҗә
Көтә мине кайчак.
Бер шигырең өчен, барсын ташлап,
Тагын сиңа качам.

Миндә үлгәнеңне белсәм әгәр,
Бар сереңне ачып, –
Яши алмам, тизрәк китәрмен мин,
Гомеремнән качып.

*Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

Керәшен гөслә ансамбле

«ГОМУМТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ӨЧЕН МӨҺИМ!»

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Керәшен татарлары һәм нугайбәкләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге җитәкчесе, сәнгать фәннәре кандидаты Геннадий МАКАРОВ белән әңгәмә

– Хөрмәтле Геннадий Михайлович, бүген керәшен татарлары дип без кемнәрне атыйбыз? Тарих күзлегеннән караганда, элек тә татарлар православие динен кабул иткәннәр, хәзер дә андый кешеләр юк түгел.

— Керәшеннәр тарихы һәм мәдәнияте Идел-Урал төбәгендә яшәгән төрки-татар җәмгыятьләре тарихыннан аерылгысыз. Керәшеннәр һәм нугайбәкләр — татар халкының, беренче чиратта, этник мәдәнияте үзенчәлеге булган, икенчедән, рухи мәдәниятләре, православие һәм тәңречелек традицияләре йогынтысында калыплашкан төркеме. Керәшеннәрнең антропологик һәм этник тибы Кама-Идел җирлегендә формалашкан. Хәзерге татарлар православие динен кабул итсәләр дә, алар керәшен була алмый, чөнки этник мәдәният сыйфатлары буыннан-буынга килгән тәрбия традицияләре белән генә күчә һәм аны дин белән генә алыштырып бетереп булмый. Хәзерге чорда керәшеннәрнең тарихына һәм мәдәниятләренә игътибар артты, тик күпчелек очракта керәшеннәр борынгы тарихларын һаман да үзләре үк иҗат иткән төрле мифлар һәм риваятьләр аша гына беләләр. Билгеле ки, тарихны белү — ата-бабалар төзегән йортның нигезләрен ныгытуга ярдәм итә. Керәшеннәр дә тарихлары белән кызыксыналар, аны белергә омтылалар һәм дин кыйммәтләрен Болгар, Алтын Урда, Русия чоры мәдәниятләре белән бәйлиләр, үзләрен төрки дөньяның бер өлеше итеп саныйлар. Төрки христианлыкның чылбыр буыннары күптөрле. Аларда тарихтагы төрле дәверләр чагыла: Үзәк Азиядәге несторианнар; Болгар каласында христиан динен кабул иткән өчен үтерелгән элекке мөселман, хәзер Рус православие чиркәве тарафыннан изгеләштерелгән Авраамий; Алтын Урда христианнары, Гаярь патша Иоанн IV чоры, XIX гасырның икенче яртысында Бәчли әтей (Василий Тимофеев) эшчәнлеге заманы һ.б. Бу чылбыр буыннары, бер өзелеп, бер ялганып, бүгенгә кадәр килеп җитә алган. Керәшеннәр әлеге байлыкның варислары, аларда христиан дине һәм тәңречелек кыйммәтләре тыгыз үрелеп үсеш алган.

– Миңа калса, керәшен татарларының мирасында әле ислам йогынтысы да бар. Геннадий Михайлович, совет чоры руслар, украиннар, татарлар, гомумән, барлык халыклар өчен милли гореф-гадәтләрне саклап калу өлкәсендә зур сынау һәм югал-

Гөсләдә уйнаучы. Дөргә авылы

Тикшеренүче Оксана Степанова һәм башкаручы Мария Морозова. Кибәч авылы. 2007 ел

ту еллары булды. Бу яктан караганда, керәшен татарлары үзләренең бәйрәм-йолаларын саклауда күпләр өчен үрнәк. Әлеге феноменның сәбәпләре нидән гыйбарәт?

— Керәшеннәр — ил белән яшәгән халык. Патша заманында ук алар урысча начар белгән. Исемнәре русча булгач, рәсми документларда христиан булып исәпләнгәч, аларның эчке тормышларына артык тыкшынмаганнар һәм алар ата-бабалары гореф-гадәтләре, йолалары буенча яшәгәннәр. Мөселман кардәшләре белән аралары шактый суык булган, моның сәбәбе дин үзгәлекләренә бәйле. Совет дәверендә дини кысулар, керәшен мәктәпләрен юкка чыгару нәтиҗәсендә, алар үзләренең авыл иле дөньясына бикләнеп яшәгәннәр. Моның өчен колхоз менә дигән мөмкинлек биргән — алар элеккеге авыл иле — общинасындагы — кебек гадәт буенча яшәгән. Дөрес, хакимият Питрау, Торыйсын, Пыкрау, Олы көн бәйрәмнәрен тыярга тырышкан, халык җыелса, аларны милиционерлар куып тарата торган булган, әмма тыелган бәйрәм-йолалар, киресенчә, көч җыйган һәм үҗәтлек белән ныграк башкарылган. Керәшеннәрнең үз йолаларын саклап калулары батырлык түгел, ул — аларның язмышы, Ходайдан килгән тәкъдирдер.

– Бүген керәшен татарлары илебезнең кайсы республика-өлкәләрендә яши? Соңгы ике халык санын алу нәтиҗәләре буенча алар күпме? Сан ягыннан үсеш зурмы?

— 2010 елдагы халык санын алу нәтиҗәләре буенча 34 мең кеше үзен керәшен, 8 мең кеше нугайбәк итеп билгеләгән. Керәшеннәрнең, төрле вакытта төрле сәбәпләр белән күченеп, Удмуртия, Башкортстан, Самара, Оренбург, Чиләбе, Төмән, Иркутск, Красноярск төбәкләрендәге авыл-калаларда да яшәүләре билгеле. Тел үзенчәлекләренә килсәк, керәшеннәр көнкүрештә үз төбәкләренә хас сөйләшләрендә аралаша, гомуммилли мәгълүмат сферасында исә татар әдәби телен кулланалар. Рус теле дәүләт теле буларак мәгариф системасына киңрәк керә бару сәбәпле, хәзер яшьләр арасында рус теле ешрак кулланыла башлады. Дини көнкүрештә керәшеннәрнең XIX гасырның икенче яртысында православ миссионерлар тарафыннан әйләнешкә кертелгән язма-чиркәү теле кулланыла.

– Татарстанда, Башкортстанда, башка төбәкләрдә керәшен

Албай авылы. Мамадыш районы. 2011 ел

татарларының җыр-бию коллективлары эшләп килә. Алар турында да әйтеп үтсәгез иде.

— Керәшеннәр, кайда гына яшәсәләр дә, балаларына, оныкларына тын-ден, белем тәрбиясе бирергә, ана телләрен өйрәтергә тырышалар. Мәдәни-агарту һәм белем бирү йортларында укытучылар, тәрбиячеләр балаларга аталардан калган йолалар, гореф-гадәт нигезләре турында мәгълүматны сеңдерү өчен көч куя. Мондый омтылышның сәбәпләре гади: Россиянең төрле төбәкләрендә сибелеп яшәгән керәшен ырулары үзләренең дини, мәдәни йөзләрен саклап калырга телиләр һәм аталардан калган рухи мирасларын киләчәк буынга тапшыру юлларын эзлиләр. Моның өчен алар хәзерге татар, рус әдәби теле нормаларын белүдән тыш, керәшеннәрнең дини-чиркәү язуын, үзләре яшәгән төбәктәге сөйләм теле үзенчәлекләрен, борынгы халык көйләрен, дини сюжетлы җыруларын да балаларга өйрәтәләр. Ата-бабалардан килгән традицияләрне җуймау юлларының берсе — китаплар чыгару һәм халыкның язма хәтерен ныгыту. Әлбәттә, яшьләребез дә, олыларыбыз да керәшеннәрнең сәнгатен, дини карашларын чагылдырган шигырьләр, җыру, бәетләр, бәйрәмнәр турындагы белешмәләр, керәшеннәрнең җирле сөйләм үзенчәлекләре тасвирланган хәзерге заманга туры килерлек хезмәтләр басылып чыгуын түземсезлек белән көтәләр.

– Әле күптән түгел Бакуда узган Евровидениедә Удмуртиянең Бураново авылы әбиләре ансамбле Җир шары тамашачысының мәхәббәтен яулады. Керәшен татарларының җырлары, биюләре дә шундый халыкара масштабта күрсәтерлек бит. Шушы бәяләп бетермәслек бай мирасны пропагандалау ничек бара? Татарстан, Башкортстан, башка республика, өлкә хөкүмәтләре ярдәм итәләрме?

— Әйе, Бураново әбиләрен карагач, аларның җырлау алымнары, бию килбәтләре керәшен әбиләрен искә төшерде. Удмурт әбиләренең уңышы ул, беренче чиратта, продюсерларының да уңышы. Удмуртия

Республикасы хөкүмәте өчен сөенергә генә кала.

Бураново авылы әбиләре безгә кечкенә халыкның да борынгы җыр традицияләре дөньякүләм игътибарга лаек була алу үрнәген күрсәтте.

– СССР таркалганнан соң, күпсанлы иҗтимагый оешмалар барлыкка килде. Аларның кайберләре инде үз миссияләрен үтәп таркалды, кайберләре һаман уңышлы гына эшләп килә. Соңгы чирек гасырда керәшеннәрне нинди иҗтимагый оешмалар берләштерде? Алар аерым республика кысаларында гына эшлиләрме яки ил күләмендәме? Үзара элемтәләре бармы?

— Керәшен җәмәгатьчелеге 1990 елда «Этнографик мәдәни-агарту җәмгыяте» төзеде, мәдәни һәм дини үзенчәлекләрне тергезү, саклау һәм үстерү буенча шактый эш башкарды. Шушы ук юнәлешне «Керәшен сүзе», аннан соң оешкан «Туганайлар» газетасы да куәтләп тора. Керәшеннәрнең милли-мәдәни хәрәкәтенә барлык татар җәмгыятьләре дә теләктәшлек белдерә. Мөселман кардәшләребезнең мондый күркәм гамәлләре безнең туганлык хисләребезне тик ныгыта гына. Керәшеннәр яшәгән төбәкләрдә дә җәмгыятьләр төзелде. Республикабыздагы керәшеннәрнең ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү, күләмле проектларны тормышка ашыру өчен, 2007 елда Татарстан керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы төзелде. Аны, оешкан көннән башлап, «Ак Барс холдинг компаниясе» ААҖ директоры Иван Михаил улы Егоров җитәкли. Татарстан Президенты Аппаратының этник сәясәт бүлеге катнашында яңа оешма күп кенә мәсьәләләрне уңай чишә алды. Керәшеннәрнең дәүләт статусына ия булган «Бәрмәнчек» фольклор ансамбле төзелде. Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты

Кумырык авылы әбиләре. Мамадыш районы

каршында Керәшен татарлары һәм нугайбәкләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге ачылды. Казанда керәшеннәргә бирелгән Тихвин чиркәве янындагы ике катлы бинада капиталь ремонт үткәргәннән соң, биредә Мәдәният үзәге ачылачак. Хәзерге көндә республика күләмендә Питрау, Торыйсын бәйрәмнәре уздырыла. Быел Керәшен яшьләренең икенче форумы үтте. Нәтиҗәдә, керәшен оешмасы республикадагы милли-мәдәни җәмгыятьләр арасында абруй яулады һәм керәшеннәрнең милли-мәдәни, дини ихтыяҗларын үтәргә, яшь буынга ана телен, милли традицияләрне сакларга ярдәм итә.

– Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Сез җитәкләгән Керәшен татарлары һәм нугайбәкләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәгенең төп эш юнәлеше, максатлары, бурычлары нидән гыйбарәт? Нинди уңышларыгыз бар?

— Керәшен татарлары һәм нугайбәкләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге 2010 елда өч фәнни хезмәткәр һәм лаборант штаты алып эшен башлады. Үзәкнең эше керәшеннәрнең этник һәм мәдәни тарихын, матди һәм рухи мирасын өйрәнү, саклау һәм куллануга юнәлгән программаларны тәэмин итүгә багышлана. Үзәк, беренче чиратта, фәнни-методик һәм координацияләү эшен алып бара торган фәнни оешма буларак күзаллана. Ул гуманитар фән юнәлешенең төрле өлкәләрендә эшләүче галимнәрне, туган якны өйрәнүчеләрне, укытучыларны, мәдәният хезмәткәрләрен Идел-Урал төбәгендә сибелеп яшәгән керәшеннәрнең тарихын өйрәнү, этнография, матди һәм рухи мәдәниятләре үрнәкләрен җыю, тикшерү һәм җәмәгатьчелеккә җиткерү эшен оештыру белән шөгыльләнә. Үзәк шулай ук фәнни хезмәтләр әзерләү, тарих, мәдәният, сәнгать, әдәби иҗат юнәлешләре буенча фәнни-популяр һәм уку-укыту өчен китаплар чыгаруны да планлаштыра.

Үзәкне кызыксындырган фәнни проблемалар арасында керәшеннәр, нугайбәкләрнең христианлык һәм төрки-татар мәдәнияте традицияләрен өйрәнү мәсьәләсе дә мөһим. Минемчә, бу күренеш XVI-XX гасырлар белән генә чикләнми һәм борынгырак тарихи чорларны да үз эченә алырга мөмкин. Әлеге юнәлештә Казан ханлыгы чоры, Алтын Урда, Идел Болгарстаны, Азов-Дунай Болгарстаны дәверләрен өйрәнү планлаштырыла.

Бүгенге көндә мөһим фәнни-тикшеренү темалары арасында «XX йөз башында керәшен интеллигенциясе формалашу», «Керәшеннәрнең һәм нугайбәкләрнең казакчылык тарихы», «Керәшеннәрнең китаби телләре формалашу», «Керәшеннәрнең дини һәм дөньяви мәктәп мәгарифе үсеше», «Керәшеннәрнең китап бастыру тарихы», «Керәшеннәрнең гамәли-декоратив сәнгате» һ.б. бар.

Үзәкне матди-техник чаралар белән тәэмин итүдә безгә «Ак Барс холдинг компаниясе» ААҖ ярдәм итә. Татарстанның, Россия Федерациясенең төрле фәнни, мәдәни, иҗтимагый оешмалары белән элемтәдә торабыз. Анкара дәүләт университетының теология кафедрасы белән бергә экспедицияләр, очрашулар үткәрәбез. Мәсәлән, Анкарада 2010 елның 12-14 маенда теология кафедрасы галимнәре, укытучылары һәм студентлары белән очрашу узды. Анда минем тарафтан керәшен татарлары һәм нугайбәкләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге турында информация бирелде, киләчәктә бергә эшләү турында килешенде.

– Узган ел Татарстан телевидениесе Сезнең нугайбәк авылларына фәнни экспедициягез турында бик кызыклы һәм тирән эчтәлекле документаль фильм күрсәтте. Быел

Чыршылы авылында (Сарман районы) фольклор-этнографик экспедиция барышында тамга үрнәкләре җыйганда.

Түбән өлкәсе «Шытыр-шатыр» фольклор ансамбле белән. Екатеринбург «Түгәрәк уен» фестивалендә. 2011 ел

кайсы төбәкләргә экспедицияләр планлаштырасыз?

— Үзәкнең күзгә күренерлек матур эше итеп кинорежиссёр Салават Юзиев әзерләгән «Возрождая звук» («Тавыш тергезү»), «Путь нагайбаков» («Нугайбәкләр юлы»), «Питрау» исемле документаль фильмнарны әйтергә була. Быел гына «Качману», «Җапрак бәйрәме» күренешләре буенча Питрәч, Әлмәт районнарында яңа материаллар төшерелде. Җәй-көз айларында Татарстанның төрле районнарына, Чиләбе өлкәсенә барырга исәп бар.

– Үзегезнең фәнни казанышларыгыз турында да берничә сүз әйтсәгез иде.

— Бүген безнең Татарстан милли архивы белән берлектә керәшеннәрнең музыкаль фольклор язмаларын электрон форматка күчерү һәм архив сакланышына кую буенча эшләр алып бара. Татарстан Республикасы керәшеннәренең «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамблен музыкаль-этнографик материаллар, халык җырлары, биюләре язмалары, эшкәртмәләре белән тәэмин итү дә безнең өстә.

Ел саен Татарстан керәшен оешмасы белән «Туым җондызы» исемле керәшен җырларын җырлаучы яшь башкаручылар фестиваль-конкурсын гөрләтеп уздырабыз. Фестивальдә төрле милләт вәкилләре катнаша. Бу гамәл белән керәшен җырларының абруен, куллану чикләрен шактый киңәйтәбез, аларның яшәеш көчен ныгытабыз. Хәзерге көндә керәшен җырларын, көйләрен башкаручы балалар фестивален үткәрергә әзерләнәбез, чөнки яшь буынга сәнгатебезне тапшыру механизмын тергезергә кирәк. Шул чакта гына гүзәл яңгырашлы җырларыбызның киләчәге булыр. Без, беренче чиратта, балалар җырларлык репертуар әзерләүдә катнашабыз. Үзәкнең бу гамәлләре керәшеннәр өчен генә түгел, гомумтатар мәдәниятенең төрлелеген, байлыгын саклауга юнәлдерелгән.

– «Яңа мирас» журналы редакциясе эшләрегезнең дәвамлы һәм нәтиҗәле булуын тели. Журнал битләрендә керәшен татарларының һәм нугайбәкләрнең тарихын, бүгенге халәтен, тормыш-көнкүрешен киләчәктә дә бергә яктыртып барырбыз дигән теләктә калабыз.

Әңгәмәдәш —
Илдус Заһидуллин

КЛАРА БУЛАТОВА

* * *

«Питрау үтте — җәйләр бетте», — диләр
Безнең якта халык сүзендә.
Питраудан соң чәчәк атмый гөлләр,
Сары йөгерә кырлар йөзенә.

Питраудан соң яфрак бәйләмиләр,
Мәтрүшкәләр җыеп кайтмыйлар;
Үләннәрдә хуш ис бетә, диләр,
Питраудан соң печән чапмыйлар.

Питраудан соң кош сайраудан туктый,
Ишетелми кәккүк тавышы.
Җирләр сүрелә, кояш көн балкытмый,
Салмаклана тормыш агышы.

Питрау үтте, димәк, җәйләр үтте,
Болыннарга сары йөгерде...
Бу тормышның питраулары җитте, —
Кыл урталай бүлеп гомерне.

ПИТРАУ ЫРУЛАРЫН ҖЫЯ

ГЕННАДИЙ МАКАРОВ,
сәнгать фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының
Керәшен татарлары һәм нугайбәкләр тарихын һәм
мәдәниятен өйрәнү үзәге җитәкчесе

СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАННЫҢ ТӨРЛЕ РАЙОННАРЫНДА ПИТРАУ БӘЙРӘМЕН УЗДЫРА БАШЛАДЫЛАР. ПИТРАУ ИНДЕ ЕГЕРМЕ ЕЛДАН АРТЫК МАМАДЫШ РАЙОНЫНДАГЫ ҖӨРИ АВЫЛЫНДА БӨТЕН ТАТАРСТАННЫ, РОССИЯНЕ ТАҢ КАЛДЫРЫП, ГӨРЛӘТЕП УЗДЫРЫЛА. ЗӘЙ РАЙОНЫНДА КАШКА ТАУ БУЕНДА, ПИТРӘЧ, КУКМАРА, ЧАЛЛЫ, ТҮБӘН КАМА ҺӘМ БАШКА РАЙОННАРДА БУ БӘЙРӘМГӘ КҮП ХАЛЫК КИЛӘ.

Питрауга барлык туган-тумача бергә җыела. Күрешер өчен, туганлык җепләрен ныгытыр өчен, ерак җирләрдән авылларына, бабаларының каберләренә барып зиярәт кылырга дип кайталар алар. Шундый ук христиан бәйрәме русларда да бар, әмма аларда Питрау бу дәрәҗәдә колачлы итеп үткәрелми.

Керәшеннәр өчен Питрау бәйрәменең мәгънәсе, көче нидән гыйбарәт соң? Керәшеннәр христиан булгач, дин тарихында аеруча хөрмәт ителә торган Питер һәм Павал апостолларга атап уздырылган бәйрәмне билгеләү хуп күренеш. Чынбарлыкта аның сәбәбе күпкә тирәндәрәк ята.

Элекке заманнарда бабаларыбыз авылларда община-ил булып яшәгәннәр. Елга бер тапкыр, гадәттә, җәй көннәрендә җыен (ил корылтае) уздырганнар. Анда барлык балигъ яшьтәге ил кешеләре катнашкан. Билгеләнгән көнне катнашучылар илнең җыенын үткәрү урынында түгәрәк ясап утырганнар. Җыенны илнең абызы Тәңрегә теләкдогаларын әйтеп башлап җибәргән. Түгәрәкнең беренче әйләнәсендә аксакаллар, булдыклы ирләр, ил агалары, бай хуҗалар утырган. Икенчесендә гади кешеләр тезелгән. Аннан ары яшьләр һәм ярлылар булган. Беренче түгәрәктәге хәлле, бай агайлар, абруйлы кешеләр аякларын бөкләп утырган. Икенче түгәрәктә хуҗалыкларын мөстәкыйль рәвештә алып бара алган ирләр утырып яисә тезләнеп торган. Өченче әйләнәдә күпчелек яшьләр, балалар, ярлылар һәм еш кына хатын-кызлар басып торган. Мондый өч катлы түгәрәктә ил кешеләрен күрергә һәм ишетергә уңайлы булган. Ил тормышы турында сөйләшү, гадәттә, беренче әйләнәдә утыручылар арасында барган. Икенче рәттәгеләр, сүзгә өстәп, кайбер төзәтмәләр һәм өстәмәләр керткән. Соңгы рәттә басып торучылар шыпырт кына тыңлап торганнар.

Борынгы дәвердә җыеннар һәм туган-ырулык мөнәсәбәтләре көчле булган, игенче общиналарында авылдашлар бергә җир биләгәннәр һәм үзләренең хуҗалыгын алып барганнар.

Җыеннарда ил тормышына кагылган барлык проблемалар каралган, киләчәккә планнар корылган. Җырчы-думбрачылар үткән тарихка кагылышлы батырлар, данлыклы ата-бабалар турында риваятьләр, дастаннар, эпик әсәрләр башкарганнар. Шуннан соң, алдан ук сөйләшеп куелганча, унбишәрләп яисә егермеләп туган чиратлап, өйдән-өйгә кунак булып йөргән. Өй хуҗасы кунакларны сыра, әчегән бал яисә кымыз белән сыйлаганда, бер генә тустаган кулланылган. Хуҗа алдан, тустаганы әзерләнгән һәр туганына үз мөнәсәбәтен белдереп, җыр җырлаган, туганы да җыр белән җавап биргән һәм эчеп куйган. Шуннан җыр әйтешү һәм тустаган күршегә күчкән. Бу борынгы кунак сые йоласы керәшеннәрдә онытылмаган. Мәсәлән, Көньяк Уралда яшәүче нугайбәкләр кунак мәҗлесен җыен, диләр.

Җыеннарның чагыштырмача тулы сакланган тәртибе Казан арты авылларында билгеле. Анда татарларның патриархаль тормышлары белән бәйле шактый күп йола, гореф-гадәтләр катламының эзләре бар. Һәрбер җыенның территориясе билгеләнгән, бәйрәм итү вакыты булган. Җыен җәй көне уздырылган. Ул — һәрбер ыру-нәселнең, туган-тумачаның, кода-кодачаларның очрашу көне. Бу бәйрәмдә олы яшьтәгеләр табын әзерләп җыелганнар. Яшьләр исә түгәрәк уеннарда катнашканнар, күңел ачканнар, яр сайлаганнар һ.б. Керәшеннәрдәге Җыен-Питрау бәйрәме шул вазифаларны үтәгән.

Бәйрәм тәмамлангач, Питрауны җәйнең «чиге» дип билгеләгәннәр, печән өсте башланган, аннары урак өсте җиткән. Керәшеннәрнең ышанулары буенча Тәңре изге Питер Питрау көненнән соң яфракларга төкерә, шуңа күрә Питраудан соң үләннәр үсүдән туктый һәм үсемлекләрнең сихәтләү сыйфатлары бетә. Шул сәбәпле халык дару өчен үлән җыюдан туктаган.

Питрау җыенына туган-тумача, барлык ырулар бергә җыелган, берберсенә рәт йөрешкәннәр. Йола буенча Питрау тәкәсе сую, христианнарның Питрау уразасын бетереп, авыз ачуы белән бәйле.

Питрауда махсус пешерелгән йола ризыгы булып дурычмак саналган. Күке Питрау көнендә дурычмак белән тыгылган, шуңа Питраудан соң ул саташып кычкыра башлый, диләр. Дурычмакны пичтән яшьләргә, кунак кызларына тарату өчен «Күке» дип аталган шаян такмаклар җырлап чыгарганнар.

Тагын бер матур йола булган. Яңа кияүгә чыккан кызлар һәм яңа өйләнгән егетләр Питрауга кунакка килә торган булган. Гадәт буенча Питрау көнендә атасы тормышка чыккан кызына яңа сәнәк һәм тырма ясап бүләк иткән. Йола биюләр һәм җырлар белән дәвам иткән.

Түгәрәк уен яшьләр өчен Питрау бәйрәменең үзәге булган. Питрауда өйләнешергә сүз куешкан яшьләр Пыкрауга туйга әзерләнә башлаганнар.Яшьләр төн буе түгәрәк уенда уйнаган, таң атканда «кояш сакларга» барганнар, кояш нурларының төрле төсләргә кереп «уйнаганын» карап хозурланганнар. Халык ышануы буенча Питраудан башлап Күк чирүләренең сугыш-яу арбалары тавышлары көчле күк күкрәү булып ишетелә һәм кояш бу көнне үзенең йөрешен кыскарта, нурларын балкытып уйната башлый. Аны халыкта «нәҗәгай» яисә «аҗаган», «аждаган», «аждаркан», «аздаркан», диләр. Шулай итеп Питрау көненә күк йөзе үзенең сөенечләрен җибәрә, имеш. Башка борынгы риваятьләр буенча, күкнең төнлә кинәт актырып китүен үтә зур аждаһа / аждаган кошының ялкынлы сулышы дип ышанганнар һәм ашлыклар өлгерүгә уңай тәэсир итә дип белгәннәр.

Питрау уенынннан кайтканда, кызлар кырдан унике төрле чәчәк җыйганнар һәм өйләренә кайткач, ырымы буенча, шул чәчәкләрне мендәр астына салып: «Унике кырдан унике төрле чәчәк, унике җегет! Кеме миңа язылса, төштә миңа күрен», — дип әйткәннәр, иртәгесен төшләрен юраганнар.

Бүгенге көндә Татарстанда керәшеннәрнең мәдәни тормышында уңай үзгәрешләр күзәтелә. Керәшеннәрнең милли традицияләрне, туган телне саклауда, туганлык җепләрен өзмичә, ил җыеннарын үткәрү теләге һаман да бик көчле. Мондый күренеш, һичшиксез, сөендерә һәм бу юнәлештә зурлап Питрау бәйрәмен уздыру борынгы йолаларны тергезүдә мөһим роль уйный.

КЕРӘШЕННӘРНЕҢ «БӘРМӘНЧЕК» ДӘҮЛӘТ ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЕ

АРТУР ПОЛЯКОВ,
Керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле директоры

Керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле — Бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреаты, күптөрле фольклор фестивальләре җиңүчесе. Ансамбльнең этник сәнгать кыйммәтләрен үстерү һәм тергезү юнәлешендә башкарган хезмәте татарларның үзенчәлекле керәшен төркемнәре һәм Көньяк Уралда яшәгән нугайбәкләрнең этник сәнгатен таныту, дөньякүләм гуманитар мәдәнимәгълүмәти кыр киңлегенә чыгаруга зур өлеш кертә.

Ансамбль 2002 елның 11 апрель көнендә Татарстанның беренче президенты М.Ш.Шәймиев һәм керәшеннәрнең иҗтимагый оешма вәкилләре белән очрашуы нәтиҗәсендә төзелгән протокол карары нигезендә оешты. Шул ук елның көзендә Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының Милли сәнгать институтына ансамбльгә иҗади кадрлар әзерләү өчен укырга керәшен студентлары кабул ителде һәм иҗади төркем тупланды. Ансамбльнең җитәкчесе итеп музыка белгече Геннадий Михайлович Макаров чакырылды. Ансамбльгә «Бәрмәнчек» («Кызыл тал», «песиле тал») исеме бирелде, репертуар әзерләнә башланды. Бәрмәнчек —

яз көне иң беренче булып бөреләрен чыгарган тал һәм язгы яңарыш символы.

«Бәрмәнчек» ансамбле борынгы мәдәни мирасыбызның күркәм үрнәкләре — Кама алды, Кама аръягы, Бакалы, Нугайбәк төбәкләре йолалары, җырлары, төрле уен коралларында уйнау сәнгате белән тамашачыларны таныштыра да башлады. Музыка белән бәйле татар фольклор сәнгатен укытуда традицияләр салынмаган чор иде ул вакытта. Мәсәлән, татар халык музыкасы диалектларын укыту алымнары билгеләнмәгән, этник вокал башкару ысулларын укыту мөмкин түгел сыман иде. Ансамбль эшендә Милли сәнгать институты студентлары Сергей Гладков, Алексей Савельев, Оксана Дмитриева, Снежана Абрамова, Римма Никитина, элекке Казан дәүләт педагогика унивеситетының музыка факультетыннан Людмила Степанова (Янеева), шулай ук Казан дәүләт консерваториясендә белем алучы Вера Васильева, Светлана Матвеева бик теләп катнаштылар.

«Бәрмәнчек» ансамбле үзенчәлекле һәм бай репертуар гына түгел, үзенең иҗади йөзен булдырырга тырышты һәм университетта үткәрелгән төрле чараларда, Казан шәһәренең милли-мәдәни җәмгыятьләре оештырган бәйрәмнәрдә даими рәвештә катнашты. Ижау каласына Халыкара традицион музыка кораллары бәйрәме «Инву утчан гур» («Күктән төшкән чык моңы») дип аталган фестивальдә зур уңыш казанды. Финляндия, Эстония, Марий-Эл Республикасы һ.б. төбәкләрдән килгән коллективлар арасында «Бәрмәнчек» ансамбле Татарстан фольклор сәнгатен лаеклы итеп күрсәтте. Ансамбльдә катнашучылар башкаруында гөслә, думбра, нугай курае, сызгычлы кылкубыз кебек борынгы милли уен кораллары көйләренә кушылып башкарылган җырлар үзләренең кабатланмас аһәңнәре белән тамашачыларның күңелләрен яулады.

Ансамбль шулай ук керәшеннәрнең дини җырулары кичәләре оештырды. Туым көне (Раштуа), Олы көн (Пасха) бәйрәмнәренә багышланган славутлар, мактау җыруларын башкару аларны яңадан кулланылышка кертүгә өлеш булды, онытылган традицияләр яңартылды.

«Бәрмәнчек»кә Татарстан Республикасы дәүләт фольклор ансамбле статусы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 11 феврале карары нигезендә бирелде. Татарстан хөкүмәтенең бу карары бүгенге этник сәнгать өлкәсендә керәшен татарларының мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кабул ителде һәм көтеп алган олы вакыйга булды. Г.М.Макаров сәнгать җитәкчесе буларак эшен дәвам итте, бер елдан соң ансамбльнең фәнни

җитәкчесе вазифаларын башкара башлады, башкару стиле юнәлешләрен, репертуарын яңартып тору эшен тәэмин итүне үз өстенә алды. Сәнгать җитәкчесе вазифасын Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә күп еллар җырчы булып эшләгән, ансамбль эшенең нечкәлекләрен тирән аңлаучы Эльмира Вафа кызы Кәшәпова башкара. «Бәрмәнчек»нең беренче директоры Геннадий Григорьевич Максимов булды.

Иҗат коллективының киләчәге турында Татарстан сәнгать осталары тарафыннан күпсанлы фикерләр әйтелде, тәкъдимнәр яңгырады. Көйләрне, җырларны Европа сәнгате югарылыгында башкаруны максат итеп куюны, этник көйләрне эшкәртмичә яисә заманча эшкәртеп, «баетып», чын күңелдән башкаруны, шулай ук

башка «профессиональ» ысулларны тәкъдим итүчеләр булды. Алда торган максатларга ирешүдә этник көйләрне башкаручы иҗади кадрларларның профессиональ әзерлеклеге хәлиткеч роль уйнады.

Җыр, бию, уен кораллары төркемнәре җитәкчеләре итеп фольклор коллективлары белән эшләү тәҗрибәсе булган, этник музыка буенча белемле шәхесләр чакырылды. Ансамбльнең вокаль төркеме белән эшне Казан консерваториясенең этномузыкология кафедрасын тәмамлаган Анна Пётр кызы Васильева башлап җибәрде, бүген Эльза Сабир кызы Шәмсетдинова дәвам итә; музыка коралларында уйнаучылар төркемен башта Айдар Мөҗәһит улы Әхмәтҗанов, соңрак Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Харис Шәрип улы Нигъмәтҗанов җитәкләде, бүгенге көндә Константин Валерий улы Владыкин алып бара; биючеләр төркеменә беренче вакытта Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты укытучысы Оксана Владимир кызы Степанова үз һөнәренең осталыкларына өйрәтте, бүген исә алар Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә күп еллар эшләгән талантлы биюче Григорий Сергеев җитәкчелегендә осталыкларын чарлый.

Ансамбльнең репертуары бай, анда йола җырлары, әйтмешле такмаклар, лирик көйләр бар. Безнең максат — башкарылган әсәрләрнең стиль эчтәлеген беренчел этник сыйфатта бозмый саклап калдыру, аның нәфислеген тамашачыга җиткерү. Көйләрне ике-өч тавышка эшкәртеп «урысчалату» яисә мелизмнар белән бөдрәләтеп «тәфтиләүләштерү» теләге кызыктырып торса да, ата-бабалардан килгән традицияләргә тугрылыклы булып калу кирәк. Репертуарга этник эстрада әсәрләрен дә кертергә мөмкин, дигән фикер бар, чөнки яшьләрнең заманча, адаптацияләнгән халык музыкасына булган ихтыяҗларын исәпкә алу сорала.

Ансамбльнең йөзен булдыруда этник костюмнар мөһим роль уйный. Борынгы кием үрнәкләре, тәңкәле, ювелир бизәкләр ерак гасырларны чагылдыра. Борынгы төркиләргә хас муйтомар, тамакса, дәвәт, әзәрләр, җилән чикмәннәр, яка чылбырлары, беләзекләр борынгы Үзәк Азия киңлекләрен искә төшерә. Бу катлаулы, четерекле, тарихи белем һәм күзаллауны сорый торган өлкәдә художник-декоратор, керәшен киемнәре белгече Валентина Петровна Максимова уңышлы эшли. Аңа бик зур рәхмәт!

Борынгы уен кораллары думбра, гөслә көйләре белән үрелеп барган җырлар бигрәк тә зәвыклы яңгырый, күңел кылларына кагыла. Борынгы кораллар яңгырашы безнең сәнгатебезнең төркилек, кыпчаклык сыйфатларын калку итеп күрсәтә.

«Бәрмәнчек» ансамбле концертлар белән бөтен Татарстанны йөреп чыкты, Башкортстанның Бакалы районында, Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районында булып кайтты. Ул милли сәнгатебезне саклау, пропагандалау эшенә шулай итеп үз өлешен кертә, «Туым җондызы», «Олы көн», «Торыйсын», «Питрау», «Пыкрау» кебек бәйрәмнәр белән сәхнә аша таныштыра.

«Бәрмәнчек» Халыкара мәйдан киңлекләрен дә яулый башлады. 2010 елда «Алтын Мәйдан» халыкара фествалендә катнашып, фольклор ансамбле, вокаль ансамбль, инструменталь ансамбль номинацияләрендә лауреат булды. Шул ук елның көзендә Россиянең төньяк башкаласында «Санкт-Петербург» кунакханәсенең конгресс-холлы залында мәртәбәле концертта чыгыш ясады, тамаша Санкт-Петербург татар диаспорасының концерт сезонын ачу тантанасына багышланган иде. Узган ел IV Дукат-фест Халыкара фестивалендә унбер ил коллективлары арасында Россия вәкиле буларак катнашты һәм Баня-Лука, Сараево, Модрич шәһәрләрендә чыгышлар ясады. Ансамбль башкарган «Чабата», «Ышкып бию», «Тыпырдык», «Чүпләмле» биюләре, борынгы этник көйләр, җырлар алкышларга күмелде. «Дукат-фест» нәтиҗәләре буенча ансамбль Төркия һәм Италиядәге фольклор фестивальләренә чакыру алды.

2001 елның 25 сентябрендә «Бәрмәнчек» «Казаклар станы. Мәскәү — 2011» дип аталган Халыкара фестивальдә чыгыш ясады. Мәскәү консерваториясе профессоры Н.Гилярова, этномузыкология белгече О.Никитенко ансамбльнең казаклар сословиясендә булган нугайбәкләрнең борынгы көйләрен оста башкаруын аерым билгеләп үттеләр.

Бүгенге көндә фольклор өлкәсендә кадрлар әзерләү проблемасы уңышлы хәл ителеп килә. Бәхетебезгә, Казан дәүләт консерваториясендә татар музыкасы кафедрасының бер тармагы буларак этномузыкология юнәлеше бар. Анда студентлар ел саен фольклор экспедицияләренә йөри, борынгы җырларны язып ала, нотага сала, сүзләрнең диалект үзенчәлекләрен сакларга тырыша. Бу кафедра белән хезмәттәшлек җайга салынган, анда белем алучылардан Эльвира Камалова, Лилия Фәхруллина ансамбльдә уңышлы эшлиләр.

«Бәрмәнчек» ансамбле, керәшеннәр традицияләре белән генә чикләнмичә, гомуммилли татар фольклоры җәүһәрләрен саклау юнәлешендә нәтиҗәле эш башкара. «Бәрмәнчек» шушы кыйбланы саклап, киләчәктә дә тамашачыларны яңадан-яңа иҗат ачышлары белән шатландырсын өчен тырышабыз.

УКЫМЫШЛЫЛАР ТУРЫНДА

ГӘРӘЙ РӘХИМ

(Керәшеннәргә шаяру катыш юату сүзе)

...Укыган кеше — чукынган кеше...
...Чукынган кеше — укыган кеше...
Татар үзе бит... Татар үзе бит
Бу гыйбарәне тукыган кеше.

Шулай булгач, син бер дә кимсенмә,
Башың горур тот, көрәш син, яме!
Татар әйтсә, ул хак әйтә инде
Укымышлы, дип, керәшеннәрне.

Әгәр бер абзый сүгенсә сиңа:
«Һай, син чукынчык керәшен!» — диеп,
Җавап бир: «Абзый, дөрес әйттең бит,
Туры оҗмахка керәсең! — диеп, —
Чукынганнарны укыганнар дип
Таныгач инде, гөнаһка кермә —
Чукынмаганнар укымаган дип,
Син үз-үзеңне кимсетә күрмә!»

ӘДӘБИЯТ

Шигырь язган төнне

Дөньядан ничә мизгелгә
Әҗәткә алган көем!
Китәсең кире дөньяга,
Сүзләрдән киеп кием.

Гәрәй Рәхим

КЫСКА,
ӘММА МӨҺИМ НОТЫК

Быел татар әдәбияты классигы, прозаик, драматург, публицист, журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның «Әсәрләр»ен 15 томда басмага әзерләү эше тәмамлана. Бу мөһим эш, 1993 елның 26 апрелендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кабул иткән карар нигезендә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни-тикшеренүләр планына кертеп башкарылды. Язучының язма мирасы, бигрәк тә, мәкаләләре, рәтләп барланмаган, фәнни библиографиясе төзелмәгән хәлдә дә Институт хезмәткәрләре язучы каләменнән чыккан төрле жанрдагы бик күп әсәрләрне эзләп таптылар һәм аларның текстларын хәзерге татар язуында әзерләп томнарга урнаштырдылар. «Әсәрләр»нең I-VIII, XI томнарын Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарды инде, IX, XII, XIV томнары буенча да эш дәвам итә.

Форсаттан файдаланып, без IX томга (аны Э.Галимҗанова, Г.Хөснетдинова, З.Рәмиев төзеде) кертелгән бер текст белән укучыларыбызны таныштырып куймакчы булабыз. Ул мәкалә түгел, ә нотык. 1917 елның 1-10 май көннәрендә Мәскәүдә күпсанлы вәкилләр (делегатлар) катнашында Бөтенрусия мөселманнарының Беренче съезды (корылтае) үткәрелә. «Мәскәү мөселман комитеты» рәисе сыйфатында буларак та Гаяз Исхакый аны әзерләү, үткәрү буенча зур тырышлык күрсәтә, Мәскәү мөселманнары арасында чыгышлар ясый, төрле төбәкләрдән килгән кунакларны — делегатларны кабул итү буенча оештыру эшләре җаелдерә. Съезд утырышларында — мәҗлесләрендә рәислек вазифасын үтәүчеләрнең берсе була, докладлар ясый, бәхәсле мәсьәләләрне чишүгә катнаша. Съездда милләтләрнең киләчәгенә бәйле төп мәсьәлә — Февраль революциясеннән соң Русия федератив дәүләт булырга тиешме, әллә төрки-татарлар, унитаризм кысаларында мәдәни мохтариятләр төзеп, үзләрен саклап калырга тиешләрме? Г.Исхакый рәислек иткән мәҗлестә хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсе дә тикшерелә. Фатыйма Коләхмәдева доклады буенча кабул ителгән резолюция иске фикерле имамнарга ошамаган, аны Коръәнне һәм шәригатьне мыскыллау дип санаганнар.

Корылтайда ун кешедән торган Милли Шураны сайлаганда Гаяз Исхакый башта исемлеккә кертелми кала. Шушы уңай белән трибунага Шакир Мөхәммәдъяров күтәрелә һәм ул: «Бу съездны җыюга бик күп хезмәт иткән һәм аның эшендә армыйталмый йөргән Гаяз әфәндене Милли Шурага сайларга кирәк. Аның кандидатурасын куймасагыз, мин дә сайланудан отказаться итәм, Әхмәдбәк (Салихов) тә отказаться итә,» — дип игълан итә. Моны ишетүгә, мәҗлестә булган эшче сыйныфы вәкилләре һәм солдатлар, «ура» кычкырып, президиум янына киләләр дә Гаяз Исхакыйны зал буенча күтәреп йөртәләр, диелә съезд беркетмәләрендә. Кабат тавыш биргәндә исә аның кандидатурасы иң күп тавыш җыя.

Түбәндә укучыларга тәкъдим ителә

торган нотыкны Г.Исхакый съезд ябылганда сөйли, аны үткәрүнең мәшәкатьле эш булуын искә ала, оештыру эшендәге кимчелекләр өчен ярым җитди һәм үз-үзенә карата ярым шаяру белән делегатлардан кылган «гөнаһлары» өчен түбәнчелек белән гафу үтенә, уңышсыз адымнарының сәбәбен холкындагы «ахмаклык», максатка ирешү юлындагы үҗәтлеге белән аңлата. Нотык авторның съезд барышындагы күңел халәтен ачык чагылдыра. Иҗат психологиясенә бәйле рәвештә моңа охшаш фикерләрне Г.Исхакый «Бер тоткарның саташуы» повестенда да кат-кат ассызыклаган иде. Г.Исхакыйның максатчан үҗәтлек, ныклык (сөбат) илә идеал утын эзләүче, аны тормышка ашыру юлындагы фидакарь шәхес икәнлегенә «Даһига» шигырендә (1913) Габдулла Тукай да игътибар итә иде:

Күз карашыңда синең дөнья күренде мәңге төн:
Киттең эзләп син аны яктыртмага идеал утын.
Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син,
Чын сөбатлә алга бардың, бакмый уңга-сулга син.

Гаяз Исхакыйның Бөтенрусия мөселманнары корылтаеның йомгак утырышында сөйләгән нотыгы, «Рәислек иткән вакытларда кимчелекләрем булса, гафу үтенәм. …Алла моннан соң матур һәм бик төзек съезд насыйп итсен» дигән, җылы юмор һәм ирония белән өретелгән сүзләр белән тәмам була. Җор телле Гаяз Исхакыйның ялкынлы чыгышы күңел күтәренкелеге белән үрелгән көлү тавышларына һәм алкышларга күмелә.

Зөфәр Рәмиев, Резеда Ганиева

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

Мәскәү мөселман халык комитетының рәисе булмак сыйфаты белән һәммәңезне тәбрик итәм. Бу съезд беренче съезд да булганга, йитешмәгән йирләре булды. Моны сөйләп үттек, күземез белән дә күрдек. Ләкин боларны тәхлил итеп карaганда, Мәскәүнең гөнаһысы юк иде. Мәскәүдә мөселман съезды ясалуның максаты гаять олугъ, бу хакта Мәскәү мөселманнарының күңеле саф иде. Бөтен Русия мөселманнарын каршы алырга уйланган иде. Мәскәү мөселманнары бу съездга кулларыннан килгән кадәр фидакарьлекләрене эшләсәләр дә, баласы-чагасы, олугъсы-кечесе, хезмәтчесе — һәммәсе тырышып хезмәт итсәләр дә, һәммәсен съезд ихтыярына бирсәләр дә, кунаклар алып тарлыкка төшсәләр дә,

съезд зур булганлыктан, төрле уңгайсызлыклар тугъды. Наразыйлыклар [ризасызлыклар] ишетелгәләде. Шундый хәбәрләр булды: кайсылары ач калган, кайсыларына торырга квартир табылмаган. Менә шундый уңгайсызлыклар булып, гаепләй торган булсагыз, сездән гафу үтенәбез. Бу кадәр кысынкылыклар хәтергә алынмаган иде, гафу итегез *(Алкышлар).*

Әфәнделәр! Съездны ясарга йөргәндә, бөтен Русия мөселманнарының съездын ясар өчен сезне тора торган авылларыңыздан, илләреңездән, полк вә казармаларыңыздан аерып монда китерүнең гөнаһысы безгә төшә. Мәскәү мөселманнары, ихтиляләль [революция] көннәре башлану белән үк җыелышып, Русия мөселманнарының съездын ясарга кирәк, диделәр. Бу хакта һәм телеграмм да бирделәр. Иң беренче телеграмм бу хакта Мәскәү мөселманнарыныкы булды. Буның өстенә, Мәскәү мөселманнары, Петроградка мөселман фракциясе һәм бюрога вәкилләр йибәреп, тизрәк ясауны тырыштырырга иҗтиһад иттеләр.

Бу залда ун көн бербуйдан төрле мәшәкатьләр күтәрсәңез, монда Мәскәү мөселманнарының гына түгел, минем дә зур гөнаһым бар: моны башлап мин төшендем. Гаебем зур булса да, гафу кыйла торган бер нокта табам: хилкатем [табигатем, яратылышым] буенча ахмаграк бер кеше булганга, бер нәрсәне кирәксенсәм, аны-моны карамастан, шуңа тотынам. Башкаларны да шуңа кушам. Башкаларның аны эшлисе киләмеюкмы, мин алар белән исәпләшеп тормыйм. Минем мәгълүм бер гаяга [максатка], мәгълүм бер идеалга барып тияргә теләвемне һичбер нәрсә туктата алмый. Шуның өчен мин күп мәшәкатьләр дә күрдем. Шулай да яратылмыштан килгән ахмаклыгым һичбер беткәне юк.

Съезд ясалганда да, аны алып барырга тырышуым шулай иде. Бөтен эшләрдә, хәрәкәтләрдә минем тарафымнан сезнең хәтереңезне калдыра торган эшләр булгандыр. Ләкин боларның берсе дә фәлән әфәнденең хәтерен сакламадым яки аның кәефен йибәрер өчен түгел. Мин һәркемнең дәрәҗәсенә күрә монасиб [лаеклы] хәрәкәттә булырга тырышам. Мин йөргәндә бәрелеп китсәм дә, эндәшергә кирәк булса да, эшем күп булып, ашыгыч булганлыктан, онытам. Болар дошманлыктан дип уйланмасын.

Съезд бетте. Күпме эшләнде, азмы эшләнде — анысы икенче мәсьәлә. Өйләреңезгә кайтып йокыдан торгач уйлап карасаңыз, байтак нәрсә хис итәрсез. Туйган булсаңыз да, иншаалла, монда килгәнеңез өчен ахырдан үкенмәссез. Ун еллар үткән соң, сәяси көрәшләр юлга кереп киткәч, сез дә әйтәчәксез: без дә Русия мөселманнарының съездында булган идек дип. Шунда була торган нәрсәләрнең һәммәсе дә мөәррихләр [тарихчылар] өчен зур материал булачак.

Съезд бетте. Безнең залим булып президиум вазифасын үтәвебез дә бетте. Без хәзер рәис булып залим түгел, сез мәзлум түгелсез *(Көлгән тавышлар ишетелә)*. Съездның актык мәҗлесе булганга, беткән хисап итеп, сезгә сәламемне укыйм. Минем рәислек иткән вакытларда 1+ кимчелекләрем булса, гафуыңызны үтенәм. Телеңез беләнме, кулыңыз беләнме, яки башкачамы, сезнең миңа булган гаепләреңез булса, аларын сезнең үзеңезгә багышлыйм. Алла моннан соң матур һәм бик төзек съезд насыйп итсен, дип сүземне бетерәм, вәссәлам *(Алкышлар).*

ЯКОВ ЕМЕЛЬЯНОВ

* * *

Ходай сине илдән алган
Илгә иркен сөйләргә,
Ходай сиңа куәт биргән
Бирелеп чын дин сөйләргә.

Бирелеп чын дин сөйләвеңне
Соңгы көндә аңларлар,
Синең кылган эшләреңне
Вакытында данларлар.

Данларлар аны халыклар,
Үзеңә бар да күренмәс,
Соңгы көндә эшләрең өчен
Бирелгән күңелең сүрелмәс.

Сүрелмәс синең чын күңелең,
Эшләрең данына туеныр,
Соңгы көндә зур эшләрең
Затлы өлгегә куелыр.

Затлар аны өлге итеп
Һәрвакытта сакларлар,
Изге эшне гадел уйлар
Һәрбер чакта якларлар.

«ҖАНГА РӘХӘТ ТУГАН ЯКТАН ЯХШЫ ХӘБӘР...»

(ГАВРИЛА ДЕРЖАВИН ШИГЪРИ МИРАСЫНЫҢ БҮГЕНГЕ ТАТАРСТАН ӘДӘБИЯТЫНДА ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ)

ӘЛФИЯ ГАЛИМУЛЛИНА,
педагогика фәннәре кандидаты, КФУ доценты

Казан — элек-электән төрле традицияләрне үзенә туплаган шәһәр. Шуларның иң күзгә ташланганы — Шәрык һәм Европа әдәбиятлары һәм мәдәниятләренең бергә тоташуы. Шул сәбәпле, тарихка күз салгач, һәр очраклы вакыйганың ниндидер канунилык белән шартлануын аңлый башлыйсың. Мәсәлән, XVIII гасыр бөек рус шагыйре Гаврила Державинның шәхес һәм шагыйрь буларак формалашуында безнең төбәкнең төп җирлек булуы, бары тик алда аталган ике культура кисешкән даирәдә генә шундый әдип үсеп чыга алуы аермачык аңлашыла. Ул — рус әдәбиятында яңа юллар ачучы, шигъри эзләнүләре белән А.С.Пушкинга нигез әзерләүче, әдәби телнең мөмкинлекләрен киңәйтүче, Екатерина II дәверенең бөтен киеренкелекләрен үзенә туплаган зур шагыйрь, дәүләт эшлеклесе.

Казан XVIII-XX гасырлар рус язучыларының тормышында һәм иҗатында зур урын тота. Әйтик, Г.Р.Державин, С.Т.Аксаков, Л.Н.Толстой, В.В.Хлебниковлар Казан гимназиясендә яки университетта белем алган. Икенчеләре — А.Н.Радищев кебекләре — тормышларының иң киеренке вакытларында — сөргенгә китешли кагылып узганнар. А.С.Пушкин, Е.А.Евтушенколар исә биредә язылачак әсәрләренә материал туплар өчен килгәннәр. Е.А.Боратынский, А.М.Горький, В.П.Аксёнов Казандагы тормышлары турында истәлекләр язып калдырганнар.

Без, казанлылар, аеруча горурланабыз: Гаврила Державин — безнең якташыбыз, Казан һәм Лаеш шәһәрләре (дөресрәге — Сокуры яки Кармачи авыллары) аның туган ягы булып санала. Шагыйрь хатларында, истәлекләрендә, шигырьләрендә үзенең туган ягы турында сагынып яза: Казан, Идел, Чулман елгалары, туган ягының имәннәре турында сагыш белән искә төшерә, «Казанда алтын вакытлар агышын» сагына:

Аһ, ул минем тәүге көннәрем бишеге!
Саф чагымның, үсмер чакның изге өе!
Кайчан кабат таң нурында коенырмын
Элеккечә улың булып сине сөеп.
«Арфа» (Р.Харис тәрҗ.)

Рус әдәбиятында язучылар классицизм стиленә өстенлек биргән чакта, Г.Р.Державин үзенең туган ягына, әти-әнисе истәлегенә багышлап лирик шигырьләр иҗат итә. Бу өлкәдә ул лаеклы рәвештә беренче сукмак салучылардан санала. Шагыйрь туган ягына бик еш ягымлы шигъри сәламнәр юллый:

Күңелле лә синең белән бергәләшеп
Тыңлау Ватан турындагы
җыр тавышын...

Г.Р.Державин Казанда егерме яшенә кадәр яши, беренче Казан гимназиясендә укый. Россиянең башка төбәкләрендә яшәгәндә әнисе янына, Сокурыга кайтып йөри (1763, 1773, 1778 еллар), Пугачёв гаскәрләре белән көрәш барган чакта, Казан һәм Оренбург өлкәләренә махсус миссия белән җибәрелә. Әлбәттә, аның бу якларда туып үскәнен дә искә алалар. Г.Р.Державин Казанга губернатор булып кайтырга да риза була, әмма, кайбер сәбәпләр аркасында, бу тормышка ашмый кала.

Үзенең авыр балачагын истә тотып, Г.Р.Державин икенче хатыны Дарья Алексеевна Дьякова белән үзләренең әйберләрен (арфа, язу өстәле, кресло һ.б.) Казан университетына бүләк итә һәм дүрт студентка стипендия бирерлек акча васыять итеп калдыра.

Казанлылар якташ шагыйрьләренә шундый ук ялкынлы мәхәббәт һәм хөрмәт белән җавап кайтара. Г.Р.Державинның вафат булуын белгәч, шагыйрьнең иҗатын сөючеләр, университет каршындагы «Ватан әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте» җитәкчелегендә, Казанда аның һәйкәлен куярга акча җыя башлыйлар, соңыннан бу эшкә Россиянең күп кенә төбәкләрендә яшәүче шигърият сөючеләр кушыла. 1847 елда Казан университетының ишек алдында Г.Р.Державинның халык акчасына коелган һәйкәлен куялар. Аның авторлары — данлыклы скульптор, академик К.А.Тон, барельефчы — скульптор С.И.Гальберг.

Г.Р.Державин үз һәйкәленең язмышын үзе язган сыман тоела. Ул һәйкәле мисалында шигъриятнең мәңгелек мирас булуын искәртә. Ихтимал, Горацийның «Exegi monumentum» («К Мельпомене») мәдхиясен укып һәм 1795 елда аны М.В.Ломоносовтан соң үзенчә русчага тәрҗемә иткәндә, бу юлларының нинди күрәзәлек итү булганлыгы әдипнең уена да кермәгәндер:

Мин үземә шундый һәйкәл куйдым —
гүзәл, бакый,
Металлдан да ныграк,
пирамидалардан да биек;
Давыллар да, яшеннәр дә
сугып ега алмый,
Вакыт агышы да һәлак итмәс аны,
тиеп.
«Һәйкәл» (Р.Харис тәрҗ.)

Шагыйрь мирасының үлемсезлеге рус әдәбиятында, А.С.Пушкин, В.Я.Брюсов, А.А.Ахматова, И.А.Бродский иҗат иткән шигъри «һәйкәлләрдә» дә раслана.

Г.Р.Державин үзенең әсәрләре мәңге сакланачагына чын күңелдән ышана. Хөкемдарларның иң элек кешелекле, әхлаклы булырга тиешлеген, хөкүмәт законнарына әүвәл үзләре буйсынырга тиешлеге турында ачыктан-ачык яза *(«Фелицаның игелекләрен әйтеп салырга»)*. Патшага үз фикереңне «елмаеп әйтү» — зур батырлык *(«Һәм елмаеп патшаларга турысын ярырга»)*. Шагыйрь кешеләрнең рухи камиллеккә омтылуларын, бөтен галәм серләренә төшенергә тырышуларын хуплый. «Аллаһ» шигырендә ул кешене бөек Ходай белән турыдан-туры сөйләшергә лаеклы булырга тиешлеген яклый *(«Аллаһ турында сөйләшергә ачылып китеп»)*. Шагыйрь, классицизмның әдәби кануннарын бозып, югары стиль сөйләменә гади сөйләм сүзләрен кушып, мәдхия белән сатира алымнарын берләштереп («Фелица» һ.б. Екатерина II гә багышланган мәдхияләрдә), үзенең иҗаты белән XIX гасыр башындагы яңа әдәбиятка юл күрсәтә. Ул, билгеле булганча, А.С.Пушкинга зур тәэсир иткән. Шигърияттә яңа эзләнүләрне ул мәңгелеккә юл дип күз алдына китерә: *«Уйнак рус телендә беренче мин җөрьәт иттем»*. Аныңча һәр шагыйрь үз сүзен нык ышаныч белән әйтергә, бернигә дә карамыйча, үз юлыннан туры барырга тиеш:

Йа Муза!
Хаклы казанышың белән горурлан,
Кем санлашмый синең белән,
син дә аны читкәр;
Тәкәллефсез, ашыкмаучан
ныклы кулың белән
Маңгаеңа үлемсезлек
таңын таҗың иттер.
«Һәйкәл» (Р.Харис тәрҗ.)

Г.Р.Державинның «Һәйкәл»ендә әйткән васыятьләре тормышка ашты, әмма аның Казандагы һәйкәле язмышы бик гыйбрәтле, маҗаралы. Беренчедән, ул «сәяхәтче» булып чыкты: үз ихтыярына каршы диярлек, урынын өч тапкыр үзгәртте: 1871 елда аны Казан шәһәренең гүзәл бер урынына — шәһәрнең үзәгендә торган гомуми бакчага күчерделәр, соңыннан искиткеч матур Державин бакчасына әверелде (ул хәзерге вакытта Ирек мәйданында урнашкан М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры урынында була). И.А.Гончаров, Ф.И.Шаляпин, А.М.Горький истәлекләренә караганда, бу һәйкәлнең тирә-ягы һәм аның исемен йөрткән бакча казанлыларның ял итәргә яраткан урыннарының берсе булуы әйтелә. Татарлар, һәйкәлне үз итеп, аңа «Бакыр бабай» дигән рәсми булмаган исем кушалар. Әмма XX гасырның 30 нчы елларында «Екатерина әби патшаның җырчысы», аңа һәм аның морзаларына багышлап мәдхияләр язучы, патшаларның хезмәтчесенә (хөкүмәт казначее, сенатор, юстиция һәм таможня министры) шәһәр уртасында шундый һәйкәл булырга тиеш түгел дигән карар кабул ителә. 1931 елда «Бакыр бабай» юкка чыгарыла. Ә бит һәйкәл Г.Р.Державинның дәүләт эшлеклесе булуын түгел, аның шагыйрьлеген чагылдыра. Шуны күздә тотып, үлемсез шигъри иҗади мирасына лаеклы бәя биреп, 2003 елның ноябрендә, Г.Р.Державинның 260 еллык юбилее көннәрендә, һәйкәлне яңа урында — Казанның үзәгендә — М.Горький урамындагы матур бер бакчада яңадан торгызылды (XIX гасыр скульпторларыннан күчереп эшләүчесе М.Гасыймов). 2003 елның 14 июлендә Лаеш шәһәрендә шулай ук Г.Р.Державинга һәйкәл куелды. Аныңсын да шул ук скульптор иҗат итте.

2000 елдан башлап Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан (ул вакытта — Татарстан Язучылар берлегенең рәисе — Ф.Г.Галимуллин), Лаеш районы җитәкчеләре белән

берлектә, рус телендә иҗат итүче язучыларга ел саен Г.Р.Державин исемендәге махсус премия бирелә. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге, Лаеш районы җитәкчелеге һәм Россиянең әдәби фондының бердәм карары нигезендә, 2010 елдан башлап Г.Р.Державин исемендәге әдәби премиягә Бөтенроссия премиясе статусы бирелде. Ел саен илебез күләмендә Казанда һәм Лаешта Г.Р.Державинга багышлап шигъри фестиваль уздырыла. Бу бәйрәмнең дәрәҗәсен үстерүгә, әдәби премиянең статусын күтәрүгә республикабызның ул вакыттагы мәдәният министры Зилә Вәлиева, Татарстан Язучылар берлегенең ул вакыттагы рәисе шагыйрь Илфак Ибраһимов, рус телле язучылар белән эшләү һәм әдәби тәрҗемә бүлеге җитәкчесе шагыйрә Лилия Газизова зур өлеш керттеләр.

Бу чаралар Г.Р.Державинның мирасын киң җәмәгатьчелеккә таратуда ярдәм итә, шагыйрьнең тормыш юлын, иҗатын фәнни өйрәнүгә зур мөмкинлек тудыра, гомумән алганда, XVIII гасыр рус язучыларының иҗатларын хәзерге фән таләпләреннән чыгып бәяләү юлларын ача. Боларга бәйле рәвештә, Г.Р.Державин иҗатыннан алып, үсә башланган рус әдәбияты традицияләрен һәм бүгенгесен күзаллауда яңадан-яңа ачышлар ясала.

Г.Р.Державинның татарлар арасында туып үсүе, татарлар белән якын аралашуы һәм аның татар телен Казан гимназиясендә өйрәнүе үзенең тәэсирен ясамый калмаган, билгеле. Шагыйрь, җае чыкканда, үзенең татар морзасы — Ибраһим (Бәгърим) онысы икәнен дә искәртеп тора. Моны шигырьләренә дә үткәрү җаен таба. Әйтик, «Фелица», «Видение мурзы», «Благодарность Фелице» шигырьләрендә морза онысы исеменнән сүз йөртә. Моның белән, бер яктан, шәрык колоритын булдырырга теләсә, икенче яктан, бу борынгы бабаларына зур хөрмәт күрсәтү билгесе булып тора. «Тончию» шигырендә ул: *«Җил-давыллар җиңеп, тауга менә барыйм, / Һәм күренсен бозлы якта туганлыгым, Ерак бабам булганлыгы морза Бәгърим»*, — ди.

Санкт-Петербургта Г.Р.Державинның архивында бер кызыклы документ саклана. Шагыйрь кушуы буенча тәрҗемә ителгән дүрт татар шигыре ул («Бохар җыры», «Дөньяви җырлар», «Яклау сорап ялвару» һәм «Исемсез»). Бу текстлар рус шагыйренең татар фольклоры һәм татар халкының язма мирасына игътибарлы булуын күрсәтә. Әдипнең яшь чагында, Казан гимназиясендә укыганда, укытучысы М.И.Верёвкин җитәкчелегендә аның борынгы Болгар шәһәренә археологик экспедициягә барганлыгы билгеле. Татар җырлары гарәп графикасыннан кириллицага күчерелгән һәм шунда ук русчага тәрҗемә ителгән.

Әдәбият галимнәре Х.Ю.Миңнегулов, Ш.А.Садретдинов бу җырларның авторы Оренбург якларында яшәп иҗат иткән данлыклы шагыйрь Габдессәлам (1700-1766 еллар) дип билгелиләр. Ул — ахун, укытучы-мәгърифәтче, Батыршаның остазы [Х.Ю.Миңнегулов, 2010, Ш.А.Садретдинов, 1993]. Г.Р.Державин үзенең иҗатында татар җырларын турыдан-туры кулланмаса да, алар аңа шәрык төсмерләрен чагылдырырга булышкан. Г.Р.Державинның шигырьләрендә Казан мәңгегә балачак бишеге, җуелган, әмма ялкынлы рухи идеал булып кала.

Г.Р.Державин иҗаты шактый вакытлар татар әдипләре, язучылары, тәнкыйтьчеләренең игътибарыннан читтә кала. Беренче тапкыр рус шагыйренең исеме 1908 елда Фатих Кәриминең (тәхәллүсе — Каләм) рус әдәбиятының тарихына багышланган мәкаләсендә искә алына. Автор сүз башында үзенең зур нияте турында әйтә, ягъни укучыларга борынгы чорлардан башлап М.Горькийга кадәр рус әдәбияты белән таныштырырга вәгъдә итә. Өченче мәкаләсен М.В.Ломоносов һәм Г.Р.Державин иҗатлары белән танышырбыз дип тәмамласа да, дүртенче

мәкаләсен нindидер сәбәпле бастырмый кала. Әлеге мәкаләләрнең татар телендә чыга торган журналда басылуы очраклы түгел. Бу татар әдәбиятының яңа типтагы мәдәнияткә омтылуына өстәмә дәлил булып кабул ителә.

XX гасыр башында татар әдәбиятчылары рус сүз сәнгатенә игътибарны арттырсалар да, рус язучылары әсәрләре татар теленә шактый тәрҗемә ителсә дә, Г.Р.Державинның шул замандагы тәрҗемәләрен без таба алмадык. Шуңа нигезләнеп, татар язучылары һәм укучылары Г.Р.Державинның иҗаты белән рус телендә генә танышa алган дигән нәтиҗәгә килдек. Дөрес, уку-язу танучылар әле XX гасыр башында татар халкы арасында бик аз була, шуңа күрә татар шагыйрьләренә Г.Р.Державинның йогынтысы булмаган дип әйтергә мөмкинлек туа. Шул ук вакытта Г.Р.Державин һәм XVIII йөздә яшәгән башка рус язучыларының татар әдипләре иҗат иткән әсәрләр белән типологик яктан якын булган очракларны өйрәнү, рус һәм татар мәгърифәтче язучыларының әсәрләрен чагыштыру, яңа жанр төрләрен куллану үзенчәлекләрен фәнни өйрәнү — алдагы көн әдәбиятчыларының бурычы.

Бу юнәлештә беренче юл салучылардан Казан федераль университеты профессоры Х.Ю.Миңнегулов «Даһи шагыйрь татарча уйлаган» дип аталган мәкаләсендә Г.Р.Державинны «руслашкан татарларның ул иң данлыклы вәкиле», дип атый [Х.Ю.Миңнегулов, 2010]. Галим Г.Р.Державинның «Грозный яки Казанның яулап алынуы» (1814) трагедиясендә, «Добрыня» драматик әсәрендә һәм «Сөембикә турында шигырьләр»ендә татар риваятьләрен кулланганлыгын әйтә. Х.Ю.Миңнегулов Г.Р.Державинның иҗатын шәрык, татар әдәбияты контекстларында өйрәнүнең алдагы көннәрдә яңа ачышларга китерәчәген, Г.Р.Державин шигырьләренең борынгы татар әдәбияты белән генетик якынлашулары мөмкин булуын искәртә.

Безнең заман Казан шагыйрьләре Г.Р.Державинның иҗатына зур игътибар бирә: кайсыбер юллар һәм өземтәләр аерым әсәрләрдә кулланыла, реминисценцияләр, аллюзияләр, интертекстуаль бәйләнешләр аркылы искә төшерәләр. Аның «Арфа» шигыре аеруча еш искә алына. Мәсәлән, Н.Н.Беляев «Язгы, яшь, акылсыз җил искәндә...» («Весенний, молодой, безумный ветерок...»), С.В.Малышев «Ай астында» («Под Луной») әсәрләрендә Г.Р.Державинның *«Казанда алтын вакытлар агышын»* җөмләсен куллана. Н.Н.Беляев, Г.Р.Державинның «Арфа» шигыренең төп мотивын — лирик геройның үзенең балачагын искә алганын искәртеп, үз әсәрендә Казанның үткәнен, бүгенге көнен һәм киләчәчен берләштереп сурәтли [Как время... 2005: 61]. Г.Р.Державинның шигыре безнең заман кешесенә рухи таяныч булып тоела. Н.Н.Беляев үз шигырендә XVIII гасыр шагыйренең яраткан темаларын да искә төшерә: тормыш һәм үлем, шагыйрь һәм аның җәмгыятьтә тоткан урыны. Безнең заман шагыйре зур өмет белән киләчәккә омтыла, чөнки аның өчен кыйбла булып Г.Р.Державинның *«Ул җыр ишеттерә яз килүен / Казанда алтын вакытлар агышын»* дигән оптимистик юллары тора.

Вакыт образын С.В.Малышев та «Ай астында» исемле шигырендә искә ала. Аның өчен Г.Р.Державинның шигъри юллары бер үк вакытта «авыр да һәм бик гүзәл дә» булып тоела. Мәңгелекне сурәтләгәндә, җилбәзәк Казан образына Ай образы капма-каршы куела, шул ук вакытта Казанда элеккечә *«Мизгелләр җиңел генә гасырларга күчә, / Ә гасырлар агышы бик җитез»* (сүзгә-сүз тәрж.).

Шигъри һәйкәл темасын Лилия Газизова күтәрә. Ул «Державинга һәйкәл ачылуга багышлап» («На открытие памятника Державину») шигыренең исемендә үк данлыклы рус шагыйре белән сүз башлый, аның «Һәйкәл» шигырен искә алып, әдипнең тагын бер

яраткан темасын искә төшерә. Ул упкын, *«вакыт дәрьясы ... алып китә инсан эшләренең барын...»* (Р.Харис тәрҗ.). Л.Газизова шагыйрьнең иҗади мирасы упкынга да, вакыт агымына да буйсынмый дигән нәтиҗә ясый. Г.Р.Державинның һәйкәле — ул Шагыйрь һәйкәле, дәүләт эшлеклесенеке түгел. Ул уттан яшәреп чыга. Л.Газизова вакыт образында узган вакытны (һәйкәлне җимергән чакны), бүгенгесен (шагыйрь үз урыныннан карап тора) һәм киләчәген берләштерә (аның янында булачак очрашуларга өмет). Мондый мисалларны Казанда яшәп иҗат итүче шагыйрьләрнең әсәрләрендә күпләп табарга мөмкин.

Ә.Х.Мушинский үзенең «Шәех һәм йолдыз санаучы» романында Г.Р.Державинның һәйкәлен җимерү вакытын сурәтли һәм төп герой Николай Новиковның рус шагыйренең һәйкәлен саклап калырга тырышканын күрсәтә. Герой өчен ул бик зур рухи сынау булса да, ул аны үзенең намусына кызыллык китермәслек итеп үтә. Әле һәйкәлне тергезү турында сүз алып барыр чакларга ерак булса да, язучы әсәрдә үзенең фикерен ачыктан-ачык әйтә. Нәкъ шундый ук максат белән Равил Бохараев «Вокруг Тукая (комментарии к любви)» («Тукай тирәсендә (мәхәббәткә аңлатма)») исемле поэмасында Г.Р.Державинның һәйкәлен вакыт белән сөйләшү контекстына кертеп җибәрә. Поэманың сюжеты ике төрле заманда бер үк вакытта бара: Казанда 1912 елда һәм Мәскәүдә 1983 елда. Г.Тукайның тормышы, иҗаты татар һәм рус әдәбиятлары аркылы тикшерелә, рус һәм татар әсәрләре, мәдәният күренешләре хакында ике яклы әңгәмә коралар. Ул әңгәмәдә А.С.Пушкин, Г.Р.Державин, Г.Тукай әсәрләре аралашалар, яңа мәгънәләр тудыралар. Әңгәмәдән аңлашылганча, Г.Р.Державинның һәйкәле 1912 елда Казан урамында Г.Тукайга һ. б. образларга карап тора.

Р.Бохараев үзенең поэмасын 1983 елда яза, әле шагыйрьнең һәйкәлен яңадан куярга 20 ел кала, Г.Тукайның һәйкәле 1912 елда әле куелмаган. Автор укучыларын кисәтеп куя: монда аңа һәйкәл куелачак. Рус язучылары белән чагыштырып, Р.Бохараев Г.Тукайның үз юлы булганын исбат итә, аның бөеклеген күрсәтә, шул ук вакытта рус язучыларына яңа бәя бирә. Беренче чиратта, бу Г.Р.Державинның иҗади мирасына кагыла, ул чын шагыйрьнең символы буларак та сурәтләнә.

Бүгенге көндә Г.Р.Державин татар телендә дә еш яңгырый. 2003 елдан башлап Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис ел саен яңа тәрҗемәләр белән укучыларны таныштыра. Аның тәрҗемәләре тематик яктан бик бай. Шулай итеп, безнең якташ — рус язучысы үз бабасының телендә камил яңгырый: «Хөкемдарларга һәм судьяларга», «Кошчыкка», «Шук теләк», «Вакыт дәрьясы үзенең агымында» (2003), «Тончига» (2004), «Аллаһ» (2005).

Г.Р.Державин 81 нче псаломны тәрҗемә иткәндә, югары гражданлык пафосын белдерә, җәмгыятькә хыянәт иткән хөкемдарларның һәм судьяларның законнарны үтәмәүләрен фаш итә, үлемнең барлык кешеләргә дә тигез килгәнен исләренә төшерә, Аллаһның иң югары хөкеме белән кисәтә. Р.Харис төгәл тәрҗемәдән баш тарта, ул, метафора һ.б. поэтик алымнарны кулланып, Г.Р.Державинның төп фикерен саклап, рус шагыйренең образларына татарча тиңдәш эквивалент таба. Г.Р.Державинның шигырьләре татарчада көчле, үткен яңгырый, шуның белән күңелгә барып җитә: *«Бурычыгыз сезнең — кануннарны саклау, / Көчлеләрнең кемлегенә карамыйча, / Ятимнәрне һәм толларны беркайчан да / Ярдәмсез һәм яклаучысыз калдырмыйча...»*

Р.Харис хәзерге татар телендә инде кулланылмый торган югары сүзләрне дә сирәк кенә булса да контекстка кертеп җибәрә, югары интонацияне саклаганда, төрле ысуллардан файдалана: *«бәбәкләрен ришвәт...», «языклыр».*

Күптөрле риторик сораулар, өндәүләр югары интонацияне сакларга ярдәм итә. Икенче строфада Р.Харис оригиналда булмаган «беркайчан да» сүзен өсти, шуның белән инкарь итүнең көчен арттыра, паузаның урынын көчерү дә шул ук вазифаны үти: *«Бурычыгыз сезнең: бәлаләрдән йолу / гаепсезне, бәхетсезгә терәк булу...»* Шундый үзгәрешләр кертсә дә, Р.Харисның тәрҗемәсе оригиналга якын яңгырый. Татар теленә тәрҗемә иткәндә, Р.Харис оригиналның строфикасын саклый, шул ук вакытта ямб белән язылган рус шигырен татар шигъриятенә хас булган силлабик юллар белән тәрҗемә итә. Г.Р.Державинның күп кенә фикерләре, фәлсәфи уйланулары татар шагыйренең үз иҗатына да хас. Р.Харис, тәрҗемәче буларак, оригинал текстка бик сак карый, Г.Р.Державинның стиль үзенчәлекләрен сакларга тырыша.

Күргәнебезчә, Г.Р.Державинның иҗаты һәм тормышы безнең әдәбиятта һәм мәдәниятта үз урынын саклап килә. Г.Р.Державинның туган көненә багышлап ел саен уздырылган тантаналы чаралар, шигъри фестивальләр илебезнең төрле төбәкләреннән бик күп кунаклар җыя. Үтеп бара торган 2012 ел юбилей алды елы гына булса да, чаралар зурлап уздырылды. Ике елга бер оештырыла торган конференция дә югары дәрәҗәдә әзерләнде. Халыкара фәнни конференция статусын алган гыйльми чарада чит илләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән йөздән артык галим катнашты. Кунаклар Франция (Париж), Төркия (Истанбул), Белоруссия (Минск, Брест) һәм Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Саратов, Ульяновск, Самара, Алабуга, Мурманск, Петрозаводск, Екатеринбург, Бозаулык (Оренбург), Түбән Новгород, Череповец, Киров, Тамбов, Тверь, Кемерово, Барнаул, Магнитогорск, Яр Чаллы, Елец, Рязань, Кемь һ.б. шәһәрләрдән килделәр.

Быел 2012 елның 21 июнендә Лаеш районы туган якны өйрәнү музееның вестибюлендә Г.Р.Державинның һәйкәлен ачу тантанасында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм данлыклы рус шагыйренә туган иленнән (Чулман буе) сәлам буларак китереп утыртылган имәннәргә Чулман елгасы суын сипте. Шулай итеп, быел Г.Р.Державинга багышланган чаралар инде Санкт-Петербургтан аның туган иленә — Татарстанга да килеп җитте. Казан һәм Лаеш шәһәрләре Г.Р.Державинга сәламнәрен шулай һәрчак җиткереп торыр.

Әдәбият

1. Галимуллина А.Ф. «Звучи, о арфа! Ты все о Казани мне!» (Казанская тропа к памятнику Г.Р.Державина) // Русская словесность. — 2006. — №3. — С.14-20.
2. Бухараев Р.Р. Вокруг Тукая (комментарии к любви) — Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. — 128 с.
3. Державин Г.Р. Сочинения с объяснительными примечаниями Я.К.Грота, тт. I-IX. — СПб.: Изд. Академии наук, 1864-1884. — Т. I, III.
4. Державин Г.Р. Сочинения. — Л.: Худ. лит., 1987. — С.29-32.
5. Западов А.В. Мастерство Державина. — М.: Сов. писатель, 1958. — 258 с.
6. «Как время катится в Казани золотое...»: Антология русской поэзии Казани. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. — 480 с.
7. Миннегулов Х.Ю. «Его гений думал по-татарски» (Размышления о Г.Р.Державине) // Фәнни язмалар. — 2008: фәнни мәкаләләр җыентыгы. — Казан: Ихлас, 2010. — С. 167-176.
8. Мушинский А.Х. Шейх и звездочёт. Роман. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. — 286 с.
9. Садретдинов Ш.А. Татарские стихи в архиве Державина // Г.Р.Державин: Личность, творчество, современное восприятие. Тезисы Международной научной конференции, посвященной 250-летию со дня рождения поэта (Казань, 26-29 мая 1993 года). — Казань: Изд-во КГУ, 1993. — С.42-44.
10. Харис Р. Аллаһ / Р. Харис // Мәдәни җомга. — Казан, 2006 — №16. — 28 апр. — Б.12.
11. Харис Р. Переводы стихотворений Г.Р.Державина / Р.Харис // Мәдәни җомга. — Казан, 2003. — 11 июль. — Б.14.
12. Харис Р.М. Переводы стихов Г.Р.Державина на татарский язык // Державин Г.Р. Стихотворения / Сост. и авт. вступ. ст. Л.Р.Газизова. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2010. — С.103-118.

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

И керәшен, карендәшем минем,
Халкымның бер асыл бизәге.
Синең көйне бер тыңлаганнарның
Гомерлеккә өзелә үзәге.

Гәрәй Рәхим

КАЗАН АРТЫ КЕРӘШЕННӘРЕНЕҢ ТАБЫН ҖЫРЛАРЫ

ЗОЯ КИРИЛЛОВА,
филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты

Татар халкының милли характерына хас күркәм бер сыйфаты — кунакчыллыгы, дусларча тату яшәүгә, кардәшлек һәм бердәмлек тойгыларына хөрмәте — чагылыш алган [1] табын җырлары керәшен татарларының җыр сәнгатендә әһәмиятле урын алып тора. Кунак табыны, якыннарны бергә җыйган аш-су мәҗлесе, гаилә бәйрәме яисә туй вакытында туганнар һәм дусларның аралашуы җыр белән үрелеп бара, бу исә мәҗлесне тагын да ямьлерәк һәм кызыклырак итә.

Табында хуҗа һәм кунакларның бер-берсенә матур теләкләр белән җыр әйтешүе, күмәк җыр — керәшен татарларының һәр төркеменә дә хас күренеш, ата-бабалардан калган матур традиция. Язмабызда тикшереләчәк табын җырлары Балык Бистәсе районының Казак Чаллысы һәм Иванай авылларында тупланды. Әлеге авыллар керәшеннәрнең тел

үзенчәлекләрен һәм йола иҗатын төрле яклап өйрәнгән күренекле галимә Ф.С.Баязитова тарафыннан Казан арты сөйләшенең Чулман буе диалектына кертелә [2]. Әмма шунысын искәртеп үтү мөһим: керәшен татарларының башка төбәкләрдә яшәүче карендәшләре белән аралашып яшәве, моннан тыш керәшен җырларының татар халык иҗаты җыентыкларында [3] һәм кайбер вакытлы матбугат битләрендә урын алуы нәтиҗәсендә, табын җырларының саны арта, ә аларның билгеле бер төбәккә хас икәнлеген күрсәткән билгеләре исә югала бара.

Керәшен татарлары мәҗлесләрендә башкарыла торган җырларны эчтәлекләре һәм эзлеклелеге ягыннан берничә төркемгә берләштерергә мөмкин: олылар хөрмәтенә башкарыла торган җырлар, туганнар яки дусларга багышланган җырлар, аш бирү җырлары, тау итү җырлары һәм табынны тәмамлау җырлары. Шуларның һәрберсенә тукталып үтик.

Һәр табын иң элек олылар хөрмәтенә җырлау белән башланып китә. Әлеге җырлар ярдәмендә мәҗлестә катнашучылар әти-әниләргә һәм, гомумән, өлкәннәргә үзләренең рәхмәтләрен, хөрмәт хисләрен белдерәләр:

Безнең өстәлләргә шул килешә:
Чүпләп кенә суккан ашъяулык.
Ашыйк, ай, әле без, эчиек —
Олылардан калган ашамлык.

Безнең әтекәйнең капкасы
Чыршы-нарат белән тактасы.
Бу ашаганнар, бу эчкәннәр —
Бар да әткәй-әнкәй аркасы.

Безнең әнекәйләребез бик әйбәт,
Әтекәебез кыйбатлы.
Әткәй дә әнкәй аркасында
Безнең башкынаебыз хөрмәтле.

Күләме ягыннан иң зур катламны тәшкил иткән икенче төркем — туганнар яки дуслар хөрмәтенә башкарыла торган җырлар. Нигездә хуҗа һәм кунакларның кара-каршы җырлашуы рәвешендә алып барыла, шулай ук кунакларның үзара җыр әйтешүе яки күмәкләшеп җырлау формаларын да алырга мөмкин. Әлеге төркем җырларда күптөрле хис-тойгылар, теләк-омтылышлар чагылыш таба. Мәсәлән, шуларның кайберләре:

— туганнарны сагыну: «яндый тәрәзәләрдән күзем алмый, сез булдыгыз минем көткәнем», «быел Мәкәрҗәләргә мин бармадым, сезне бер күрерләргә алҗадым», «ерак араларны якын итеп, сагынып килдек без күп җирдән» һ.б.:

Агыйделгә бадъян салдым
Тармак-тармак үрергә.
Ике күзем тилмерде инде
Сез туганнарны күрергә.

— кунаклар килгәнгә шатлану: «чакырган кунаклар килгәч, безнең күңел булды инде», «җыен туганнар безгә килгәч, ямьнәр керде эткәйәнкәй йортына», «сез кодалар белән күрешкәчтен, йөзләремә сыймады шатлыгым» һ.б.:

Кырга чыксам, исем китә
Алма агачы иелүләренә.
Үземә үзем хәйран булам
Сезне күргәч сөенүләремә.

— ярату, якын итү: «бу җырымны җырлыймын мин җаным сөйгән туганга», «сезнең өчен минем җаным өзелергә торган җеп кебек», «илләрдә кеше бикләр күп, сездән башкалары ошамый» һ.б.:

Туганнарым, сезгә ни бирим —
Мәкәрҗәдән килгән малым юк.

Җаным ярып бирер идем —
Җандин башка торыр хәлем юк.

— туганлыкның кадерен белү, дус-тату яшәү теләге: «без барыбыз да берләр туган, бер-беребез өчен үлиек», «юлларга чыксак, юлыбыз уңар, аерылмас туганнар булыек», «әз гомернең эчләрендә сүз китерешмик берләр беребезгә», «араларга дошман кертмичә, бергә йөрик гомер эчендә» һ.б.:

Бу дөньялар яралганда,
Кемнәр йөргән аклар өләшеп?
Ашаган бетә, кигән туза,
Утырыйк бергә лә сөйләшеп.

Әлеге төркем җырларда кунаклар яки хуҗа хөрмәтенә бик күп мактау сүзләре әйтелә, аларның төрле сыйфатлары ассызыклана:

— күркәмлекләре: «буегыз койган шәм кебек, йөзләрегез тулган ай кебек», «йөзләреңдә кояш уйный, ай гына куймаганнар», «мәкнең алсу чәчәге күк күземә күрендегез» һ.б.:

Кара урманнарны өч әйләндем
Кара сусарларның эзеннән.
Карасам, күзем ала алмыйм
Сез туганнарның нурлы йөзеннән.

— нәселләренең затлылыгы: «безләр кызыгызны шуңа алдык, нәсел-ырулары затлы дип», «килгәннән бирле карап торам: сез кайсы пәйгамбәрләрнең нәселе?», «яхшы ата баласының сүз сөйләшүләреннән билгеле» һ.б.:

Каралты түбәләрем ачылды,
Бастырмалар куйгач басылды.
Килгәннән бирле карап торам:
Сез барыгыз да шушылай асылмы?

— тәмле телләре: «йөзләрегездә нурлар уйный, телләрегез җомакай (оҗмах — З.К.) ачкычы», «шикәрләрдән тәмле, балдан татлы тел тибрәтеп әйткән сүзләрең», «сезләр белән сөйләшергә җепәкәйдәй тасма тел кирәк» һ.б.:

Агыйделкәйләрнең буена
Балыккайларга сөкә салгансың.
Бу кадәр тәмле сүзләреңне
Умарталар ачып алгансың.

— өстәлләренең муллыгы, ризыкларының тәмлелеге: «безнең кодаларның өстәлендә ни ашыйсың килсә, шулар бар», «безнең туганнарның өстәлендә өч көн ашап-эчсәк тә җитәрлек», «монда ашаганның, монда эчкәннең гомер буе бетмәс тәмнәре» һ.б.:

Өстемдәге күлмәгемнең
Утә чыккан зәңгәре.
Аш-суыгыз бигрәк тәмле —
Айсыз бетмәс тәмнәре.

Җыр ярдәмендә мәҗлестә катнашучылар бер-берләренә күптөрле матур теләкләр әйтәләр: «йөргән юлларыңда яхшы йөре, сокланмаган кеше калмасын», «бай да булсын, сау да булсын бу ашларның иясе» һ.б.:

Болыннарга чыгам, чәчәк җыям,
Чәчәк белән тула кулларым.
Чәчәк кебек матур булсын иде
Алгы тормышыңда юлларың.

Табын җырларының алдагы төркемен аш бирү җырлары тәшкил итә. Туй мәҗлесе вакытында алар күбрәк җырлана, чөнки хуҗаларның сыеннан тыш кодалар һәм хуҗаның якын туганнары үзләренең күчтәнәчләре белән чыгалар, болар исә барысы да җыр белән үрелеп бара:

Олы юлга чыккан идем,
Ак калфаклы кыз килә.
Өстәл өсләрен ямьләндереп,
Ипи белән тоз килә.

Кибетләргә кердем, пәке алдым,
Кисим дип агач башларын.
Аякларга басып, кул чәбәкләп,
Каршы алыйк кодалар ашларын.

Аш бирү вакытында сыйлаучылар һәм кунаклар арасында диалог дәвам итә. Мәсәлән, шуларның кайберләре:

Өй түрендә садыгыз,
Садыгызда — атыгыз.
Бу дәүләтне, бу хөрмәтне
Ничек тартып килде атыгыз?

Ерак безнең кырыбыз,
Күкрәп үскән солылар.
Ник тартмасын безнең атыбыз —
Бәхилләп җибәргән олылар.

Иртә торып тышка чыксам,
Очрады миңа гаетче.
Безнең сыйларыбыз бары шунда,
Сез булмагыз инде гаепче.

Йөгерә-йөгерә җыярларга
Юл буенда юа юк.
Сездә ничек, бездә шулай —
Гаеп итә торган йола юк.

Башка мәҗлесләрдә исә аш бирү җырлары берничә дүртьюллык белән чикләнә. Шуларны тәкъдим итәбез:

Биек тауның башларында
Әйләнәдер минем башларым.
Тәмле-татлы итеп сез ашагыз —
Сезнең өчен пешергән ашларым.

Өстегезгә кигән алъяпкычның
Алмаларын тигез төшергән.
Безләр киләсене сезләр белгән,
Тәмле-татлы ашлар пешергән.

Алъяпкыч баулары ал тасма,
Бәйли-бәйли торам бит.
Никләр ашамыйсыз, эчмисез —
Каршыгызда җырлап торам бит.

Карлыганнар ашар идем,
Ашасам, тешләрем камаша.
Килгәннән бирле карап торам —
Сезнең аш бирүегез тамаша.

Мәҗлес тәмамланыр алдыннан, ашаган-эчкәнгә рәхмәт әйтеп, тау итү җырлары башкарыла:

Биек тауның башларында
Ак җәймәләр кордым ау итеп.
Бу җырларны без җырлыйбыз,
Ашаган-эчкәнгә тау итеп.

Язлар җитәр, кошлар сайрар,
Ишетер микән Нуриәхмәт?
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Алла риза булсын, бик рәхмәт.

Иртә торып тышка чыксам,
Ап-ак кырау төшкән шомыртка.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Дәүләт иңсен иде бу йортка.

Мичкә лә мичкә балыгыз,
Мәскәүләргә киткән данығыз.
Мичкәләрдә балыгыз бетмәсен,
Башыгыздан дәүләтләр китмәсен.

Хәзерге җирле сөйләшләрдә һәм йолаларда сакланып калган «тау итү» гыйбарәсе борынгы төрки телдә кулланылган, ә соңга таба ул гарәп теленнән кергән «рәхмәт әйтү» сүзе белән алмаштырылган [4].

Табын җырларының соңгы төркемен мәҗлес тәмамланганда башкарыла торган җырлар тәшкил итә:

Урманнардан чыккан чакта,
Куак кисеп алдык таякка.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Басып карыйк инде аякка.

Челтәр элдем читәнгә,
Җилфер-җилфер итәргә.
Кунаклар йөри китәргә,
Белмим нихәл итәргә.

Тар гына басмалар булганчы,
Киң генә басмалар булсачы.
Киткән чакларыбыз булганчы,
Килгән чакларыбыз булсачы.

Айкый-чайкый керләр юдым
Кулларым күшеккәнче.
Туганнарым, сау булыгыз,
Яңадан күрешкәнче.

Керәшен татарларының күп гасырлар дәвамында чарланган һәм һәр мәҗлес өчен дә диярлек уртак булган җырлары, гадәттә, ике төрле — озын яки кыска көйгә башкарылалар. Озын көйгә җырлана торган дүртьюллыкларның күпчелеге — 10-9, ә кыска көйгә башкарыла торганнары 8-7 шигырь үлчәменә нигезләнә, шулай ук аралаш-катнаш үлчәмнәр дә урын алырга мөмкин. Кайбер кыска үлчәмле җырларның озын көйгә башкарыла торган вариантлары да була, бу мөмкинлек җырга төрле ярдәмлек сүзләр, кушымчалар яки эмоциональ ымлыклар кушу хисабына барлыкка килә.

Табын җырларының шигъри төзелешенә игътибар итсәк, аларның барысы да диярлек беренче зат исеменнән башкарыла. Әмма җырларда чагылган хис-кичерешләр барлык кешеләр өчен дә уртак һәм аңлаешлы.

Халык җырлары өчен табигый бер күренеш буларак, табын җырларының да зур күпчелегендә төп фикер соңгы ике юлда чагылыш таба. Җырның ике өлеше арасында бернинди мәгънәви бәйләнеш булмаган, ягъни шартлы янәшәлеккә нигезләнеп төзелгән җырлар зур урын алып тора. Мәсәлән:

Алъяпкычыңның чигеше —
Кемнәрдән күчереше?
Тату гына гомер итик,
Адәмнәр көлдермичә.

Кызыл-кызыл бөрлегән
Юл буена тезелгән.
Минем кебек кем бар икән
Сезнең өчен өзелгән?

Ләкин шунысына да игътибар итәргә кирәк: беренче карашка, җырдагы тезмәләр арасында бернинди дә мәгънәви бәйләнеш юк кебек тоелса да, кайбер җырларда беренче өлештә тасвирланган күренеш яки образ белән лирик геройның рухи халәте чагыштырыла: алар бер-берсенә охшатыла яки тиңләнә, нәтиҗәдә билгеле бер ассоциатив бәйләнеш, стилистик алымнардан саналган сурәтле янәшәлек барлыкка килә. Мәсәлән, түбәндәге җырларның беренчесендә, турыдан-туры әйтелмәсә дә, ике каенның бер төптән үсүе белән туганнарның бердәмлеге арасында ассоциация туа, икенчесендә исә мыскалларга салып кына, ягъни граммлап кына сатыла торган кыйммәтле ука белән туганнарның затлылыгы арасында тиңдәшлек хасил була:

Кара урманнар уртасында
Ике каен бер төптә.
Сезнең белән утырганнар
Онытылмас бөртек тә.

Ак ука белән сары уканы
Мыскалларга салмый сатмыйлар.
Күрер күзгә, сөйләшер телгә
Аерата сезләрне мактыйлар.

Табын җырларындагы шигъри юлларны үзара бәйләп торган образлар, сүз-сурәтләр татар халык җырлары белән уртак. Мәсәлән, иң зур лексик катламны тәшкил иткән табигать

күренешләре атамаларыннан урман, болын, яңгыр, болыт, җил, ай, кояш, йолдыз һ.б сүзләр еш кулланыла. Елга атамаларыннан иң зур урынны Агыйдел алып тора, шулай ук Идел, Мишә, Казансу образлары да очрый. Мәсәлән:

Килә болыт, ява яңгыр,
Китсен иде Мишә буена.
Бу ашаганнар, бу эчкәннәр
Китсен иде гомер буена.

Агач исемнәреннән табын җырларында каен, нарат, шомырт, тал, туйра, алмагач кебек образлар, ә үсемлекләр белән бәйле атамалардан исә гөл, чәчәк, мәк, мадъян (бадъян) һәм каләмпер (канәфер) образлары кулланылыш ешлыклары белән аерылып тора. Мәсәлән:

Каләмпер белән мадъянны
Мыскалларга салмый сатмыйлар.
Күрер күзгә, сөйләр сүзгә
Аерата сезне мактыйлар.

Сыйлы табын янында башкарылсалар да, әлеге җырларда ашамлык атамалары сирәк кулланыла, бары аш, ашамлык, ашау, сый кебек сүзләр генә зуррак урын алып тора, аның каравы җыр, җырлау сүзләре исә активлыклары белән аерылып тора.

Табын янына җыелуның төп максатын һәм мәҗлестә җырның әһәмиятен түбәндәге юллар да ачык күрсәтә:

Безләр монда ник килдек? —
Ашар-эчәр өчен дип килдек.
Ашаган-эчкән гомер тормый,
Бер күрешер өчен дип килдек.

Җырла дисәң, мин җырлыймын
Берне түгел, бишне дә.
Ашау-эчү арасында
Җырламый килешми дә.

Җидегән йолдыз койрыгы
Борыла микән таңнарга.
Сүздән генә әйтү түгел,
Мөмкин җырдан аңларга.

Йомгак ясап әйткәндә, татар халык иҗатының кыска (дүртьюллык), лирик һәм йола җырлары үзенчәлекләрен үзенә туплаган керәшен татарлары табын җырлары, барлык мәҗлесләрнең дә үзәген тәшкил итеп, кешеләрнең хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын шигъри юллар белән матур көйгә салып белдерү өчен хезмәт иткәннәр. Халыкның авыр тормышын җиңеләйтеп, шатлык-борчуларын җыр-моңга төреп бирергә, туганлык җепләрен тагын да ныгытырга ярдәм иткән әлеге җырлар буыннан-буынга тапшырылып, халык хәтерендә сакланып килгәннәр, яңа җырлар исәбенә тагын да байый төшкәннәр. Әмма шунысы кызганыч: хәзерге заманның массакүләм мәдәниятенә бирешеп, алар күбрәк олы буын өчен хас булган мираска әверелеп баралар.

Искәрмәләр

1. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. — Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. — Б.23.
2. Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты / Ф.С.Баязитова. — Казан: Матбугат йорты, 1997. — Б.11.
3. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар). — Казан: Тат.кит.нәшр., 1976. — 392 б.; Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. — Казан: Тат.кит.нәшр., 1980. — 319 б.; Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. — Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. — 488 б.
4. Баязитова Ф.С. Күрсәтелгән хезмәт. — Б.130.

КАЗАН КЕРӘШЕН ПЕДАГОГИЯ КУРСЛАРЫ УКУЧЫСЫ И.Д.БАБУШКИН ИНШАСЫ

РАДИК ИСХАКОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре

ХАЛИДӘ БАҺАВЕТДИНОВА,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты
фәнни хезмәткәре

Керәшен татарларының тарихы һәм этнографиясе буенча әле фәнни әйләнешкә кермәгән мөһим язма чыганаклар Чебоксар каласындагы Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты фәнни архивында саклана. Биредә күренекле чуваш тарихчысы һәм этнографы, Керәшен милли-мәдәни автономиясенең беренче рәисе (1917) булган Николай Васильевич Никольский фонды бар. Аның коллекциясенең нигезен галим тарафыннан 1920 елларда җыелган материаллар тәшкил итә.

Мәгълүм булганча, 1918 елны Казан үзәк керәшен татар мәктәбе нигезендә (1863-1918) Керәшен педагогик курслары оештырыла. Курсларга керәшен татарлары күпләп яши торган төбәкләр өчен башлангыч мәктәп укытучылары әзерләү бурычы йөкләнә. 1922 елны бу уку йорты Казан керәшен педагогик техникумы итеп үзгәртелә (1930 елга кадәр эшли).

Чуваш тарихчысы Н.В.Никольский 1920 елларда керәшен татарлары турында китап язарга җыена. (Аның бу планы, ни кызганыч, тормышка ашмый кала). Казан керәшен педагогик курсларында тарих һәм этнография фәннәре укытучысы булып эшләгәндә, ул укучыларга сорау-анкета тарата. Студентлар, туган авылларына кайткач, шушы сораулар буенча авылдашларының гореф-гадәтләре турында мәгълүмат

җыйганнар, соңыннан аларның тормыш-көнкүрешләренә багышлап иншалар язганнар. Бу студент иншалары Н.В.Никольский *(рәсемдә)* фондында саклана.

Н.В.Никольскийның корреспондентлары — 1921 елны галимнең лекцияләрен тыңлаган Татарстан, Башкортстан, Оренбург, Самара, Пермь төбәкләреннән килгән керәшен егетләре һәм кызлары. Аларның күбесенең язмышлары бик аяныч була. 1921 елны Идел буенда башланган ачлык һәм акчасызлык күпләрне укуларын туктатырга, кайберләрен, укуларын ташлап, туган якларына кайтып китәргә мәҗбүр итә. Укучыларның бер өлеше ачлыктан үлә, бик азлары гына, укуларын тәмамлап, педагогика өлкәсендә хезмәт юлларын башлый, кайберләре күренекле укытучылар булып таныла.

Н.В.Никольскийның укучылары язган иншаларда ул чордагы авыл халкының көнкүреше, кием-салымнары, йола-бәйрәмнәре, фольклоры, игенче хуҗалыгы, авыл архитектурасы һ.б. мәгълүматлар теркәлгән. Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган И.Д.Бабушкин иншасыннан өзек ТАССРның Лаеш кантонында яшәгән керәшен татарларының туй үткәрүгә әзерлек гореф-гадәтләренә багышланган. Ул бүген онытылган кайбер традицияләрне искә төшерергә мөмкинлек бирә.

Текстның орфографиясе һәм пунктуациясе хәзерге татар теле кагыйдәләре нигезендә бирелә. Авторның стиле сакланды.

СВАДЕБНЫЕ ОБЫЧАИ И ОБРЯДЫ КРЕЩЁНЫХ ТАТАР КАЗАНСКОЙ ГУБЕРНИИ ЛАИШЕВСКОГО КАНТОНА

Казан губернасындагы керәшеннәр өйләнәләр нардуганнар ары. Җәй көне и көз өйләнәләр шундыйлары, кайсыларының өйләрендә хатын-кыз җәмәгате юк. Яшь егетләр өйләнәләр 18-22 яшенә хәтле, бик сирәк калучылары 26-27 яшькә: кайсылары сугышта була, кайсылары бик ябык кешеләр. Кызлар кияүгә китәләр 16-22 яшьтә, бик сирәк калалар 25-27 яшькә хәтле. 22 яшьтән узган кызларга исем кушалар «сазаган кыз» дип. Алар, кияүгә китсәләр дә, тол иргә китәләр. Безнең керәшен халкында андый калган кызлар юк, калсалар калалар аяксыз-кулсызлары гына. Ирләр тагы юк. Һәркайсы ир тырыша өйләнергә. Шушындый тырышуларның мәгънәсе күренә: туй. Туй башлана шушылай. Өйләнәсе килгән егет пирбый әйтә җәмәгатьләренә, что мин өйләнәм шушы кызга. Җәмәгатьләре күнсә, чакыралар яучы, җибәрәләр аны кызның җәмәгатьләренә. Яучыны ча-

кыралар егетнең карендәш-ырулары, ә күбесенчә чакыралар шундый кеше, кайсы кеше бик оста телгә и бик тәмле телле.

Яучыны чакырып китергәч, утырталар чәй эчәргә. Чәй эчкәндә сөйләшәләр и яучы китә кызның өенә. Кияү икенче авылныкы булса, то ул җибәрә килешергә я атасын, я анасын, я үзенең карендәшен. Кызның авылына килеп җиткәч, җибәрүчеләр туктыйлар карендәшләрендә я бик белеш кешесендә. Яучы туктаган өй атала кунак өе дип. Яучы шушы турыга куша өйнең хуҗасын, я хатынын. Кайчагында бик читен була, шул чагында бик оста кешене җибәрә. Кызның өенә кергәч, яучы әйтә: күт астым мендәр, аяк астым бүкән. Бу сүзләр күрсәтә, что бу кунак буш түгел, ә яучы. Шуннан ары хуҗаның хатыны сәкегә сала мендәр, яучы утыра. Бүкән кую турында, яучы аны бүкән түгел, бүтән, [ди]. Хуҗаның хатыны сорый, нәрсә соң, и шушы сүз белән башлана кызның семьялары белән [сөйләшү]. Яучы әйтә кызның семьяларына, что ул килде шундыйшундый эш белән. Кызның аталарыаналары шундук кызны бирмиләр, ә әйтәләр, менә кыз ни әйтер, кыз белән белешергә кирәк, диләр. Шуннан ары өстәлдә самавыр да була, ашамлык та. Сөйләшеп утырганда, яучы әйтә кияүнең бар әйбәт турларын и байлыкларын. Инде кияү икенче авылныкы, бик билгеле түгел кызның аталарына, то яучы, бер дә оялмыйча, ялганлап әйтә кияүне, и байлыгын бер дә юкны я күршесенекен. Яучы кайчагында шул ялган белән үзенең кирәген урынына җиткерә. Күндерә аталарын кызның. Пербый ук алай да алар калдык ответларны бирә алмыйлар, кыз күнсә дә. Кызның аталары сорыйлар яучыдан икенчеләй килергә, калдык ответ алырга. Яучы кайткач, барын да рәтләп әйтә кияүнең аталарына-аналарына. Если алар тагы килергә әйткәннәр, то кияүнең олы җәмәгатьләре и карендәш-ырулары бергә җыелып сөйләшәләр бирнә турында. Бирнәне бирә кыз, кияүнең карендәшләренә. Шул көннәрдә кызның өендә эшлиләр калдык ответны, аннары бирнә турында. Шул көннеме или икенчеме яучы тагы бара кызның өенә, бу килүендә әйтә калым турында. Шундук, яучы килү белән, кыздан сорыйлар: күнәме, юкмы. Шунда кыз китәм дисә, яучы сөйләнә башлый калым турында. Шул чагында ул тырыша төрләндерергә кызның аталарын калымны киметергә. Хотя кызның аталары калымны гораздо күбрәк куйсалар да, яучы тырыша күпме алар әйткәннәр, егетнең аталары. Кайчагында шундые да туры килә: какой-нибудь 5-10 тәңкәдән килешү бетә. Но если егет белән кыз сөешеп йөрсә, аннан гына килешү тора алмый. Карышыбрак торсалар, кызның агай-энеләре, яучы аларны йомышата аракы белән. Шунда утыручы кызның агай-энеләре сорыйлар кызның аталарыннан: бирергәме, юкмы, калымын да шул өчәү белән күнәләр. Калым Лаеш кантонында 10-50 тәңкәгә хәтле. Калымның күплеге-азлыгы тора яшьлектән, матурлыктан, саулыктан и байлыктан кызның. Калымны килешкәч, яучы әйтә башлый дары турында. Дары әйберләре: күлмәк киҗеле, карендәш-ыруларына икесенә дә, баш әйберләре — хатын-кызларга, янчык — тәмәке салырга ирләргә. Дарыны салганда кайчагында кыз ягыннан килешеп бетмиләр. Дары аркасында гына килешү бозылмый, яучы азрак кимәтә. Кроме калым янына акча, кияү должен кызларга разный подаркылар. Күбесенчә бу подаркылар кызның карендәш-ырулары белән куела. Менә нинди подаркылар: җилән җәйге, тун тышлаган пыстау белән, шәлъяулык; җәйге кием-

нәр: ризинке кәлүш, көмеш сырга. Яулык и кәлүшләр, и бүтән төрле әйберләр алалар базарда кыз белән егет икесе бергә. Бу әйберләр тегелә егетнең өендә. Яучы кияүнең агай-энеләре белән китә кызның аталары өенә. Кызның бар төше чиста була, көйлиләр кунакларга аш-су и аракы, киенәләр әйбәт киемнәр. Кыз шул бримадә карап куя әйберләрен, кияүгә бирәселәрне. Яучы тагы буш килми, алып килә үзе белән $^{1}/_{4}$ *чиләк аракы. Кунакларны утырталар өстәл әйләнәсенә. Өстәлгә китереп утырталар самавыр. Чәй эчә башлыйлар и аракы да сала башлыйлар. Чәй артыннан ботка да утырталар самый әйбәтен.*

Ашаганнан ары яучы сорый кызның аталарыннан, кызыгыз күнәме, юкмы — сорап карагыз әле, дип. Сорыйлар: кыз күнәм, ди. Шуннан ары кызның анасы куя өстәлгә ипи белән тоз, ак яулык, ашъяулык и янчык — кияүгә дигән. Бу әйберләрне яучы ала. Сыйланып туйгач, яучы кайтып китә кияүнең өенә, анда аны бик сыйлыйлар и рәхмәт укыйлар кызны килешеп кайтканына и әйберләр алып кайтканына. Бу әйберләр әйтелә ак дип, шуңа күрә дә атала аклашу дип. Шуннан ары 5-10 көн торгач була ярәшү. Ярәшү белән аклашу көннәре арасында үткәрәләр кызның өендә: пешерәләр сыра, пешерәләр ак ипи, разный бөккәннәр. Әйтелгән көнне егетнең агай-энеләре бара кызның өенә, ә егет икенче авылныкы булса, кунак өендә туктыйлар, аннары я хуҗа белән, я хатыны белән баралар кызның өенә. Алар үзләре белән алып баралар 1 чиләк аракы, 4 бөтен ак ипи, бер пешкән каз. Кунаклар килү белән, кызның аталары чакыралар карендәш-ыруларын и әйбәт дусларын. Кунакларны утырталар өстәлгә, хатын-кызын бергә, ашамлык-эчемлек — барсы өстәлдә. Кияүнең ага-энеләрен утырталар түргә. Если өйдә эссе түгел, кунаклар утыралар тун белән. Кунакларга пирбый чәй эчәргә кушалар, аннары разный ашамлыклар ашарга, сыра, аракы эчертәләр, калдыгында ботка утырталар өстәлгә. Шуннан ары өстәлгә утырталар ипи, ит и аракы, кияүнең агай-энеләре алып килгәнне.

Кияүнең атасы ипи өстенә куя акча калымныкын. Калым акчасының бер ягы була көмеш, көмеш акча китә кызның әйберләрен матурландырырга. Бу акча булырга кирәк чиста көмеш и әвәлге акча; кыйбатлырак әвәлге акчаның Екатерина II, ул бик билгеле татарларда, и алар аны атыйлар гәдрә тәңкә дип. Салгач акчаны, кияүнең атасы әйтә: бездән мал, сездән хезмәт; Ходай тазалыкларын бирсен; ипиле-тозлы булсыннар. Акчаны өстәлдән ала кызның анасы и бирә бер-бер кешегә чутларга, и ул кеше әйтә күпме биргән акча. Аннары кияүнең атасы әйтә: менә без байтак акча бирәбез, сез безгә ни бирәчәкне безнең беләсебез килә. Безгә сезнең кызыгызны бик мактадылар, алай да булса үз күзебез белән күрмичә, кеше сүзенә ышанып җитеп булмый: кияүгә дә кайткач әйтергә кирәк, ул сорар — кыз аксак түгелме дип. Моңар каршы кызның аталары әйтәләр: бу турыда борчылмагыз, хәзер алдыгызга китереп күрсәтербез, безнең кызыбызның җитмәс җире, шиге-күге юк… Ну бу сүзләрне кайчагында җыр белән әйтәләр:

Олы дулкын маягы,
Ак юкә агач таягы.
Чыгарыгыз кызыгызны,
Аксак түгелме аягы?

Моңа каршы:

Йөгереп төштем мин инешкә,
Инеш буенда пешкән җимешкә.
Алан кызы кебек булса булыр
Җомакның эчендәге фәрештә.

Шуннан ары кыз беркәү эченнән чыга. Кызның ягыннан тотып чыга ике иптәше. Өчесе дә комнатның уртасында туктыйлар. Күргәчтен кызны, кияүнең аталары әйтәләр аның матурлыгын, ябыкмы, тазамы. Кызны карыйлар биш минут. Шуннан ары өстәлгә куялар дуңгыз ите и каз, и кунаклар яңадан башлыйлар ашарга, җырлап, эчеп ашый башлыйлар. Калдыгында кунаклар бик каты сөйләшә башлыйлар и җырлап та җибәрәләр. Менә җырларының кайсысы:

Кара урман артыннан
Кара болыт киләдер.
Кара болыт кар булмас,
Егете матур, кызы хур булмас.

Биек тауның башында
Язып төштем ташына.
Кайда йөрсә дә хур булмас,
Алла исәнлек бирсен башына!

Урак урдык ызансыз,
Печән чаптык мижасыз.
Әй бер Ходаем, чын Тәңгерем,
Гомерләреӊ уздыр нужасыз!

Чәчтем бодай, чәчтем бодай,
Чәчкән бодаемны бир, Ходай.
Сокланмыек кеше малларына,
Үз бәхетләрен бирсен бер Ходай.

Җырлыйлар и бүтән җырлар, бу җырларда кунаклар берсенә-берсе әйтешеп. Кунаклар ашап-эчеп утырганда, иптәшләре белән кыз кәтәйсәгә чыгалар. Егет белән кыз бер авылныкы булса, егет үзе әйләндерә ат башына утырып, ә егет икенче авылныкы булса, егет урынына кызның бер-бер агай энесе я кызның энесе [утыра]. Кызларны егет белән озаталар ике-өч иптәше. Кәтәйсә әйләнәләр ике-өч ат белән. Кәтәйсә әйләнүе бара 1 сәгатьтән 2 сәгатькә хәтле. Бу бримедә җырлыйлар гел әйбәт җырлар. Менә кайсылары җырның:

Егет булсаң, бул егет,
Көмеш койдыр каеш йөгәнгә.
Егет гомереңне зай үткәрмә,
Кәбен койдыр җаның сөйгәнгә.

Җепәкәй яулык башында,
Җилләр аладыр да китәдер.
Җилбердәп үскән зифа буйны
Егет аладыр да китәдер!..

Җилбер, җилбер, җилбер чук,
Ник җилберди — җил дә юк.
Сезнең кебек пар килгән
Авылда түгел, илдә юк!

Ике Идел пар килгән,
Аның агар җире тар килгән.
Казанда түгел, юк Мәскәүдә,
Сез икегез пар килгән.

Кәтәйсәдән ары кыз әзерли кияүгә күчтәнәч, чикләвек, матур теккән янчык белән. Шул вакытта бетүе була туйның. Кунаклар кайтырлыклары кайталар, ә исергәннәре — аракы белән — йоклыйлар үз урыннарында таң атканчы. Мичкәне — кияүнең аталары алып килгәнне — аракы белән тутыралар, бал белән, ә янчык — ипи тутырып килгәнне — ипи белән. Шуннан ары кияүнең аталары кайтып китәләр өйләренә, ә если икенче авылныкы, аралары да бик ерак булса, куналар кунак өендә. Шуннан ары кыз әйтелә ярәшелгән кыз дип, ә егет — кияү дип. Ярәшкәннән ары туйга чаклы — 10 көннән 2 айга чаклы. Бу көннәрдә кыз әзерли кияүнең аталарына и үзенә әйберләр. Самый кирәкле әйберләре — баш әйберләре.

Әйберне әзерләргә керешәләр кызның иптәшләре и туганнары. Кияү әзерли кызга кышкы киемнәр: тун и җилән. Материя моңар алалар якын базарда, бергә кыз белән и туганнары белән. Бу гына түгел, кияү тагы ала кызга ризинке кәлүш, ефәк яулык, көмеш сырга, барсын да элек килешкәннәрен. Бар әйбер дә әзер булгач, кияү алып бара кызга. Бу баруында ул сорый үзенең карендәшләреннән туй турында. Если бар әйбер дә кызның әзер булса, то җәмәгатьләре кызның куялар кияүнең җәмәгатьләре әйткән көнгә. Я, каршы торганда, сорыйлар азрак көтәргә, но ун көннән артык түгел. Шуның белән кала бик кыска срок, и шуңар күрә кияү киткәннән ары туйга чаклы атала кыска бужал дип. Икенче көнне, кияү киткәннән ары, кызның аталары чакыралар үзләренә карендәшләрен и дусларын, туйга керешергә. Туйда чит кешедән була ике өй, ә байларда — өч. Чакыргач кунакларны, кызның аталары ашаталар, эчертәләр. Өстәл арасында кызның атасы сорый кунаклардан туйга керешергә, моңар кунаклар күнәләр, хотя туйга 10-15 тәңкә расход кирәк. Шушылай и кияү өендә дә, аталары шушылай сыйлыйлар туйга керешкәннәрне. Сыйланганнан ары кызның өендә дә и кияүнең дә, и бүтән өйләрдә дә әзерләнә башлыйлар: сыра пешерәләр, (умартачылар) [1] бал, калач ипи пешерәләр, аш-су әзерлиләр; хатыннар үзләренең эшләрен эшлиләр, ирләр — үзләренекен, сатып алалар аракы 1 чиләк я 2 чиләк, атларны тазарталар, сбруйларны чистарталар. Туйга чаклы әллә ничә сәгать алдыннан гына әзерләнү бетә. Әйткән вакытта туйга керешкәннәр, кияү ягыннан, керәләр кияүнең өенә. Алар киләләр гутау булып кызга барырга. Баручылар әйтеләләр кодалар дип, хатыннар — кодачалар; аралап әйткәндә, шушындый исемнәр: 1) кыяматлек кода, 2) аның хатыны — кыяматлек кодача; 3) кияү егете, 4) аның хатыны — кодача (кияү егете өйләнмәгән дә була), аннары ул бара үзенең карендәш хатыны белән, 5) олы кода (дядясе или атасы кияүнең), 6) олы кодача (җиңгәсе или анасы кияүнең). Если дүртенче пар булса, то әйтелә просто кода-кодача.

Кыяматлек чанасында — кайсын без әйтәбез «атасы утырган» кияүнең — җигелә пар ат, ә калдыкларына бирәр. Туйга барганда, чанага салалар мендәр (1 ар[шин] калынлыгы 1 $^1/_2$ буе) ястык; атларда әйбәт сбруй и кайсыларында кыңгырау. Кияүнең өендә кодаларга-кодачаларны ашаталар, эчертәләр. Ашап-эчкәннән ары, китәр алдыннан кияүне аталары бәхиллиләр и кәбенгә барырга шушы сүзләр белән: «Без синең атаң-анаң, сине тудырдык, сөеп, хәстәрләп үстердек; син аякка йөри башлап, телең чыгып «әни, әти» дигән сүзеңне ишетеп, бик сөенештек, сине юатырга төрле уенчыклар бирдек. Син буйга үсә башлагач, урамга чыгып, иптәшләрең арасында уйнарга күңелле булсын дип, өстең-башыңны аруырак киендерергә тырыштык; аз-маз эшкә ярый башлагач, без сине авыр эшкә вакытсыз кушып имгәндермәдек. Менә соңыннан син дәү булып, эшне үзең башлап эшли башладың, без сиңа үзең теләгән эшне сайлап эшләргә ирек бирдек. Бәйрәм көннәрне син теләсә кая бардың, уенда теләсә кем белән уйнадың, без сиңа үзең сөйгән кызны сайлап алырга ирек иттек. Менә син сайладың аласы кызыңны Аудыйны; без җаныбыз теләп сине аның белән кәбенле булырга бәхиллибез. Аның белән рыскаллы бул, балакаебыз, Алла-Ходай үзе сине аласы кызың белән дәүләтле тормышка

бәхилләсен... Менә инде син тиз үк яңа тормыш белән тора башларсың, сөенечең булса да, кайгы-көенеч булса да, хатының белән киңәш итәрсең, шуны исәпләгәч, безгә ямансу түгел; алай булса да син, балакаем, безне онытып җибәрмә; без сине тудырып, җаныбыздай сөеп, хәстәрләп үстергәнебезне онытма. Без картайгач, бездән җирәнмә, Алла үзе сакласын, безне ят кешеләр кулына калдырма! Барыгыз инде, Ходай изге юл бирсен!» Шундый сүзләр, кияүгә атасы, анасы әйткән, күңеленә беркелә. Кияү кайчагында елый: даже шунда булганнарның да күзләреннән яшьләр китә. Калдык сүзләрен әйткәч, атасы, анасы ипи, тәре белән бәхилли. Атасы кияүнең ала тәрене, утыра сәкегә и хач формасына сала башын иеп тезләнеп торган малаена. Тәре белән бәхилләгәч и ипи белән дә бәхилли. И шулай бәхилли анасы кияүнең. Шуннан ары барсы да торалар да келәү итәләр тәре алдында. Келәү иткәч, барсы да чыгалар өйдән и утыралар чаналарына. Кияү утыра атасы утырган чана башына ат тотып. Калганнары, кодалар-кодачалар, утыралар пар-пар. Олы коданың чанасына салалар туй күчтәнәчләрен: дүрт бөтен ипи, каз, $^{1}/_{2}$ — 1 $^{1}/_{2}$ чиләк аракы. Ишек алдында и капка төбендә бик күп кеше була: яшьләр, олылар җыйналалар озатырга. Калдыгында китү куба шушы порядкыда: 1) кияү егете, 2) кыяматлек кияүе белән, 3) кода-кодача, 4) олы кода, олы кодача. Шушы порядкада китәләр туйга, күрше авылга гына түгел, кайчагында 20-40 чакрымга. Кайчагында шушылай да була: кызның өе рядем кияүнеке белән. Калдыгыйда баручылар туктыйлар кыз өенең капка төбендә и шунда авылның әллә кай төшләреннән киләләр йөгереп кешеләр: яше, олысы. Капка төбендә озак туктау була: капка бикле була, и бер малай бик каты тота бикләвечне. Көмеш я бакыр акча кияү егете бирә малайга, аннары малай ача капканы, и килүчеләр керәләр ишек алдына. Шул бримедә мылтык аталар... Курыккан атлар кереп китәләр лапас эченә үк, если кияү тыя алмаса үзенең атларын, то аннан көләләр. Кайчагында шулай да туры килә: кодалар чаналарыннан егылып төшәләр, ә атмаска ярамый — шундый обычай. Төзләнгәч, әйбәтләнгәч, чаналарда килүчеләр өй алдына тезелеп торалар. Ирләр уң якта тора, хатыннар сул якта. Кияү уртада тора, калдыра урын кызына сул якта. Өйдән кодаларның каршыларына чыгалар: кызның атасы тәре белән, анасы — ипи белән тоз, май белән; бер карендәше кызның аракы белән. Кыз, ике ягында ике иптәше белән, чыга беркәү белән, туктый кодалардан-кодачалардан ераграк, баскыч төбендә үк. Агай-энеләре кызның, якынрак килеп, кодаларга-кодачаларга мактыйлар аларны. Шундагы кешеләр барсы да кияүгә карап торалар, ул шул минутта кызның кулыннан алырга туры килә. Кыяматлек кодача әйтә: кызыгызны якынрак китерегез, безгә күрергә кирәк: йөри беләме, аксамыймы... Моңар каршы кызның бер карендәше әйтә: «Ай-ай сез! Егет үзе килеп алсын, аңар кыз кирәк, безгә сезнең егетегез кирәк түгел! Әллә ул аксакмы, шуннынтан кешеләрдән ояла торгандыр; әллә кыз янына килергә кыймыймы? Алай булгач, ул нинди кияү, егет дигән булалар тагы!..» Шуннан ары егет кызның кулыннан тотып ала алмый. Ул кыз янына бара, но белә кызның иптәшләре аңар бушка бирмәсен, шуннан ары ул ала кесәсеннән янчык — кыз күчтәнәчен — и янчык эченнән ала ике көмеш акча, аннары бирә кызның иптәшләренә. Шуннан

ары егет кызның уң кулыннан ала да и аның белән рәттә тора. Аннары кызның аталары, аналары китерәләр һәркайсына рәттә торучыларның тәре и ипи-тоз, и хач билгесе салалар. Ә җамаяктан эчәләр сыра. Шуннан ары кызның аталары керәләр өйгә, алар артыннан кодалар да, кодачалар да. Кияү белән кыз керә бергә, берсенә-берсе орыныбрак, что тыгызланганда, аларның арасыннан чыкмаска, чыксалар әйбәт булмый, ди. Өйгә кергәч, килүчеләр шушындый картина күрәләр: өйдә бик чиста, стеналарда элгәннәр ашъяулыклар, бистәрләр, өстәл өстендә ак ашъяулык, ашамлык белән, утыралар әллә ничә карчык, ашамлыкка тимичә. Өйдә, өй җәмәгатьләреннән башка, каршы алалар кодаларны-кодачаларны туйга керешкән бүтән кешеләр дә. Каршы алгач кунакларны, хуҗаның хатыны куша толыпларын салырга, но өстәл арасына утыртмый шунганчы, олы кода урын сатып алмыйча карчыклардан.

Шуннан ары өйгә кертәләр чанадан ящигы белән ипи, мичкә аракы, олы кода алып килгәнне. Атларны алып китәләр туйга керешкәннәр, калдыралар только кыяматлек парын: олы кодадан акча алгач, карчыклар кунакларга урын бирәләр, утырталар өстәл арасына, кодаларны киезгә, кодагыйларны күбчек өстенә. Кодалар-кодачалар утыралар туннарын салмыйча, шушы порядкыда: түрдә — почмакта «тәре астында» — кыяматлек кода хатыны белән; уң якта, аннан түбән, кияү егете, кияү егетенең сул кулы янына аның хатыны; рядом аның белән олы кодача, олы кода белән кырыйда. (Если булса 4 нче пар, то ир утыра кияү егете янына, ә хатыны олы кодадан югары). Кияүне кыз белән утырталар бүтән төшкә, почмакка чаршау корып и шунда бер бәләкәй өстәл кулар, ашамлык белән. Бу урында пербый утыралар кызның иптәшләре, кияү акча биргәч, урын бирәләр кияүгә. Но кияү и кыз урынны сатып алгач, утырмыйлар шунгынчы, кызның анасын утыртмыйча. Кияүне утырткач, ул обещать итә аңар бербер мал, нап. [например], тай, бозау, сарык и т.п. Кияү утыра кызның уң кул ягына, ә сул кул ягына утыралар аның иптәшләре. Кияү утыра бүрек белән и салмый бүрекне шунгынчы, кызның анасы салдырмыйча. Бүреген салдыргач, ул может кияүнең башына, әйтә әйбәт сүзләр, напр. [например]: «Алла үзе бәхилләсен и җәмәгать бәхетен» и пр. [прочие]. Кияү и кыз гел утыралар ястык өстендә, ә бер-бер төшкә чыксалар, үз урыннарына калдыралар бүреген я яулыгын; кай чагында шулай да туры килә: буш урынны кызның иптәшләре ала, и кияүгә яңадан сатып алырга туры килә. Шуннан ары башлана туй ашы. Башта кунакларга чәй эчертәләр шикәр белән, (умартачылар) бал белән, каймак ашыйлар, шишәрә бодай онынннан пешергән май салып и калач ипи. Чәй эчкәндә, кунакларга аракы, бал эчертәләр. Аракы эчәләр и кодачалар да, но азрак кодалардан. Кайчагында шундыйлары да була — аракы эчмәгәннәре; аларга аның урынына сатып алалар виноград аракысы я бал-чәй эчкәннән ары кунаклар салалар туннарын и утыралар үз урыннарына камзул белән генә.

Бабушкин Иван Данилов.
1921 ел

Искәрмә:
1. Текстта шулай бирелгән.

Чыганак:
Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты фәнни архивы. 1 бүлек. Н.Ф.Никольскийның шәхси фонды, 311 саклау берәмлеге, 155-170 б.

КЕШЕГӘ НИ ҖИТМИ?

ЕГОР УТКИН

Кеше туа.
Туа чишмәләр.
Җилләр куба,
тына,
исәләр...
Барысы да җиргә җитәрлек,
Барысын да җирдән табабыз.
Шатлык,
сөю,
дуслык хисенә
Тулган чишмә,
сулар,
һавабыз.
Барысы да җирдә бар безгә:
Дөньябыз бай, бай ул шултикле!
...Тынлыкка һич урын калмады,
Кешеләргә менә шул җитми.

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Һай, сүз тәме!
Һай, син татлы тамыр!
Яшәртәсең уйны, җаннарны.
Уйнатасың тәндә яңа каннар,
Алмаштырып иске каннарны.

Гәрәй Рәхим

ХАЛЫК БАЙЛЫГЫ – ҖИР БЕЛӘН СУ*

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА

филология фәннәре кандидатлары

Табигатьне ярату ул табигать күренешләренә, ландшафтка соклану, аннан ләззәт алу гына түгел. Кешенең табигать серләрен аңларга омтылуы — үзе генә дә изге эш. Ул, кеше рухын тормышның вак-төяк ыгы-зыгысыннан, мәгънәсез буш хыяллардан, үз шәхесеңне генә кайгыртудан һәм башка шундый вакҗанлылык күренешләреннән арындырып, бөек максатларга әйди. Табигать белән актив рәвештә аралашу кешенең уй-тойгыларына илһам өсти, аның үз-үзенә ышанычын ныгыта, хисләрен сафландыра, аларны хөрлек хисе һәм пакь һава белән җилләтә.

* * *

Кеше тарафыннан пычратылмаган табигать тормышы ул — хөрлек патшалыгы. Табигать белән аралашу кешеләрне бер-берсенә якынайта һәм җәмгыятьнең сафлануына ярдәм итә.

* * *

Табигать сөючеләр арасында мин явыз холыклы, кара эчле әшәке кешеләр очратмадым.

* * *

Авыл кешесе һавадагы торнага бик үк ышанып бетми. Ул бит — җир кешесе. Тормышын табигатькә тиңләп карарга ярата.

* * *

Авыл кешесенең ата-бабадан килә торган үз дару-дәрманнары бар: мәтрүшкә, юкә чәчәге, май кычытканы, бака яфрагы, ак әрем, кырык ызан үләне, каен себеркесе…

Гомәр Бәширов

Иң кадерле нигъмәт су икән.

Гамил Афзал

Үткәннәрне, тарихны фаш итү — безнең гомерләрнең зая узуын тану дигән сүз. Табигать биргән вакыт яшәлмәгән, дияргә туры килә. Аны ничек кайтарырга? Бушлыкны ничек тутырырга? Ә табигать бушлыкны белми.

* * *

Хозурланасың килсә, дөнья күз алдында бөтен киңлеге һәм гүзәллеге белән ачык.

Әхсән Баян

Табигатьне танып белү һәм табигать белән татулыкта, бердәмлектә яшәү — кеше өчен иң югары бәхет. Хакыйкатьне иң элек табигатьтән эзләргә кирәк.

Мәхмүт Хәсәнов

Уңайлылык белән генә булмый бит ул! Җан җылысы кирәк кешегә. Иркенлек кирәк. Табигать белән бәйләнеш кирәк! Ә без, уңайлы дигән булып, гомеребезне таш тартма эчендә үткәрәбез. Ә кешенең табигате моңа каршы! Табигать үзенекен итә! Шуңа бит инде күпме кеше эт асрый, кактус үстереп иза чигә. Чөнки табигатьтән аерылып яши алмый кеше!

Мәдинә Маликова

Кешеләргә ялгыш берәр авыр сүз әйтсәң үпкәлиләр, озак вакыт ачу саклыйлар. Табигать ачу сакламый: без быел сындырган шомырт агачы киләсе язда ап-ак булып яңадан чәчәк ата. Аның ачу сакламавыннан без усал файдаланабыз. Бәлки, аның ачулануы, вакытында безнең кулга сугуы кирәктер. Юк, табигать алай итә алмый. Кешеләр былтыр эшләгән начарлыклары өчен үкенәләрдер, тагын бер генә тапкыр чәчәк атыйм, ди ул. Һәр яз саен шулай эшли. Аның көчлелеге дә — кичерә белүендә. Кешеләргә үз ялгышларын төзәтергә мөмкинлек бирүендә.

* * *

Кеше белән табигать гел бергә. Кеше табигатьтән кыюлыкка, батырлыкка, сабырлыкка өйрәнә. Кеше табигатьне, табигать кешене бизи. Бер-берләрен тулыландыручы бу ике көчне аерып карап булмый. Кеше табигать матурлыкларыннан кыска гына вакытка аерылып торса да ямансулый, сагына башлый.

Теплицадагы үсемлекләргә дә бөтен нәрсәсен бирәләр: ашламасын, дымын, яктылыгын. Әмма алар барыбер кыр чәчәкләре кебек нык булып үсә алмый. Йолкып алуга, сабаклары егылып төшә. Чөнки алар көннәр буе җилләрдә тирбәлмәгән, кояшның рәхимсез эсселегендә сыналмаган. Кыр чәчәкләре тамырларын теләгән кадәр тирәнгә җибәрә ала, ә теплицадагы чәчәкләрнең тамырлары, каты бетонга төртелеп, кая китәргә белмичә, сабак тирәсендә чуала. Тамыры ташка тигән гөлнең очы саргая башлый.

* * *

Кешеләргә булган ачуны табигатьтән алмыйлар.

Фәнис Яруллин

Күпме генә тапталса да, түбәндә, безнең табаннар астында кимсетелеп ятса да — Җир барыбер бөек!

Шамил Анак

Йолдызларга бару серен чиштек,
Нәрсәнедер дөрес чишмибез:
Рәхәт явар сыман иде күктән,
Ишелә бит афәт... Нишлибез?
Галимнәрме булдык, залимнәрме?
Җирдә табигатьтән көчле без:
Табигатьнең карынын
ярып куйдык,
Яралгысы кибә... Нишлибез?

Рөстәм Мингалимов

Урман-кырда, табигать кочагында үскән балалар тирәнрәк хисле, сәләтле һәм кешелеклерәк була.

* * *

Табигать тудырган бөтен тереклек ияләре яшәргә хаклы. Алар бер-берсенә шулкадәр бәйләнгән һәм булышып яшиләр, кайсын гына юк

итсәң дә, табигатькә зыян килә. Ә бу исә соңыннан кешеләрнең үзләренә үк зарар китерә башлый.

* * *

Комсызланып, табигатьне талау, башкалар өлешенә кереп баерга тырышу — бик зур җинаять ул. Табигатьтә һәр җан иясенә тереклек итәрлек һәм үзенең дәвамын калдырырлык кына байлык һәм мөмкинлек бар. Шуңа күрә һәр җирдә кеше аннан үзенә кирәк кадәр генә алырга һәм башкаларны да шуңа өйрәтергә тиеш.

Табигатьтән берне аласың икән, аңа икеләтә кайтарырга кирәк. Шулай гына саклап калып була аны.

Заһид Фәйзи

Ә Табигать гадел!
Юк кодасы,
Кодагые,
Килен-кияве.
Даһиларны үзе сайлап ала
Һәм бәяли, биреп тиярен.

Эльмира Шәрифуллина

Табигатьнең — үз законы, кешенең — үз законы. Табигатькә кеше кирәк түгел, ә кеше табигатьсез яши алмый. Җәнлек-җанварларны гына карагыз сез: алар табигать законнары буенча яши, алардан табигатькә бер зыян да юк. Ә кеше? Кеше кыра, җимерә, елгаларны туктата, урманнарны кисә, һавага күпме агу очыра... Табигатьнең үз баласы булса, үзен тудырган дөньяга шулай карамас иде ул. Димәк, кеше — табигатьнең үги баласы.

Разил Вәлиев

Җир астыннан чыккан су гына саф.

* * *

Саф чишмә агымы кеше тормышы аша үтә, аны юа, чистарта, сафландыра һәм язмышлар ләмен үзенә алып болганчыклана. Шуңадыр инештән су эчмиләр. Эчәр өчен гел чишмәләрнең сафы, кәүсәре кирәк.

Камил Кәримов

Җир тере. Ашатмасаң, эчертмәсәң, ул да үлә.

* * *

Җир кулдан-кулга күчкәндә,
Күпләр күченеп киткән.

* * *

Җир астына кереп ятканчыга кадәр, адәм баласы җир бүлүдән туктамый.

* * *

Һәркемнең
Тәнен — Җир,
Җанын Ай
Көтәдер.

Мөхәммәт Мирза

Табигатьнең бөеклеге нидәме? Табигать һәрвакыт гүзәл. Хәтта ялангач, шыксыз, салкын, усал чагында да... Ул кызгануга мохтаҗ түгел. Ул яратуга гына мохтаҗ!

Галимҗан Гыйльманов

---

*Дәвамы. (Башы журналның 2-3 саннарында.)

АЛЕКСАНДР ФИЛИППОВ

* * *

Табигатькә нәрсә булды икән,
Чәчәк атты балан көзен дә?
Тик җимшәнен генә өтеп алды
Кара суык Покрау төнендә.

Нигә инде чәчәк аттырырга
Өшетерлек булгач тәлгәшен.
Ашыктыңмы әллә күрсәтергә
Алтын көзнең яшел кәлшәсен.

Кызыл балан янында ак тәлгәш
Кояш җылысыннан коела.
Яхшы да бит көтү үз нәүбәтең
Ашыкмыйча гына кая да.

Ничек кенә матур күренмәсен,
Көзге чәчәк туа җимешсез.
Аңламаслар сине тыңлаучылар
Әйткән сүзең булса килешсез.

КИЛӘЧӘККӘ ИЛТИК

ЯМАШ ИГӘНӘЙ

Жыр ургыла ишек, тәрәзәләрдән.
Нәни кыйтга — авыл ызбасы.
Керәшен туе бүген бу кыйтгада —
Борынгы жыр, болгар йоласы:

«Тәрәзә төбендә ай, тутый кош,
Ак мамыклар белән тотыгыз.
Безнең бәбекәебез сезгә килә,
Какмый гына, сукмый тотыгыз».

Кода-кодагыйларның жор телләре —
Чакма белән гүя чакматаш.
Жыр бәрелеп жырга очкын чәчри,
Тапкырлык һәм акыл башма-баш!

«Урманнарга кердем атым бәйләп,
Кисепкәйләр алдым киртәлек.
Хезмәтләрен килен аямаса,
Шунда булыр аңа иркәлек.

Ничек бөреләнгән яңа дәвам —
Үткәннәргә яле күз салыйк.
Асылташта кояш чагылгандай
Һәр йолага сыйган бер тарих.

Болгар учагыннан бүгенгегә
Төшкән чаткы чорлар аркылы.
Авыл ызбасында керәшен туе —
Чал тарихның нәни ярчыгы.

Шул ярчыкның бөтен ышанычы
Һәм өмете балкый ил-көннең.
Йөрәкләргә төреп, киләчәккә
Илтиекче аны, и энем!

БАЛАЧАК ЯДКӘРЛӘРЕ

Мин бәләкәй чакта уйнап йөргән
Сукмак килә нәни инештән.
Сабый чаклар! Тагын сезгә килдем
Яшеренеп кенә дус-иштән.

Гәрәй Рәхим

Хөрмәтле нәни укучыларыбыз!

Тарих өчен вак әйберләр юк, аның хәтере әйбәт. Тарих тузаннары аша да асылташтай ялтырап торган кадерле ядкәрләр һәр йортта, һәр гаиләдә саклана. Алар буыннар чылбырын тоташтыра. Әлеге кадерле гаилә ядкәрләрен бергәләп барлыйк. Сездән кызыклы, гыйбрәтле хатлар көтеп калабыз. Үзенчәлекле экспонатлар, ягъни иң кызыклы хатларны «Чын мирас» журналы музеена куеп, укучыларга да күрсәтербез, укытырбыз.

«Үткәнен белмәгәннең — киләчәге юк», — диләр. Безнең милләт киләчәкле һәм якты, матур киләчәкле булырга тиеш!

ЧЫНАЯКЛАР

ЙОЛДЫЗ ШӘРАПОВА,
шагыйрә

Һәрбер йортта, бигрәк тә, авыл өйләрендә буыннардан-буыннарга әманәт булып тапшырылып килгән, тарих тузаннары кунса да, кыйммәтләрен югалтмаган гаилә ядкәрләре була. Бабамнар өендә дә шактый алар. Араларында иң кадерлесе — түр яктагы ак шкафта саклана торган чынаяклар. Балачагымның күп кенә татлы мизгелләренең шаһиты алар. Ул чынаяклар безнең өстәлгә бик кадерле кунак килгәндә яисә Коръән мәҗлесләре үткәргәндә генә куела иде. Иң тәмле чәй шул чынаяктан эчкән чәй була иде. Бәйрәм узу белән, алар, әйбәтләп юылып, корытып сөртелеп, кадерле кунак кебек, үз дәрәҗәләрен бик яхшы белеп, яңадан урыннарына менеп кунаклыйлар. Икенче кунаклар җыйганчы, шунда торалар. Безнең ише бала-чагага, ватар-нитәр тагын дип, тоттырып та карамыйлар иде.

Бу чынаякларның гади түгел, ниндидер сер саклауларын кечкенә булсам да сизенә идем, ләкин шактый еллар узгач кына аларның тарихы турында дөресен белә алдым. Чынаяклар хакында чын хикәятне миңа әниемнең абыйсы Миңнислам абый сөйләде. Беренче рус революциясе белән бер елны (1905) туган бабам Бәдретдин, Зыятдин атлы абыйлары белән (алар 7 малай), узган гасырның 20 нче елларында Идел буена ябырылган ачлыктан котылырга теләп, Мәскәү өлкәсе Вербилки бистәсенә китәләр, андагы фарфор заводына эшкә урнашалар. Эшләп караган, күргән эшләре булмаса да, бу уңган егетләр тиз арада, планнарын арттырып үтәп, алдынгылар рәтендә бара башлый. Ә бер бәйрәмдә хезмәт хакларына өстәп, премия итеп, үзләре эшләгән 12 чынаяк (бер дюжина) та бирәләр. Егетләр аларны авылда үзләрен сагынып көтеп калган әниләре Азизә әбигә бүләк итеп алып кайта. Азизә әби улларының бу кадерле бүләген, җаныннан да артык күреп, күз карасыдай саклый, хәтта әҗәле җитеп, үләр вакытында да суны шул чынаякта бирүләрен сорый, соңгы йотымны шулардан эчә.

Вак кына чәчәкләр төшерелгән, тотарга да куркырлык юка әлеге чынаякларны да илебез иңенә төшкән аянычлы язмыш урап узмаган. 1933 елда кулакларга каршы көрәш башлангач, үз хезмәтләре нәтиҗәсендә хәлле генә яшәп ятучы Җамалетдиновлар гаиләсенә дә әлеге зур давылның шаукымлы җилләре килеп кагыла. Көннәрдән бер көнне «сәвит куштаннары» ике бертуган яшь этинең күкрәк балалары берни белми йоклап яткан пар бишекне ат аранына чыгарып әләләр дә барын бергә, югын

уртак итеп бәхетле яшәгән зур гаиләнең өен көпә-көндез сүтә башлыйлар. Бу сабыйларның берсе, әниемнең апасы Камәрия, бу гаделсез дөньяда тормавың яхшырак дип, бер яше тулганчы ук гүр иясе була. Икенче бишектә яткан Әсимә апаның да гомере кыска була.

Әллә нинди гомергә онытылмаслык кара көн була ул. Өйдәге самавырны да, түшәк-ястыкларны да, теге 12 пар чынаякны да ат арбасына төяп алып китәләр. Бу көнне бабам өйдә булмый, ерак кырга урак урырга киткән була. Авыл өстеннән төтен шикелле кара болыт күтәрелгәнен күргәч, янгын дип куркып, атны тугарып, арбасын калдыра да үзе шул атка атланып, авылга «оча». Урам башына җитсә, өйләре күренми, кара тузан эчендә, әнисе елыйелый шешенеп беткән. Өй бүрәнәләрен арбага төяп маташалар. Ә теге кара болыт төтен түгел, ә өй чормасына салынган туфрактан чыккан тузан икән. Өен сүткәнне, нигезен туздырганны кем тыныч кына карап тора алсын?! Бигрәк тә әнисенең күз яшьләре, чарасызлык бәгырен өтә бабамның. Ул чакта 28 яшьлек, инде ике бала әтисе бабам үз-үзен белештермичә сикереп менә дә багор тотып, түбәне каерып торучы ирне сыптырып та ега. Ничек утыртып куймаганнардыр үзен, ничек Ходай саклагандыр?!

— Чынаякларымны да калдырмадылар, ичмасам, — дип, өзгәләнә Азизә әби. Бабам аны ничек юатырга да белми. Олы улы Миңнисламга ике яшь кенә, хатыны Гөлмиҗамал (минем әбием) күкрәк баласы белән. Бабама Чыдар кушаматы нәкъ шул көнне тагылгандыр, мөгаен. Бабам ул кушаматны гомере буе горурланып йөртте.

Икенче көнне бабам кибет янында үзләреннән талап алынган әйберләрнең сатылганын ишетә. Тиз генә акча хәстәрли дә шунда йөгерә. Барса, әйберләре сатылып бетә язган, ерактан бүләккә алып кайткан чынаякларның да дүртесен алганнар. Ярый, әле, алар бәхетеннән сигезе калган. Бабам ике дә уйлап тормый, аларның барысын да сатып ала. (Үз чынаякларын үзе!) Башына төшкән кайгылардан картаеп калган әнисен сөендерәсе килгәндер инде.

Улларының бүләген күргәч, Азизә әби, күз яшьләре аша елмаеп: «Кайткан малда бәрәкәт бар, улым!» — ди. Ана йөрәге дөрес сизенгән: бабамнар элеккегесеннән дә матуррак, яхшырак йорт җиткереп керәләр. Бабам 9 балага гомер бүләк иткән (берсе минем әнием). Авылда алма бакчасы, умарта асрау белән дан тотып, соңгы елларда авыл мулласы вазифасын да башкарып, картайганчы үз аягында, үз акылында йөреп, тормышның тәмен табып, 97 яшенә кадәр яшәде. Балаларына, без — оныкларына да шулай яшәүне васыять итеп калдырды.

Чынаяклар хакында абыйның чын хикәятен ишеткәч, минем аларны күрәсем, кулыма тотып карыйсым килде.

Менә мин балачагымның иң күңелле чоры, җәйге каникулларым узган, миңа бик тә кадерле булган нигездә — бабам өендә. Кеше тормаганга, таптап йөрмәгәнгә «сөенеп» үскән минем буйлы кычытканнарны аралап, ишекләрне бикләгән йозакларны ачып, хатирәләрне куркытмыйм тагын дип, сак кына басып, өй эченә үтәм. Бернәрсә дә үзгәрмәгән, барысы да элеккечә: түрдә — шамаил, диварда — сәгать. Кадерле кешеләрем генә юк... Түрдәге ак шкафтан кадерле ядкәр — бүләк чынаякларны сак кына алып, өстәлгә тезеп куям. Кемнәрнең генә кул җылысын сакламый алар! Никадәр генә бөтен нәсел белән күз карасыдай саклансалар да, еллар алар өчен эзсез үтмәгән: инде җидәү генә калганнар, кайберләрендә чатнаган эзләр дә бар, ялтыравыклары да купкалаган, чәчәкләренең җетелеге кимегән — тик затлылыкларын югалтмаганнар. Үтә күренмәле диярлек фарфорга ялгыш саксызрак кагылып киткән идем, зыңлап-чыңлап тавыш биреп куйды. Гүя, бабам: «Үткәннәрне онытмагыз-з-з!» — дип, чорлар аша эндәште...

ТАҺИРОВ И.Р.
ИЛ КОРАБЫН ҖИЛ СӨРӘ: мәкаләләр, истәлекләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — 383 б. Тиражы — 2000 экз.

Күренекле татар галиме, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Индус Ризак улы Таһировның соңгы елларда язылган мәкаләләр һәм истәлекләр җыентыгы мәшһүр шагыйрь Дәрдмәнднең шигъри юллары белән аталган.

Шагыйрь Дәрдмәнд күзаллавында Диңгез тормыш-яшәешне билгеләсә, Җил һич кенә дә тыныч булмаган заманда язмышны символлаштыра. Һәр кеше Ил корабы төшенчәсен үзенчә аңлый: берәүләр өчен ул Россия язмышын, икенчеләр өчен Татарстан язмышын гәүдәләндерә. Тарихчы Индус Таһиров өчен дә, шагыйрь Дәрдмәнд өчен дә Ил корабы татар милләтенең язмышы белән аваздаш. Ил корабын «җан сорап» «упкын тарта» башлаган заманда гыйлем иясенең сүзләре, битарафлык пәрдәсен ертып, тирәякка көчле аваз булып яңгырый.

Бу китап җәмгыятебезне үзгәртү кирәклеге турында. Сигез мәкаләне берләштергән, «Без — татарлар» дип аталган беренче бүлектә сүз татарның бүгенге халәтенә бәя бирү, килеп туган проблемаларны хәл итү юлларын эзләү һәм чишү рәвешендә язылган.

Автор, үткәнгә мөрәҗәгать итеп, революциягә кадәр татарларның үзләрен саклап калу системасын төзи алуына игътибар итә. Бу модельнең иң мөһим элементлары дип татарның үз мөмкинлекләренә көйләнгән мөстәкыйль мәгариф системасы тармагы булдыруны атый. Автор безнең бабаларыбызның гореф-гадәтләрен, милли традицияләрен дәвам итәрлек һәм үстерерлек яшәү рәвешенә ия булуларын күрсәтә. Татарларның рус дәүләтендә, башка халыклар арасында, үз урыннарын билгели алулары шушы системаның аерылгысыз бер өлеше булып тора, дип яза тарихчы (Б.61).

Тел һәм моң — милләт сакчылары, ди автор. Тел бетсә, моң да калмый, милләт тә бетә (Б.25). Туган телебезне чын-чынлап гамәлгә кертү өчен, Индус Таһиров өч зур бурыч билгели. Беренчесе — татар телен дәүләти дәрәҗәгә күтәрү. Икенче төрле әйткәндә, Татарстан дәүләте, Дәүләт Советы үз халкы белән шушы телдә сөйләшергә, шуңа омтылырга тиеш, чөнки халык телебезгә карата җитди сәясәт барлыгын тоймаса, көндәлек яшәештә телгә урын калмаячак. Икенче бурыч ул — туган телне татар гаиләсенә кайтару. Балаларының телләрен туган телдә ачтыру һәм милли рухта тәрбияләү — һәр ата-ананың милләт алдындагы изге бурычы, дип ассызыклый галим. Өченче бурыч — шәһәр җәмәгатьчелеген татарча сөйләшүгә күндерү. Бигрәк тә татарларның башкаласы булган Казанда инде күзәтелә торган уңай күренешләрне бу яктан тагын да үстерү мөһим. Бирегә төрле җирләрдән килгән милләттәшләребез татар яшәешенең үрнәкләрен күрергә, туган телебезнең тулы хокуклы икәненә инанырга тиеш. Казан чын-чынлап татарча сөйләшә башласа гына, телебезнең мәңгелегенә гарантия барлыкка киләчәк, дип белдерә галим (Б.37-38).

Икенче бүлеккә төрле елларда язылган төрлечә исемләнгән мәкаләләр тупланса да, алар идея эчтәлеге ягыннан бер җепкә тезелгән. Төп идея бүлекнең исемендә чагылыш таба — «Азатлык юлында». Индус Таһиров татарның бүгенге халәтенә борынгы чорларда һәм урта гасырларда дәүләтләр тезгенен тоткан шанлы төрки-татарлар тарихыннан чыгып бәя бирә. Казан ханлыгын югалтудан соң ясалган ялгышларны киләчәктә кабатламаска ишарәләп санап чыга, Совет империясенең эчтәлеген, «төсен» үзгәртүче, Россия Федерациясенә җан өрүче «мәңгелек халык» булган татарларның үз ирек-хокукларын яклап көрәшүләрен тасвирлый, югалту һәм табышларны барлый. Автор укучының игътибарын ике мөһим чор вакыйгаларына юнәлтә: 1) Октябрь инкыйлабыннан соң дәүләтчелек өчен көрәш юлында тормышка ашмый калган «Идел-Урал штатлары», «Татар-башкорт республикасы», ТАССРга СССР составында тулы хокуклы республика статусы бирү өчен барган көрәш, шул вакыйгаларның каһарманнары һәм газраилләре; 2) «Үзгәртеп

кору» елларында ТАССРга союздаш республика статусы, «мөстәкыйльлеккә кайту» өчен барган көрәш, Мәскәү белән Татарстан арасындагы шартнамәләр төзү тарихы, әлеге документларның Россия Федерациясе һәм татар милләте өчен әһәмияте турында җентекләп яза. Бу тарихи чорлар буенча И.Р.Таһиров — зур белгеч. Аның һәр җөмләсе фактлар белән ныгытылган, тирәнтен өйрәнелгән. Ә соңгы егерме елда булып узган вакыйгаларны бәяләгәндә, И.Р.Таһиров күзәтүче генә түгел, ә тормышка ашыруга күп көч куйган шәхес буларак та сүз алып бара. Киләчәк буыннар бу язмалар буенча, һичшиксез, Татарстан Республикасының тарихын өйрәнәчәкләр һәм язачаклар.

Бүгенге көнгә карата авторның фикере нинди соң? Бер сүз белән әйткәндә, бирешмәскә, фәкать алга ыргылыш ясар өчен чигенергә һәм, иң мөһиме, бердәм булырга!

Соңгы, өченче бүлек, истәлекләр бүлеге, китапның логик дәвамы сыман кабул ителә. Биредә Индус Таһиров Татарстан Республикасының суверенлыгы турында 1991 елның 30 августында Дәүләт Советы кабул иткән документның беренче проектын төзүче буларак та, 12-15 август көннәрендә Мәскәүдә консультацияләр үткәргән Татарстанның рәсми делегация әгъзасы буларак та ачыла; аннан соңгы сөйләшүләрдә тигез хокуклар алу өчен барган көрәш турында да яза, ике республика арасында Шартнамә төзү, Татарстанда референдум уздыруны тарихи төгәллек белән сурәтли. Сугыш чоры баласынның хатирәләре, Казан университеты профессоры Мансур Абдрахманов, язучы Мөхәммәт Мәһдив, журналист, остазы Флорит ага Әгъзәмов, җырчы Хәйдәр Бигичев турында истәлекләре аеруча якын итеп, җылы язылган. Бу язмалар арасында Мирсәет Солтангалиевкә багышланган мәкалә аны милли каһарман буларак та, фаҗигале язмышлы татар, шәхес буларак та ача.

«Ил корабын җил сөрә» дип аталган басмада урын алган язмалар татар кешесенә бүгенге тормыш диңгезендә кыйбланы дөрес билгеләү һәм шуңа таба бару юлларын күрсәтә. Әһәмияте дә шуннан гыйбарәт. Китап укучыны битараф калдырмас дип ышанабыз.

Илдус Заһидуллин

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

ТАТАРСТАН ПАРЛАМЕНТЫНДА — ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАСНЫ САКЛАУ МӘСЬӘЛӘСЕ

2012 елның 4 июлендә Татарстан парламентында Тарихи-мәдәни мирас елы уңаеннан сөйләшү булып узды. Аның эшендә Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, галимнәр, сәнгать белгечләре, прокуратура вәкилләре, юристлар, архитекторлар һ.б. катнашты. Парламент тыңлауларын Дәүләт Советының мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев ачты. Ул Дәүләт Советы депутатларының 14 тарихи бинаны саклау эшен үз күзәтчелеге астына алуларын хәбәр итте, алда торган бурычларга тукталды, республикада төзекләндерү һәм саклауга мохтаҗ тарихи-мәдәни мирас һәйкәлләренең, китапханә-архив киштәләрендә саклана торган язма чыганакларның санын атады.

Төп докладны Татарстан Мәдәният министры урынбасары Светлана Персова ясады. Ул 2013-2016 елларга исәпләнгән «Мирас» дәүләт программасының кабул ителмәгән булуын искәртте, республикада 1550 данә тарихи-мәдәни һәйкәлнең саклануга мохтаҗ булуын әйтте, башка хәл итәсе мәсьәләләрне атап узды.

Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тикшерелгән мәсьәлә буенча үзенең җитди таләпләрен күрсәтеп чыгыш ясады. Ул бу эшнең вакытлы компания генә түгеллеген, ә мәдәният өлкәсендәге дәүләт сәясәте булуын ассызыклап, тарихи, мәдәни һәйкәлләрне саклауны тәэмин иткән дәүләт оешмаларыннан җаваплылыкны арттыруны таләп итте.

Казан шәһәре прокуроры Илдус Нәфыйков чыгышы Татарстан башкаласындагы тарихи объектларны барлау, аларны төзекләндерү һәм саклау өлкәсендә башкарылган эшләргә һәм алда торган проблемаларга, аларны чишү юлларына кагылышлы иде.

Чыгышлар күпсанлы сораулар тудырды. Фикер алышудан соң тикшерелгән мәсьәләдә депутатлар беренче чиратта башкарылырга тиешле эшләр күрсәтелгән рекомендацияләр кабул иттеләр.

ВЛАДИВОСТОКТАГЫ ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ

XII федераль Сабантуй 30 июнь көнне Тын океан буенда Владивосток шәһәрендә үтте. Мәйдан рәсми эмблема, рус һәм татар телләрендә бәйрәм котлаулары белән бизәлгән иде. Тантана хореографик композиция белән башланды. Башка Сабантуйлардан аермалы буларак, анда Приморье краеның диңгез төбәге булуы чагылды. Башлап халык алдына диңгез алласы Нептун чыкты. Ул бәйрәмгә килүчеләрне сәламләде һәм үзенең карары белән патшабикә Иделне Сабантуй хуҗабикәсе итеп билгеләде. Соңрак Түбән Кама сәнгать осталары тарафыннан театральләштерелгән «Сабантуй» хореографик композициясе күрсәтелде. Сабантуй кунакларына һәм катнашучыларга сәламләү сүзе белән Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Приморье крае губернаторы Владимир Миклушевский мөрәҗәгать итте. «Бу матур бәйрәм — Сабантуй күптән интернациональ бәйрәмгә әверелде. Аны татар һәм башкорт халыклары гына түгел, ә Россия, Приморье краеның күп кенә халыклары да бәйрәм итә. Бер-береңнең мәдәниятен, традицияләрен белеп, уртак бәйрәмнәрне бәйрәм итеп, бары тик шулай гына бер гаилә булып яшәп була», — дип котлады Владимир Миклушевский. Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында Владивостокта Казан мәчетенең нигезенә беренче таш салу тантанасы узуын искәртте: «Бу илебезнең зурлыгы, анда төрле милләт вәкилләре яшәве, аларның төрле диндә булулары турында сөйли. Иң яраткан бәйрәмебез — Сабантуй барлык милләт вәкилләренә ошый. Безнең дин яхшылык тарата, биредә безгә мәчет төзелешенә иң яхшы урын бирделәр. Бүген яңгыр явып үтүе дә — яхшы билге. Димәк, безнең бүген башкарган эшләребез яхшы нәтиҗә бирәчәк», — диде ул. Рөстәм Миңнеханов татар традицияләренә, мәдәниятенә, йолаларына хөрмәт белән караган Приморье крае губернаторы Владимир Миклушевскийга, төбәк хөкүмәте җитәкчелегенә рәхмәтен белдерде.

Сабантуй символы — Тулпар ат эстафета рәвешендә Төмән өлкәсе вәкиле Евгений Воробьевка тапшырылды.

МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ФЕСТИВАЛЕ

25 июньнән 1 июльгә кадәр Татарстанның «Идел» яшьләр үзәгендә Россия күләмендә VI Мөселман яшьләре фестивале уздырылды. Әлеге чара ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Татарларның федераль милли-мәдәни мохтарияте, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, «Идел» яшьләр үзәге һәм ТР Президентының Дини берләшмәләр белән элемтәләр идарәсе теләктәшлеге нигезендә оештырылды. Бирегә илебезнең төрле төбәкләреннән якынча 150 делегат килде. Алар үзләренең дин өлкәсендәге эш тәҗрибәләре белән уртаклашты, дөньякүләм танылган җәмәгать эшлеклеләренең, дин галимнәренең, имамнарның һәм җитәкчеләрнең файдалы лекцияләрен тыңлап, яңа мәгълүмат туплады; «Мәрхәмәт» акциясендә катнашты, шәһри Болгарга сәяхәт итте. Җәмигъ мәчетендә исә Коръәнне яттан уку бәйгесе уздырылды. Киләчәктә бердәм булырга, үзара аралашырга, ярдәмләшергә вәгъдә кылышканнан соң, фестиваль рәсми рәвештә тәмам дип игълан ителде.